# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 821.512.145-1-93:821.0
ББК 84(2Рос=Тат)5:83
М57

Редколлегия:
З.Р.Вәлиева, М.Х.Вәлиев,
Ш.Г.Галиев, И.Г.Юзеев, Ф.И.Урманчеев

**Миңнуллин Роберт**

Сайланма әсәрләр: Балалар өчен шигырьләр, әдәби тәнкыйть, иҗат портретлары, рецензияләр: I китап.—Казан: Мәгариф, 2004.—447 б.
ISBN 5-7761-1347-4

ISBN 5-7761-1347-4 © «Мәгариф» нәшрияты, 2004

## Без телəгəн шагыйрь

Балалар әдәбиятында Шәүкәт Галиевтән соң... Яңа исемнәрне шулай дип башлап китәрләр шикелле. Тукай шактый ерак, Бари Рәхмәт тә ераклашып бара, Шәүкәт Галиев—уртада. Бүгенге балалар поэзиясендә иң уртада. Шәүкәттән соң бик күп исемнәрне санармын, дип тотынган идем. Аз икән, сирәк килә икән, саран икән балалар әдәбияты. Аралары—унар ел. Ун елдан соң—Роберт Миңнуллин. Поэзиягә шагыйрьләр дулкын-дулкын булып киләләр, дип сөйләргә яратабыз. Монда башкача икән. Балалар әдәбиятының үз кешеләре бар, күрәсең. Болай барыбыз да язганбыз, хәтта аерым җыентыклар да чыгарганбыз, әмма балалар әдәбияты барысын да үз арасына алырга ашыкмаган. Балалар язучысына теге кирәк, бу кирәк, диярләр. Ул—педагог, балалар психологиясен дә белергә тиеш. Мин дә, тиеш, дим.

Мин, шулар өстенә, ул әле балалар язучысы булып туарга тиеш, дип тә өстәр идем. Специфик өлкә. Туганда ук алар шушы өлкәгә багышланып туалар булса кирәк. Табигатьләре белән балалар язучысы. Мин аларга кызыгып яшәдем. Балалар китапларының рәсемнәре дә әллә нинди, балачакны искә төшереп, сагындырып торалар. Мәктәп яшенә җитмәгән сабый да аларны ятлый, сине—юк. Шәүкәт Галиев белән Роберт Миңнуллин шигырьләренең яртысын китаптан укып белсәм, яртысын балалардан ишетеп беләм.

«Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек...» Робертның шундый җыры бар. Популяр җыр. Актаныш якларыннан, Сөннән, Агыйдел буйларыннан башланып китә ул җыр. Балалык күңеленнән, балалык моңсулыгыннан башлана. Балалар әдәбиятына Роберт шушы җырдан кереп китмәдеме икән? Очы шунда кебек. Киң дөньядан, әкият дөньясы—табигать эченнән башлануы ошый миңа. Актаныш якларының чын поэзия урыны икәнлегенә үзем ул якларда булып та ышандым. Халкы, табигате, җире... Җырның әнкәйләрдән башлануы да очраклы түгел. Шагыйрьне шагыйрь иткән нәрсәләр: җир, табигать, халык...

Шәүкәт Галиевнең мин әнисен күреп белә идем. Аның сөйләү характерында Шәүкәт үзе, шаянлыгы—әнисеннән... Роберт Миңнуллинның «Айга очтык» китабын укыгач, яңадан Шәүкәт әнисе искә төште. Роберт шигырьләренең теле, юморы искә төшерде. Робертның әнисе дә шундыйдыр, дип уйладым. Мин шагыйрь күңеленә салынган нәрсәләрне әнкәйләр рухыннан, туган телдән эзлим. Бөтен җылылык, байлык шуннан. Шигырьләрнең күбесенә игътибар иттергән нәрсә шул тел булды. Читләренә «тел» дип яза

бардым. Гадәттә, әсәрнең теле начар, теленә игътибар ит, диләр. Мин, соклану билгесе буларак, «тел» дип куйдым.

Тел үзе генә матур була алмый. Телнең матурлыгы—тормыш белән бергә үрелгәндә. Тел һәрвакыт *җир*, *халык*, *ил* кебек төшенчәләр белән бергә йөри. Алар—аерылгысыз. Роберт шигырьләрендә шушыларның барысын бергә бәйләгән нәрсә—гадилек. Роберт шигырьләренең музыкага ятып торуы турындагы фикерләрне минем композитор Рөстәм Яхинның үзеннән ишеткәнем бар. Халыкчан гадилек ул шигырьләрдә.

Тагын бер күзәтүем турында әйтеп китәсем килә. Балалар әдәбиятында—дүрт шагыйрь. Балалар әдәбиятының башында—Тукай. Бари Рәхмәттә, Шәүкәт Галиевтә, Роберт Миңнуллиндагы халыкчанлыкның очы Тукайга тоташкан. Нигезен ул салган. Дүртесендә дә шул халыкчанлыкны эчтән җылытып, нурландырып җибәрә торган бер сыйфат—юмор. Шигырь ничектер җанлана, яктырып китә. Балалар шигырьләрен моңардан башка күз алдыма китерә алмыйм. Менә аларның кайберләре: «Энекәш кирәк миңа», «Тәмле кычыткан», «Өлкәннәр», «Җиде абый тай җигә», «Әни эштән кайтканчы», «Әтием палас кага», «Мияулый торган ишек», «Ак ат», «ДТ-75 тракторының улына җырлаган бишек җыры», «Югалган хәрефләр», «Туган тел».

Шигырьне сынный торган урын—трибуна, укучы, халык. Роберт шигырьләрен мин заллардан укучы булып тыңладым. Үз буыны шагыйрьләре арасында ул—иң популяры. Популярлыгына җырлары да булышкандыр, телестудиядән алып барган «Шигъри тәлгәшләр» дә ярдәм иткәндер. Минемчә, беренче чиратта, әлеге балалар шигырьләре—табигый юмор белән өртелгән, тормышчан, халыкчан шигырьләр.

Роберт Миңнуллин—вакытлы, очраклы шагыйрь түгел. Халыкта озак яшәүчән кешеләргә, тамыры нык, үзәге нык, диләр. Робертның басып торган җире нык.

Бу Сөн буйларыннан килеп чыккан яшь шагыйрь турында сүз әйтү өчен җай эзләп йөри идем. Беренче җай, билгеле, шушы китабы. Икенче җай—хәзер комсомолның Муса Җәлил исемендәге премиясенә әсәрләр тәкъдим итү бара. Бездә балалар әдәбиятына игътибар зур. Җәмгыятьтә камил шәхес тәрбияләү шул балалардан башлана.

Кайчандыр Мәскәү белән Казан арасында «Октябрь баласы» журналына хәбәрчеләр эзләп йөргән Муса Җәлил үз юлында Роберт Миңнуллинны очраткан булса, бу—мин тапкан, мин теләгән шагыйрь, дияр иде. Ул, чыннан да, без теләгән шагыйрь!

*Сибгат Хәким*
*1982*

Җиде абый тай җигә

Яшь бер тайны
Җигәр өчен,
Шул бер тайны
Җиңәр өчен
И тырыша
Җиде абый,
И булыша
Җиде абый!

Тик тай дулый!
Кыргыйдыр ул,
Шуңа да тик
Тормыйдыр ул,
Шуңа күккә
Ыргыйдыр ул,
Шуңа җирне
Тырныйдыр ул!

Аны һич тә
Җиңеп булмый,
Хәтта якын
Килеп булмый,

Тибүе бар! —
Белеп булмый.

Тайны әйтәм,
Шундый көчле! —
Коеп куйган
Минем төсле!

Мине ләкин
Җибәрмиләр,
Җитмәс синең
Җегәр, диләр.

Алар мине
Белмиләр шул,
Минем көчне
Күрмиләр шул.

Җәфа чиксәм
Чигәр идем,
Мин ул тайны
Җигәр идем,
Мин ул тайны
Җиңәр идем,
Туйганчы бер
Җиләр идем...

Ләкин мине
Җибәрмиләр,
Якын барма,
Тибәр, диләр,
Йә әниең
Тиргәр, диләр,
Кирәк монда
Ирләр, диләр.

Ә үзләре
Җигәлмиләр,
Шул бер тайны
Җиңәлмиләр,

Адәм тәганәләре!

Ьлкәннәр

Бу өлкәннәр ни өчендер
Гел киресен эшлиләр.
Мин үзем чәй эчмим, алар
Кыстый-кыстый: «Эч!»—диләр.

Урамга чыга башласаң:
«Ныгытып киен!»—диләр.
Ә үзләре ни өчендер
Ныгытып киенмиләр.

Йоклыйсы килмәгән чакта:
«Бар инде, йокла!»—диләр.
Йоклаганда: «Тор инде, тор,

Аунама юкка!»—диләр.

Уйнаганда: «Китап укы,
Уйнап утырма!»—диләр.
Укысам: «Башың авыртыр,
Бик күп укыма!»—диләр.

Әгәр дә өйдә утырсам:
«Бар, урамда йөр!»—диләр.
Ә урамга чыгып китсәм:
«Бик күп йөрмә, кер!»—диләр.

Эшсез йөрсәң дә ярамый:
«Бераз ярдәм ит!»—диләр.
Әгәр ярдәм итәм дисәң:
«Борчып йөрмә, кит!»—диләр.

Тотынсаң вак-төяк эшкә,
Алар бирә эресен.
Аңламассың — бу өлкәннәр
Эшлиләр гел киресен!

Бүтәннәр күрмәсә дә...

Беркем дә
Күрми диеп,
Белмиләр
Берни диеп,
Чәчәкләрне өзмим мин,
Каеннарны каермыйм,
Сары томшык кошларны
Оясыннан аермыйм.

Дәресне әзерләми
Урамда йөргәнем юк,
Күршеләр бакчасына
Кыярга кергәнем юк.

Күрмиләр
Әле диеп,
Белмиләр
Әле диеп,
Урамнан узып барган
Машинага тагылмыйм,
Үземнән дә көчсезрәк
Малайларга кагылмыйм.

Кыерсытмыйм энемне,
Юатамын, еласа.
Янган чакта кызыл ут,
Чыкканым юк юл аша...

Бәлки чыгар
Идем дә,
Күзләрем бар
Минем дә.

Үзем тәртип

Бозганны,
Урам аша
Узганны
Бүтәннәр
Күрмәсә дә,
Бүтәннәр
Белмәсә дә,
Мин күреп
Торачакмын,
Мин белеп
Торачакмын.
Әгәр чыкса,
Мин аның
Колагын борачакмын!

## Торам менә елмаеп

Әтиемнең малае
Бераз шаянрак.

Әниемнең малае
Бераз наянрак.

Әбиемнең оныгы
Бераз кирерәк.

Ә бабамның оныгы
Бераз эрерәк.

Абыемның энесе
Начаррак укый.

Сеңелемнең абыйсы
Артыграк йоклый...

Шул бер малай бит инде
Алар барсы да—

Торам менә елмаеп
Сезнең каршыда!

## Айны ничек менгезим?

Их, ярты Ай
Югалган.
Кая киткән
Ул аннан?

Эзләп киттем
Мин Айны.
Табачакмын
Мин аны.

Эзли торгач,
Арылды...
Ай шулай да
Табылды.

Якты Айның яртысы
Йөзеп йөри Иделдә.
Идел тирән, Айны мин
Алып чыгар идем дә...

Ничек менгезеп куйыйм?
Җитми шул минем буем.
Ул үзе менмәс инде,
Ул менә белмәс инде.

Елга туңса, ярты Ай
Боз астында калачак.
Боз астында ул Айны
Чуртан тотып алачак!

Ул бер генә
Кабачак—
Ай сизми дә
Калачак!

Айны ничек
Менгезим?
Менгезергә
Юл эзлим...

Әһә, таптым, дусларым,
Нигә озак уйларга?—
Биреп җибәрәм Айны
Космонавт абыйларга.

Олы булсам...

Олы булсам, мин улыма
Чын маэмай алыр идем.
Каникулда улым белән
Диңгезгә барыр идем.

Улымны көн дә бер тапкыр
Кинога кертер идем.
Көннәр буе машинага
Утыртып йөртер идем.

Бер бинокль, фотоаппарат,
Велосипед кимендә,
Сатып алып бирер идем
Аның туган көнендә.

Их, зур булсам, әти булсам,
Нишләргә белер идем:
Ни сораса да, улыма
Гел алып бирер идем.

Ике уйлап тормас идем,
Ник көләсез?
Көлмәгез!
Үзенә дә кирәк икән

Диеп уйлый күрмәгез!

## Карбабайның борыны турында
## ике шигырь

1

Ясадым мин кичәгенәк
Менә дигән Карбабай.
Матур чыкты.
Карбабайга
Гаҗәпләнде бар малай!

Тик ни күрәм
Иртә белән:
Карбабайның борыны
Юкка чыккан.
Борынының
Калган бары урыны.

Их, сакларга кирәк булган,
Берәр хәйлә корырга.
Онытканмын бит мин аңа
Таягын тоттырырга.

Таягы булса, беркем дә
Аны җиңәлмәс иде,
Ул үзенә беркемне дә
Якын җибәрмәс иде!

2

Ул борын белән, мөгаен,
Бур куян сыйлангандыр.
Сыйлангандыр,
Ә шатлыгы
Эченә сыймагандыр.

Сыйлансын, әйдә, сыйлансын,
Кишер бездә җитәрлек.
Урмандагы бар куянны
Җыеп кунак итәрлек!

Бер сүзем юк, әйбәт булган
Сыйланырга ярагач.
Тик әллә ничек,
Борынсыз
Карбабайга карагач.

Үз борыным исән микән?
Шул килеш,
Ашалмаган.
Ярый әле минем борын
Кишердән ясалмаган!

Пират

Пират бара
Урамнан.
Курыкмагыз
Сез аннан!

Йөрми ул
Хәнҗәр асып,
Йөрми ул
Кораб басып.

Аның бит әле хәтта
Гомерендә бер кат та
Корабны
Күргәне юк,
Диңгездә
Йөргәне юк,
Бер дә су кергәне юк...

Алай булгач, ул пират
Каян килгән дисезме?
Шуны да белмисезме?

Ул бит Пират исемле
Маэмайның исеме!

### Сүз тыңлый торган малай

Безнең Алмаз
Сүз тыңлый,
Сүзне берсүзсез тыңлый.
Каршы килми
Һич кенә—
Булсын аңа
Эш кенә!

— Ярый-ярый,
Эшлим,—ди,—
Эш яратам
Ич мин!—ди.
Булса башка бер малай,
И ялындырыр иде,
Эш тапкан
Булыр иде,
Булмый дип
Торыр иде,
Мең хәйлә
Корыр иде!
Ә ул тормый
Вакланып,
Риза була
Шатланып.

Тик оныта
Үтәргә,
Туры килә
Көтәргә.

Дәшәсең
Аңа кабат,
Әйтә ул
Күзгә карап:

— Ярый-ярый,
Эшлим,—ди,—
Эш яратам
Ич мин! — ди.
Тик оныта
Үтәргә,
Туры килә
Көтәргә.

Көтә-көтә
Туясың,
Үзең эшләп
Куясың!

Әмма ләкин
Алмазны
Ачуланып
Булмый бит—

Киреләнеп
Тормый бит,
Әйткән сүзне
«Тыңлый» бит!

## Әни эштән кайтканчы

Әни таңнан
Эшкә киткән,
Бөтен эшне
Эшләп киткән!..

Нәрсә эшлик икән дип, без
И баш ваттык,
Баш ваттык—
Ахырда җаен таптык:

Банкадагы вареньены
Ялт иттердек
Бергәләп.
Чүлмәктәге
Каймакны да,
Табадагы
Коймакны да
Ашап куйдык
Бүлгәләп!

Безнең бәхеткә, шешәдә
Сөт тә никтер әчегән.
Шуңа күрә без ул сөтне
Салып бирдек мәчегә.

Чират җитте

Акмайга да,
Өлеш чыкты
Акбайга да!

Савытларны юып аннан
Тезеп куйдык өстәлгә.
Тагын эзләгән идек тә,
Савыт беткән өстәргә.

Савыт-сабалар өстәлгә
Таудай өелсен әле.
Чиста савытларны күреп,
Әни... сөенсен әле!

Сөенер шул!
Ә нигә?
Ул савытларны барыбер
Юасы бит... әнигә.

## Бутаган

Алмаз йөри урамда,
Эшләп йөри ул анда.

Чана шуу—бар эше,
Ап-ак булган бар төше.

Акбай, аны күрүгә,
Әй тотынды өрергә!

Аңламый Алмаз берни,
Өрерлек сәбәп күрми.

Ә мин аның Алмазга
Нигә өргәнен беләм:

Бутаган ул Алмазны
Аю баласы белән!

Башында—йонлач бүрек,
Өстендә дә—йонлач тун.

Өрер дә шул, ул үзе
Аю кебек булгачтын!

## Югалган көн

Тырай типкән кичә Фәһим
Һәм бер көнен югалткан.
Ярар, табармын әле дип,
Фәһим үзен юаткан.

Ләкин ничек табарга?
Кирәк эзләп карарга.

Югалган көнен Фәһим

Көне буе юллаган.
Юллавын ул юллаган,
Юлы гына уңмаган.

Сорашып та караган,
Тик күрүче булмаган.

Кичә күргән идек, бүген
Күренмәде, дигәннәр.
Артыннан куып кара син,
Диеп киңәш биргәннәр.

Юк шул инде!
Югалган көн
Сине көтеп тора, ди,
Койрыгын тоттыра, ди...

Фәһим көнсез көенә
Кайтып кергән өенә.

Табалмаган кайгысыннан
Җибәргән Фәһим елап...
Тагын бер көн югалткан ул
Югалган көнен юллап.

## Әтием палас кага

Сызгана да җиңнәрен,
Ала да сыек чыбык,
Кыйный әти... паласны,
Урамга алып чыгып.

Урамда уйнап йөргән
Малайлар, кыз балалар
Үрле-кырлы сикергән
Паласны кызганалар.

Әти көлә: «Бу палас
Тузанланып беткән,—ди,—
Тузаннарын кагарга
Кирәк булган күптән!»—ди.

Мин дә бит, үч иткәндәй,
Тузанга кергән идем,
Урамдагы тузанны
Туздырып йөргән идем.

Әтием палас кага,
Миңа да күз салгалый.
Бер — паласка, бер миңа
Карап-карап алгалый.

Ахры, минем тузанны да
Каккаларга чамалый!

## Мактанырга яратмый...

Мине беләсездер инде!—
Мәрдиев мин, Марат мин.
Мактарлык малай булсам да,
Мактанырга яратмыйм!

Миннән дә шәп укучы юк,
«Бишле» алдым бүген дә.
Шуңа мактанып торырга
Мин мактанчык түгел лә!

Мактанырга була, ләкин
Кирәк түгел ваклану.
Минем кебек шәп малайга
Килешми ул мактану.

Әгәр дә бик кирәк икән,
Иптәшләрем мактасын.
Йә килеп карый аласыз
Безнең мактау тактасын!

Башка малайлар шикелле,
Бәлки мактаныр идем,
Болай да һәркем белә бит
Әйбәтлегемне минем!

## Әйтмим

Әни кайтып керде дә:
— Пыр тузган өй эче!—ди,—
Ах, тәлинкәм ватылган,
Кайсыгызның эше?—ди...

Тәлинкәне
Кем ватканны
Беләм бары мин генә.
Беләм дә...
Әйтмим генә.

Ярар инде, сорашмагыз!
Ярдәм итмәс үгетләр.
Әйтер идем, әйбәт түгел
Сер сөйләсә егетләр.

Әйтмим аны әнигә дә,
Әйтмим аны сезгә дә.
Әйтмим булгач, әйтмим инде,
Әйтмим берегезгә дә.

Әгәр дә ул серне чишсәм,
Көлер идегез бугай,
Тәлинкәне
Мин ватканны
Белер идегез бугай,

Хәйләкәрләр!

## Булатларга кунакка!

Булат яши Әстерханда,
Алмаз яши Казанда.
Булатка ай-яй әйбәттер—
Күптән инде яз анда...

Хатлар килә ерактан—
Алмазга ул, Булаттан:

«Сездә һаман кыш әле,
Җимешләр әздер анда.
Кавын, карбыз, йөземнең
Оясы—Әстерханда!

Бездә Идел киң,—дигән,—
Кунак булып кил!—дигән.—
Сиңа бик уңай,—дигән.—
Әгәр дә булса көймәң,
Булмый хәтта ишәсең:
Иделдән агып кына,
Җырлап кына төшәсең!»

Алмаз шушы хаттан соң
Көн саен хәзер әнә
Кунакка әзерләнә.

«Язны гына көтәм,—ди,—
Әстерханга китәм,—ди,—
Казанда яз җитүгә,
Иделдән боз китүгә,
Мин бит үсеп җитәм,—ди,—
Бәләкәй малай булып
Бик күп йөрдем, җитәр!—ди...»

Язлар җитте, җәй булды—
Алмазга да җәй булды!

Теплоходта бара ул:
Бүләкләре—Булатка!
Үзе белән әтисен дә,
Үзе белән әнисен дә
Ияртеән ул кунакка!

## Йолдызлар

Бардык та кичә балыкка,
Елгада таң аттырдык.
Тик без балык каптырмадык,
Без йолдызлар каптырдык.

Йолдызлары шундый эре!
Кимендә, менә мондый.
Күрсәгез, күрер идегез—
Чуртан да андый булмый.

Без тоткан йолдызлар белән
Зу-ур чиләк тулган иде,

Чиләгебез йолдыз белән
Чүмәкәй булган иде.

Тик йолдызлар иртә белән
Качканнар да беткәннәр.
Хәйләкәрләр—качар өчен
Таңны гына көткәннәр.

Алар бер дә юкка гына
Качкан ла күгебезгә.
Без җибәргән була идек
Аларны үзебез дә!

Сабантуйда

Колга тора мәйданда—
Биегрәктер Айдан да!

Әтәч—колга башында,
Кызыктыра барсын да!

Тик менәлми беркем дә,
Мин дә бар шул төркемдә.

Менә миңа да чират.
Менәм,
Мин дә бит ир-ат!

Менеп киттем тиз генә,
Тиз генә, җитез генә!

Һәм карадым түбәнгә—
Ай-яй... биек менгәнмен,
Ничек менә белгәнмен?!

Ничекләр төшим җиргә?
Куркыта карарга да.
Торам шулай, киләлми
Бернинди карарга да...

Үч иткәндәй, әтәч тә,
Бөтен көчкә кычкырып,
Китте кулдан ычкынып!

Ычкынды, җиргә очты,
Йоны гына — учымда.
Әтәч урынына мин
Калдым колга очында.
Кирәкми әтәчегез,
Кирәкми бүләгегез—
Мине алырга гына
Менегез берәрегез!

Кем нәрсә тарта...

Тегермәнче минем әти—

Тегермәндә ул он **тарта**.
Абыйны да шунда кыстый—
Көн дә аның кылын **тарта**.

Ләкин абый гел баш **тарта**:
— «КамАЗ»ым бик кызганыч,—ди,—
Әле эшли торган эшем
Күңел **тарта** торган эш,—ди.

Клуб идәне дер селкенә,
Минем абый биегәндә.
Ул бит Алып батыр кебек—
Ун пот **тарта** ким дигәндә!

Клубка китте ул бүген дә.
Тышта берәү гармун **тарта**.
Шул гармунны тыңлый-тыңлый,
Апам тиз-тиз сөрмә **тарта**.

Ә мине кич чыгармыйлар —
Җәйгән әни урынымны.
Чыгармыйлар, шуңа күрә
**Тартып** ятам... борынымны.

## Кызыл тавык

Безнең кызыл тавыкның
Чебиләре унбишләп.
Чебиләрен саклап кына
Йөртә микән ул нишләп?

Алар янына
Килсәм,
Килеп яратыйм
Дисәм,

Чебиләр
Тик тормыйлар,
Чебиләр
Тоттырмыйлар.

Кызыл тавык
Шунда ук
Килә дә
Очып кына,
Өстемә
Очып куна,
Котылам
Качып кына...

Кызыл тавык чебиләрен
Бер дә читкә таратмый.
Чебиләрен ярата ул,
Мине генә яратмый.

Чебиләрен ярattырмый,

Тоттырып та каратмый.
Әйтегезче, кызыл тавык
Нигә мине яратмый?

### Кыр кәҗәсе

Нишләтергә
Кәҗәбезне?
Аптыратты
Кәҗә безне.

Бер генә дә
Тыеп булмый,
Бер дә ябып
Куеп булмый.

Ача—кача,
Ача—кача,
Аптыратты
Кача-кача.

Ялан кырдан
Кайтып керми,
Куркыталмый
Аны берни!

Нигә куркак
Булсын, ди, ул?
Нидән куркып
Торсын, ди, ул?

Мин бит аның
Көчен беләм:
Кирәктә ул
Бүре белән

Сөзешергә
Хәтта әзер—
Кыр кәҗәсе
Бит ул хәзер!

### Мөгезсез бозау

Бабайларга авылга
Кайтсам җәен кунакка,
Дәү эти һәм дәү әни
Тукый минем колакка:

— Бозаудан сак бул!— диләр,—
Усал, сөзгәк ул!—диләр.

Күрдем инде мин аны:
Бозаулары—мөгезсез.
Мөгезсез ул беркемне
Сөзә алмый—күрерсез!

Белмиләрдер әле—мин
Үгездән дә өрекмим!

Чын баһадир кебек мин,
Чын матадор кебек мин!

Мин бит, әгәр теләсәм,
Үгезнең үзен егам!
Мин бит, әгәр теләсәм,
Үгезнең йөзен егам!

Мускулларны уйнатып
Киттем туры бозауга.
Алай бик усал икән,
Күрсәтербез без аңа!

Аннарымы? Аннары...
Дәвамы бик күңелсез:
Әлеге бозау мине
Сөзеп еккан... мөгезсез!

Авыртса да сөзгән төш,
Түзәргә була икән.
Теләсәң, мөгезсез дә
Сөзәргә була икән!

## Саттар дәү үскән!

— Мин ник бәләкәй
Түгелдер инде?
Бәләкәй чакта
Күңелле иде:

Күтәреп кенә
Йөртә идегез,
Борынымны да
Сөртә идегез.

Алмаш та тилмәш
Сөя идегез,
Саттар—зур малай,
Дия идегез.

Вәт әйбәт иде
Бәләкәй чаклар!—
Ди әнисенә
Биш яшьлек Саттар.

## Минем таныш автобусым

Яңгыр булсын,
Буран булсын,
Минем таныш
Автобусым
Тукталышта
Көтә мине.
Ишек ачып
Кертә мине,
Тирбәлдереп

Йөртә мине,
Мәктәпкә үк
Илтә мине—
Бигрәк якын
Итә мине.

Алып кайта
Аннан өйгә—
Әйбәт шул ул
Әллә нигә...

Җилдәй җитез,
Йөртә бик тиз
Минем таныш
Автобусым—
Ул бит минем
Авто-дусым!

## Энемне тирбәткәндә

Әни юкта, энемне гел
Тирбәтәм мин җай гына.
Елап та җибәрүе бар—
Аңа җиде ай гына.

Кичә дә әни кайтканчы
«Әлли-бәлли» иткәнмен,
Энем белән бергәләшеп
Эреп йоклап киткәнмен.

Әнинең кайтып җиткәнен
Йоклый-йоклый көткәнмен.

## Әкәмәт җанварлар

Белмим, ышанырсыз микән?—
Уйламыйм ялганларга:
Очрадым серле урманда
Әкәмәт җанварларга.

Урманга килеп керүгә
Үрә торды чәчләрем:
Ят җанварлар карап тора...
Каушасам да дәшмәдем.

Яши анда болантилопа—
Бу урманның ул күрке.
Яши тагын шимпанзебра,
Юлбарыслан, төлкерпе.

Күркәҗәләр, кәлтәкәләр
Чабып йөри аланда.
Мәчелән дә, чучкабан да—

Бар да, бар да бар анда.

Үзләре ят та, таныш та.
Таба алмыйм әйтер сүз...
Нинди җанвар алар?
Бәлки,
Сез үзегез әйтерсез?

## Качышлы уйнаганда

Бар да мине эзлиләр:
Янда гына гөжлиләр!
Тирә-якны таптыйлар,
Кая гына чапмыйлар,
Кая гына бакмыйлар,
Мине генә тапмыйлар...

Ә мин ятам тын гына,
Шыпырт кына, шым гына,
Көтеп ятам тик кенә—
Тапмыйлар соң ник кенә?!

Болытлар да каралды—
Төшә бугай караңгы.

Туңдыра да нигәдер,
Рәхәт урын—өйдәдер!

Була ла ул чыдарга,
Кирәк ләкин чыгарга!

Чыксам...
Кайтып киткәннәр,
Таралышып беткәннәр,
Мине мәзәк иткәннәр...

Итсәләр соң, итсеннәр,
Китсәләр соң, китсеннәр,
Шәп иттек, дип йөрсеннәр,
Рәхәтләнеп көлсеннәр,
Ләкин шуны белсеннәр:

Җиңдем мин—
Отылмадым,
Барыбер
Тотылмадым!
Вәт!

## Яздык

(*сүз уйнату*)

Әни белән
Алмаш-тилмәш
Без май **яздык**.
Әби белән
Оекбашка

Без йон **яздык**.
Яза-яза,
Яза-яза
Шундый ардык—
Шаярышып,
Уйнап алдык—
Тәнне **язды**к.
Ә аннары
Апабызга
Без хат **яздык**.
Абый белән
Матур итеп
Кат-кат **яздык**.

Аннан хатны
Без почтага
Салып кайттык.
Кайтып керсәк,
Кайтып күрсәк,
Шаклар каттык.

Ник дисезме?
Апа тора
Каршыбызда—
Абый белән
Ава **яздык**
Артыбызга.

Күтәрелеп
Карарга да
Чак-чак баздык.
Тик торабыз—
Икебез дә
Телдән **яздык**!

Яңа ел

Карлар ябалак-ябалак,
Көннәр-төннәр яңа, ак!
Бу Яңа ел—иң яңа ел,
Барсыннан да яңарак!

Тылсымлы икән Яңа ел—
Капкасыннан кергәч тә,
Кинәт кенә үсеп җиттек,
Үсеп киттек бер яшькә!

Тик Яңа ел бер үк елда
Булсын иде берничә.
Яңа елның берсенә дә
Калмас идек кермичә!

Яңа ел еш булса, күптән
Дәү кеше булыр идек,
Күбрәк «бишле» алыр идек,

Бик көчле булыр идек!

Хәер, җәй көне диңгезгә
Ялга киткән арада,
Әбиләргә, бабайларга
Ярдәм иткән арада,
Җәйләр үткән арада,
Кышлар көткән арада,

Сизми дә калырбыз әле—
Яңа елга җитәрбез,
Тагын бер яшькә үсәрбез,
Тагын бәйрәм итәрбез!

Алдагы ел белән тагын
Якыная арабыз.
Тиз килсен дип, Яңа елга
Без үзебез барабыз!

Теләсәгез, әйдәгез,
Без сезне дә алабыз!

## Тылсымлы таяк

Үзе карап торуга
Усал түгел әллә ни,
Ә шулай да... шулай да
Тылсымчы минем әби!

Бер таягы бар аның—
Бетерә бар арганын!

— Барсам да кая гына,
Таянам таягыма,
Таянсам, көч арта,—ди,—
Аттан шәбрәк тарта!—ди.

Беләм инде—шаярта.
Ул бит гап-гади таяк,
Миллион андый таяк.

Ул бернигә ярамый,
Селкенеп тә карамый.

Көлә генә әбием:
— Син атланып кара,—ди,—
Үзе алып бара!—ди.

Шулай дигәч әбием,
Атландым мин таякка—
Чабыйм икән кай якка?

Тыеп булмый атымны,
Атым уктай атылды:

Дулый—тузан туздыра,
Чын атны да уздыра!

Әй чаба ул, әй чаба,
Тими җиргә аягы...

Чынлап тылсымлы икән
Әбиемнең таягы!

Кәнфиткә алыштырган

Әлфит
Кәнфит яраткан, ди,
Тик сөймәгән тәнкыйтьне.
Ялт иттереп куя икән
Өстәлдәге кәнфитне!

Шуннан кәнфитләр җыелып,
Үзара киңәшкәннәр,
Әлфитне нишләтергә дип,
Бик озак сөйләшкәннәр:

— Әлфит нәфесен һаман да
Тыя алмый,—дигәннәр,—
Болай булса, Җир шарында
Кәнфит калмый!—дигәннәр.

Кәнфитләр сөйләшүдән соң
Кызык эшлиләр икән:
Әлфит кәнфит капса, аның
Тешен тешлиләр икән!

Әлфитнең яшереп кенә
Кәнфит кабуы була—
Әл-ләләлә... Ай-яйяйяй...
Тешсез калуы була!

Тешләренең сызлауларын
Берни дә басмаган, ди...
Ә берзаманны тешләре
Сызламый башлаган, ди.

Шунда гына Әлфитебез
Рәхәтләнеп көләлгән.
Әй сөенгән, әй сикергән
Һәм көзгегә төбәлгән.

Хикмәтнең нидә икәнен
Шунда гына аңлаган:
Авыртырга...
Авызында
Бер теше дә калмаган!

Шулай итеп, ул тешләрен
Алыштырган... кәнфиткә.
Әллә малай...
Әллә бабай...
Кем дип дәшик Әлфиткә?!

## Бакча белән хушлашу

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде күбебез.
Бакча белән хушлашабыз,
Бүген соңгы көнебез.

Тик елыйсы килә минем,
Инде ни хәл итәсе?—
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.

Тәрбияче апа елый...
Бу дөнья кызык кына:
Китәсе килми моннан да,
Мәктәп тә кызыктыра!

Күңелле дә, күңелсез дә...
Хәлемне белмиләр шул.
Китмәс идем, зур балалар
Бакчага йөрмиләр шул.

Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына.
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!

## Авырткан кебек кенә

Әллә нәрсә
Булды эчкә—
И авырта,
Түзәм көчкә.

Өйдәгеләр
Киңәштеләр,
Бик тиз генә
Врач дәштеләр...

Утыртты да
Бастырды ул,
Авызымны
Ачтырды ул.

Әйтте аннан
Күзгә карап:
«Синең, егет,
Эшләр харап!

Алдалыйсың
Син ни өчен?
Авыртмый бит
Синең эчең».

Доктор апа
Кызык итте:
Авыртулар

Бетте-китте!

Йөрим хәзер
Көлеп кенә.
Тик авырткан
Кебек кенә

Булган икән
Минем эчем—
Борчылмагыз
Минем өчен!

## Уйламый ярамый!

Мин йөрим
Урам буйлап,
Меӊ төрле
Уйлар уйлап!

Төрле-төрле-төрле уйлар
Ала мине бөтереп.
Уйлыйм-уйлыйм—
Уйлыйм-уйлыйм...
Булмый уйлап бетереп.

Тыя алмыйм уйларымны—
Уйлата да уйлата.
Минем башымда, ахрысы,
Йөз... меӊ төрле уй ята.

Уйлыйм мин уйнаганда да,
Уйлыйм йоклаганда да.
Уйламый да ятып карыйм—
Уйлаттыра анда да.

Беләм инде, уйлануныӊ
Сез дә кимен куймыйсыз!
Уйламый ярамыйдыр шул—
Ә сез ничек уйлыйсыз?

## Тәгәрмәчле яӊгыр

Минем абый—яӊгырчы!
Әй яӊгырчы,
Яӊгырчы,
Безгә тамчы
Тамдырчы!
Безгә яӊгыр
Яудырчы!

Абый яӊгыр тылсымын
Белә берүзе генә,
Яӊгыр яудырыр өчен
Җитә бер сүзе генә!

Шул тылсымлы бер сүзне

Әйтеп ташлавы була,
Яңгырның кинәт кенә
Ява башлавы була!

Берәр хикмәте бардыр—
Сиптерә генә яңгыр!
Кояшлы, җылы яңгыр!

Көтәсе юк болыт та,
Офыктан күз талдырып.
Телисе юк яңгыр да,
Бөтен эшне калдырып.

Торасы юк тыңлап та
Һава хәлен Казаннан.
Тыңласаң да, яңгыры
Яумый—файда аз аннан!

Күр әле, кара, кара:
Басудан яңгыр бара!
Үзе тәгәрәп бара,
Үзе сиптереп бара,
Кызык иттереп бара!

Безнең авыл яңгыры
Әй ява, ява кырга.
Ялынып тормый абый
Ерактагы яңгырга!

Безнең үз яңгырыбыз!
Кирәктә туктатырбыз,
Кирәктә яудырырбыз!

## Бабай кебек

Бабай әйтә: «Мин гел күрәм
Кояшның туганын,—ди,—
Кояш чыкканын күргәнгә
Бәхетле булганмын!»—ди.

Мин дә бабайга охшаган,
Соң торганым юк минем—
Кояш чыкканын карыйм да
Аннан... тагын йоклыймын!

## Мин кояшны яратам!

Утлар матур булса да,
Кояшка җитми инде.
Нурларын кояш кебек
Берсе дә сипми инде.

Безнең өчен балкый ул,
Безнең өчен гел яна.
Кояштан да җылы ут

Юктыр бөтен дөньяда!

Ялыкмыйбыз кояштан,
Кояш безгә гел кирәк!
Гел кояшлы җир белән
Гел кояшлы көн кирәк!

Алып килә ул безгә
Кояшлы таң, яңа таң...
Кояш мине ярата,
Мин кояшны яратам!

Күчтәнәч

Әбисенә барды Алмаз
Ияреп әнисенә.
— Күчтәнәчсез килдек,—диде
Әнисе әбисенә.

— Юк, юк, зур күчтәнәч белән
Килгәнсез!—диде әби.—
Менә бит күчтәнәч,—диеп
Алмазны сөйде әби...

Алмазның әнисе тагын
Күчтәнәчләр әзерли.
— Әбиләреңә кунакка
Барып кайтам хәзер,—ди.

Дәшә Алмаз әнисенә:
— Әни, әни, карале,
Күчтәнәч итеп бүген дә
Мине алып бар әле!

Йолдыз буласым килә

Кайчагында минем бик тә
Йолдыз буласым килә.
Күккә—йолдызлар янына
Менеп кунасым килә.

Мин йолдызга әйләнүнең
Хикмәтен әгәр белсәм,
Әкияттәге шикелле
Йолдызга әверелсәм,

Әнием төннәр буена
Һаваны күзләр иде,
Күпме йолдыз арасыннан
Гел мине эзләр иде...

Кайтып керсәм, әни башта
Аптырап калыр иде.
Танысачтын мине шундук
Кочаклап алыр иде.

Ә малайлар, уенчык дип,
Уйнарлар иде бугай.
Уйнамасам, усаллары
Кыйнарлар иде бугай.

Кыйнасалар, тыелалмам—
Минем еласым килер.
Шуннан соң минем яңадан
Үзем буласым килер!

## Песнәк белән сөйләшү

И песнәгем, белеп торам,
Күреп торам—туңгансың.
Соң син бит безнең балконга
Җылы эзләп кунгансың.

Йоннарыңны кабарткансың,
Калтырыйсың—күр инде.
Җылыда җырлавы рәхәт—
Әйдә, безгә кер инде!

Югыйсә елап җибәрәм,
Торма инде салкында.
Кермәсәң безгә хәзер үк,
Үзем чыгам балконга.

Син туңсаң, мин дә туңармын.
Туңсам, белерсең әле...
Салкында торып авырсам,
Елап йөрерсең әле!

## Елмаючы... бүреләр

Ясадым мин дәфтәремә
Бүренең би-ик явызын:
Озы-ын иттердем тешләрен,
Зу-ур иттердем авызын...

Шуннан соң ул миңа таба
Карап тора башлады.
Курыктым да, бүрене мин
Тизрәк ертып ташладым.

Юкса нишли дип торам,
Мине тешли дип торам.

Бүреләрне усал итеп
Ясамам мин моннан соң—
Бүреләр ямьсез булса да,
Усал, явыз булмасын!

Мин ясаган бүреләр гел
Әйбәт кенә булырлар,
Тыйнак кына утырырлар,

Елмаешып торырлар.

Безгә килгәч, рәсемемне
Дусларым да күрерләр.
Ошамый калмас аларга
Елмаючы... бүреләр!

## Хәйләкәр малай

Берәр мутлык эшләдисәм,
Әни миңа: «Төлке!»—ди.
Өсти аннан: «Төлкедән дә
Хәйләкәр син түлке!»—ди.

Чыннан да, минем үземдә
Хәйләкәрлек җитәрлек,
Кирәк булса, ул төлкенең
Үзен кызык итәрлек!

Мине белсә, ул үзе дә
Сокланып туймас иде.
Минем алда берәүне дә
Алдарга кыймас иде.

Үзенең бөтен мутлыгын
Гел миңа өяр иде.
Улына: «Син Алмаз кебек
Хәйләкәр»,—дияр иде.

Менә шулай хәйләләргә
Булдыралам мин генә...
Әй лә, ышана күрмәгез,
Юри хәйләлим генә!

## Акбай шулай ди...

Акбай белән без — бик дуслар.
Мин аның телен беләм.
Ул үзе дә нәкъ кешечә
Сөйләшә минем белән.

Ул миннән берни яшерми:
Сиңа бер сер сөйлим, ди.
Мин бит безнең урамдагы
Малайларны сөймим, ди.

Урамга да чыгып булмый,
Мине рәнҗетәләр, ди.
Йә миңа таш аталар, ди,
Йә үртәп үтәләр, ди.

Үртәсеннәр әле, әйдә,
Мин әлегә түзәм, ди.
Әгәр тагын үртәсәләр,
Чабуларын өзәм, ди.

Анда да туктамасалар,
Аякларын тешлим, ди.
Алар миңа нишләсәләр,
Мин дә шуны эшлим, ди.

Урамга да чыгармыйм, ди,
Тагын усаллансагыз!..
Әнә үзеннән сорагыз,
Әгәр ышанмасагыз!

Урман аша узганда

Сызгырына-сызгырына
Урманнан китеп барам.
Урман—серле!
Берәр төрле
Маҗара көтеп барам.

Дөрес, монда җәнлекләрнең
Булуы бик икеле,
Ләкин каршыга Шүрәле
Килеп чыгар шикелле.

Кинәт килеп чыккач, бераз
Куркыныч булыр иде.
Тик сер биреп тормас идем—
Бик тыныч булыр идем.

Шүрәлегә: «Мин — Былтырның
Энесе»,—дияр идем.
«Шулаймыни?!
Исәнме!»—дип,
Ул башын ияр иде.

«Җибәрче, батыр егет!»—дип
Елап та алыр иде.
Җибәргәчтен, рәхмәт әйтеп,
Кул болгап калыр иде...

Тик минем шүрләмәгәннән
Шүрләгәнгә күрәме,
Әллә үзе шундый куркак—
Күренмәде Шүрәле.

Күпме генә карасам да,
Күренмәде барыбер.
Күренмәгәч, сөенечтән
Карап куйдым тагы бер.

Булса да миндә батырлык,
Булса да миндә гайрәт,
Шүрәлене берьялгызым
Күрмәвем дә бик әйбәт!

Ышансагыз да урманда
Берүзем йөрүемә,

Ышанмас идегез әле
Шүрәле күрүемә!

## Акбайга

Йөрмә, Акбай, безнең янда,
Йә тешләрсең, кит әле!
Песиебезгә дә өрмә—
Ул бәләкәй бит әле.

Юлбарыска охшаган ул
Безнең песи баласы.
Чынлап юлбарыс булган, ди,
Аның ерак бабасы!

Ул да үскәчтен юлбарыс
Булыр әле—күрерсең.
Алай бик батыр икәнсең—
Менә шунда өрерсең!

## Кояш белән узышу

Кояш белән узышабыз—
Мин чабам,
Ул да чаба.
Ул узалмый,
Мин узалмыйм—
Икебез дә бер чама!

Яндык-пештек,
Арып беттек—
Мин калмыйм,
Ул да калмый,
Узып та
Китә алмый...

Тик кояш
Кызык итте—
Болытка
Кереп китте.

Ә үзе болыт артыннан
Көлгән була, җитмәсә...
Уза идем мин кояшны,
Әгәр кереп китмәсә!

## Без абыйны озаттык

Абыем еракка—
Артекка китәчәк.
Озакка—айдан да
Артыкка китәчәк.

Абыйның киткәнен
Акбай да аңлаган—

Озата килгәндә
Артымнан калмаган.

Абыйга карый да
Карый ул нигәдер.
Мөгаен, Артекка
Барасы киләдер...

Биредә абыйсыз
Килсә дә кыенга,
Артекка ук барып
Булмастыр быелга.

Иртәрәк шул безгә—
Алып та бармаслар.
Аз гына үскәчтен
Җибәрми калмаслар...

Поезд да кузгалды.
Кул болгап калдым мин,
Поездның артыннан
Йөгереп бардым мин.

Акбай да калмады,
Аптырап тормады—
«Сау бул!» дип, абыйга
Койрыгын болгады.

Кураем

Тылсымлы минем кураем—
Эче тулы көй генә.
Бакчаларга чыгып уйныйм,
Җитми миңа өй генә!

Гади генә инде үзе,
Уемы бар берничә.
Көй чыкмый—шул уемнарга
Баса-баса өрмичә.

Ә малайлар кызыгалар,
Малайлар аптырыйлар.
Уемнарын да саныйлар,
Тотып-тотып карыйлар.

Берәм-берәм дә карыйлар,
Бергәләп тә карыйлар.
Аптырагач, бәргәләп тә,
Өргәләп тә карыйлар.

Алар кулында нигәдер
Кураем һич уйнамый.
Өрсәләр, сызгыра гына,
Уйнарга да уйламый.

Ә мин уйнасам, көйләрне
Тотып та тыеп булмый.
Бер башласам, ул көйләрне
Уйнап та туеп булмый.

Кураемны яратам мин
Менә шуның өчен дә.…
Мин белгән бөтен көйләр дә
Бар бит аның эчендә!

## Урамнан фил китеп бара

Урамнан фил китеп бара,
Урамнан фил үтеп бара.
Барсы да аптырыйлар,
Гаҗәпләнеп карыйлар.

Каян килгән, ничек килгән,
Кайчан килгән ул, диләр.
Безнең Казанга килергә
Ничек белгән ул, диләр.

Фил янында кешеләр дә,
Трамвайлар да кечкенә.
Ничек шулай үсә алган?—
Аңлап булмый һич кенә.

Ә фил бер дә гаҗәпләнми:
Каранып ары-бире,
Казан урамнары буйлап
Бара да бара бирә...

Казан циркына барырга
Чыккан икән филебез.
Фил күрергә теләсәгез,
Сез циркка килегез!

Без барып тормыйбыз инде—
Әле яңа таралдык,
Циркны билетсыз гына
Без урамда карадык!

## Мине дә күрәләрдер

Без яши торган биек йорт
Казанның иң түрендә.
Балконыннан карап торсаң,
Бөтен дөнья күренә.

Иделдәге теплоходлар,
Юллар,
Өйләр күренә.
Цирк,
Кремль,
Яшел поезд—
Әллә ниләр күренә...

Моннан
Иң биектә янган
Йолдызлар да күренә.

Алар бик тә якын кебек—
Куллар шунда үреләә!

Йолдызлар күз кыса миңа—
Алар да күрәләрдер.
Мөгаен, мине күргәнгә
Шатланып көләләрдер!

Елның дүрт төсе

**Ак кыш**

Яратам мин
Ап-ак төсне.
Бөтен дөнья
Ап-ак төсле—

Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.

Биек булып, ап-ак булып,
Урамга ак кар яуган.
Көне буе шау-гөр килеп
Шуабыз шул ак таудан.

Шундый якты, шундый нурлы
Бөтен дөнья ак кына...
Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына!

**Зәңгәр яз**

Яратам мин
Зәңгәр төсне.
Бөтен дөнья
Зәңгәр төсле—

Басулар, кырлар, үзәннәр
Зәңгәр кардан арчыла,
Челтәрләнеп-челтәрләнеп
Җирдән зәңгәр пар чыга.

Зәңгәр елгалардан әнә
Зәңгәр бозлар агыла,
Зәңгәрләнеп ага алар
Зәңгәр Идел ягына.

Зәңгәре күчә күзләргә—
Күккә карап ят кына...
Зәңгәр була белә шулай
Безнең туган як кына!

**Яшел җәй**

Яратам мин
Яшел төсне.

Бөтен дөнья
Яшел төсле—

Бу яшеллек патшалыгы
Әкияткә тиң бүген.
Дәфтәргә яшел кояш та
Ясап куйдым мин бүген.

Дөнья яшел микән әллә
Яшел яңгыр яуганга,
Урман-кырларны ямь-яшел
Тамчы белән юганга?

Яшел дулкын чаба кырда,
Җил иссә дә чак кына...
Яшел була белә шулай
Безнең туган як кына!

**Сары көз**

Яратам мин
Сары төсне.
Бөтен дөнья
Сары төсле—

Кыздырасы килми бер дә—
Кояш та сабырланган.
Сабыр булганга микәнни
Кояш та сарыланган.

Арыш, бодай бөртекләре
Кояш белән бер төстә.
Сары белән буялмыйча
Калмагандыр бер төш тә.

Саргайган яфраклар җиргә
Сарылалар сак кына...
Сары була белә шулай
Безнең туган як кына!

Курыкмыйбыз!

Шуабыз иң биек таудан,
Юк, шумыйбыз—очабыз!
Очкан чакта ак карларны,
Ак җилләрне кочабыз!

Без шуганда, бөтерелеп,
Бураннар чыгып кала.
Кайберебез ярты юлда
Көрткә дә чумып кала!

Тауга менгәндә дә менә
Шуып менәсе иде,
Шуып менүнең хикмәтен,
Серен беләсе иде.

Җиңел түгел бит менүе

Шундый текә түбәгә,
Баш әйләнә башлый хәтта,
Карап торсаң түбәнгә.

Төшүе дә җиңел түгел,
Ә шулай да шуабыз.
Куркуны без үзебездән
Еракка ук куабыз!

Таудан төшкәндә ул үзе
Чанадан төшеп кала.
Бик биек шул!
Мондый таудан
Курыкмый төшеп кара!

Туган илнең улы мин!

Бабайның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин —
Аларның уң
Кулы мин!

Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын—
Бернигә дә
Карамый.
Шулай булмый
Ярамый!—

Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

Акбай цирк карый

**Аюлар**

Әйбәтләп аңлатып бирсәң,
Әйбәтләп куштың исә,
Чаж да чож да, чаж да чож —
Аюлар утын кисә.

Әмма утын кискән өчен
Сөт эчертергә кирәк.

Эш җиңел түгел, янәсе:
Сөт—көч кертергә кирәк!

Ай-яй иркә өйрәнгәннәр—
Кара инде нишлиләр?!
Сөт бирсәң, утын кисәләр,
Сөт бирмәсәң, кисмиләр!

**Зебра**

Зебраны күргәч, Акбаем
Чак артыннан чапмады.
Көчкә тыйдым!
Чабар да ул—
Була андый чаклары.

Мондый буйлы-буйлы атны
Күргәне юк шул аның,
Мондый атка бер тапкыр да
Өргәне юк шул аның.

Өрер иде дә, зебра бит
Әйләнеп тә карамый.
Аннары кеше күп җирдә
Өрергә дә ярамый!

**Маэмай**

Бер маэмай чабып чыкты,
Баш иде безгә карап.
Әллә кем диярсең—үзен
Тотышы ай-яй харап.

Божрадан сикерә белә,
Ике аяклап йөри.
Акбай гына күрмәмешкә
Салынган була юри.

Әллә маэмайның тотышы
Аңа бер дә ошамый,
Әллә артист-маэмайның
Этлегенә ышанмый.

Барыбер Акбай түзмәде,
Күргәч аның биюен.
Шыңшып куйды.
Бу—мине дә
Шулай өйрәт, дию.

Әнә бит ничек ялварып
Утыра ул теземдә.
Бик өйрәтер идем, Акбай,
Бии белмим үзем дә!

**Бегемот**

Бегемот чыкты да безгә
Аптырап карап тора.
Янәсе, басып торсаң да

Әлегә ярап тора.

Курыкма син, Акбай, аннан,
Ялкау бит ул—тешләми.
Үзең усаллык кылмасаң,
Бернәрсә дә эшләми.

Бигрәк иренчәк тә инде—
Ашыкмас ул һичкайчан.
Әнә бит—баядан бирле
Селкенми дә ичмасам!

Әйтерсең лә береккән ул
Басып торган җиренә—
Шул басып торган җиренә
Ятарга да иренә.

Акбайның гаҗәпләнүе
Чыккан хәтта йөзенә.
Мин андый ялкау түгел дип,
Карап тора күземә.

Яз булмас микәнни?

Шәһәргә кар явып тора,
Абыйлар ташып тора.
Ник ташыйлар икән дип, мин
Аптырап басып торам.

Болай булгач, гөрләвеккә
Карлар да калмас инде.
Гөрләвекләр гөрләмәгәч,
Яз була алмас инде!

Җиңел җилләр,
җитез җилләр...

Җилфер-җилфер итә җилләр,
Күренми күзебезгә.
Битебезгә тиеп үтә—
Күренми үзе безгә.

Ишетеп кенә була шул,
Җилләрне күреп булмый.
Җилләрне күреп булмагач,
Җитәкләп йөреп булмый.

Ә шулай да җилләр белән
Шаярып, уйнап була.
Чөнки җилләр наян була,
Җилләр бик уйнак була.

Уйнак җилләр кайчагында
Усал да була ала—
Чәчләрне тузгыта ала,
Куенга тула ала...

Җиңел җилләр,
Җиләс җилләр,
Җитез җилләр,
Исегез!
Шат хәбәрләр китерегез,
Илләр, җирләр кичегез!

Йомшак җилләр,
Ефәк җилләр,
Җилдерегез,
Җилегез!
Еракларга очыгыз сез—
Иксез-чиксез илебез!

Яшел җилләр,
Зәңгәр җилләр,
Гел исегез,
Тынмагыз!
Җырлагыз сез!
Без дә сезнең
Җырыгызны тыңларбыз!
Кушылып та җырларбыз!

## Кеше карап тормагач

Абындым да мин бер төпкә,
Авырттырдым теземне.
Берәү булса түзмәс иде,
Ярый үзем түземле!

И сызланам! Әмма миндә
Берәүнең дә эше юк.
Кычкырып бер елар идем—
Янымда бер кеше юк.

Шул бер төп минем теземне
Авырттырган дип инде,
Беркем карап тормаганда
Елап тормам бит инде!

## Яңгыр шундый буламы?

Безнең авыл яңгырларын
Күргәнегез юк әле,
Яңгырдан соң яланаяк
Йөргәнегез юк әле.

Бездәге күлдәвекләргә
Муеннан батып була,
Батыр булсаң,
Баткан килеш
Өйгә дә кайтып була!

Ә шәһәрдә
Яңгыр күпме

Көттерде-
Көттерде дә,
Яугандай
Иттерде дә,
Әз генә
Сиптерде дә,
Шунда ук
Киптерде дә.

Яңгыр шундый
Буламы?—
Әле генә яуган иде—
Киптергән дә урамны!

## Агыйнеш

Уйный-уйный ага инеш,
Агыйнеш тә арыйдыр.
Аз булса да туктап торып,
Ял итсә дә ярыйдыр.

Әллә арый белми микән?
Юкса ял итәр иде.
Туктап ял итәр иде дә
Яңадан китәр иде.

Болай булгач, агыйнешнең
Бөтенләй калмас хәле.
Үскәч, елгага әйләнгәч,
Армыйча калмас әле.

Ә хәзер безнең шикелле
Көн дә чаба, уйный ул.
Диңгезгә беренче барып
Җитәм диеп уйлый ул!

## Балачак бәйрәмнәре

Бәйрәмсез бик күңелсез бит—
Күңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,
Кирәк һәммәбезгә дә!
Бәйрәмнәр кирәк әтигә,
Бәйрәмнәр кирәк әнигә,
Бабай белән әбигә!

Бәйрәмнәр бетмәс бер чак та,
Балачаклар бар чакта.
Зур бәйрәм—«бишле» алсак та,
Кырларда эшләп арсак та,
Зоопаркка барсак та!
Зур бәйрәм—җырлап алсак та,
Җәйге кояшта янсак та,
Походларга барсак та!

Бәйрәмнәр бездә җитәрлек.
Үзе бәйрәм—балачак!
Балачакның шат җырлары,
Балачакның шат еллары
Мәңге истә калачак!
Бәйрәмнәр бик күп болай да,
Ә шулай да, ә шулай да
Иң шәп бәйрәм—балачак!

## Яңгыр җыры

1
Яңгыркаем, тук-та!
Явасың бит юк-ка!
Тукта инде тот та!
Кайт та ятып йок-ла!

Игенче абыйларга
Кырга барырга кирәк!
Үстерелгән икмәкне
Җыеп алырга кирәк—
Безгә ипекәй кирәк!

Яңгыркаем,
Тук-та!
Кайт та ятып
Йок-ла!

2
Яңгыркаем, яу, яу!
Әйбәт түгел яумау!
Кырлар шундый коры—
Яу шуларга туры!

Явасың бит бик сирәк,
Ә кырга яңгыр кирәк!
Әй лә, әй, болыт бабай,
Яңгырны яудыр тизрәк!
Безгә ипекәй кирәк!

Яңгыркаем,
Яу, яу!
Әйбәт түгел
Яу-мау!

## Иписез табын...

Боткасының да тәме юк,
Ашының да тәме юк.

Хәтта чәйнең дә тәме юк,
Табынның да яме юк.

Ә табында ни генә юк?!—
Бары ипи генә юк!

## Игенчеләр гаиләсе

Әти ипи
Үстерә,
Әни ипи
Пешерә.
Ә мин... ипекәй
Ашыйм.
Ә аннары
Ипине
Үзем үстерә
Башлыйм!

## Сабантуй бүген бездә!

Шатлыклар—күңелебездә,
Ал кояш—күгебездә!
Килегез, дуслар, кунакка—
Сабантуй бүген бездә!

Иң уртага утырткannar
Иң озын бер колганы—
Колганың да бик тиз генә
Менеп булмый торганы.

Җиңгиләр биреп җибәргән
Бизәкле бүләкләрен,
Ә малайлар көрәшергә
Сызганган беләкләрен!

Ә кызлар киеп чыкканнар
Иң матур күлмәкләрен.
Латыйп бабай төяп килгән
Иң ныклы чүлмәкләрен.

Абыйлар алып килгәннәр
Иң җитез юртакларын.
Гармунчылар алып чыккан
Җырларның уртакларын.

Җилферди чиккән сөлгеләр!
Бүләкләр—күбебезгә!
Көрәшик тә, узышыйк та—
Сабантуй бүген бездә!

## Тәкә

Аптыратып авылны,
Сабантуйдан кайта Нур.
Сабантуйдан зур бүләк—
Тәкә алып кайта ул!

Нур куанган,
Сөенгән—
Борын күккә

Чөелгән!

Кайта ул горур гына!
Кайта тәкәббер генә!
Кайтыр да шул—
Дөньяда
Андый тәкә бер генә!

Малайлар көнләшәләр,
Ә кызлар серләшәләр,
Нидер чөкердәшәләр,
Нурга карап:
«Исәнме,
Әй батыр!»—дип дәшәләр.

Нур үзе дә үз-үзен
Батырга исәпләгән—
Чөнки абыйсы алган
Тәкәне җитәкләгән!

## Кулъяулык

Бар да бүләк алалар:
Йөгереп тә алалар,
Көлдереп тә алалар,

Аяк чалып алалар,
Атта чабып алалар...

Тик мин генә бер читтә
Нишләргә дә белмәдем:
Көрәшкә дә кермәдем,
Колгага да менмәдем,

Капчык белән
Сугышып карамадым,
Узышып карамадым,
Уйлап та карамадым.

Аркан да
Тартышмадым—
Бернигә
Катышмадым...

Мин чүлмәк ватучылар
Янында басып тордым.
Алар чүлмәк ваттылар,
Мин чүлмәк ташып тордым.

Хәтта бүләк әләкте!
Әй сөенә-сөенә
Алып кайттым
Бүләкне.

Апам чиккән
Кулъяулык

Булып чыкты
Ул яулык!..

Тик апам
Мактамады,
Тамчы да
Шатланмады.

Белмим инде, нигәдер?
Бәлки, мин ул бүләккә
Лаек түгел дигәндер?

Дисә дә түзәм инде.
Ә шулай да сәбәбен
Барыбер сизәм инде!

Ник яшергән буладыр?
Сер яшереп буламы?—

Күрше абый алыр дип
Чиккән булган ул аны!

Энем арттан иярә!

Белмим,
Нәрсә дияргә?—
Энем
Арттан иярә!

Ярар иде бит инде
Сабантуйда булса да,
Өйдә торып торса да!

Ә мин тиеш хәзер үк
Катнашырга ярышта—
Ә ул калмый
Карыш та!

Хәзер киләм, дип карыйм,
Кәнфит бирәм, дип карыйм,
Карыймын алдашып та,
Карыймын аңлатып та.

Аңламагач,
Аңламый!
Тыңламагач,
Тыңламый!

Калмый миннән
Тотам да!
Болай булмый—
Барыбер
Ярышам мин тотам да!

Бөтен эшне
Ташладым—
Йөгерешчелер белән
Йөгерешә башладым!

Энем дә арттан чаба—
Нәкъ менә бала-чага!
Ничауа, арыр әле,
Үзе дә калыр әле!

Туктарга һич ярамый—
Чабам артка карамый!

Әйтерсең лә мин атта!
Башкалар калды артта.

Тик энем арттан калмый,
Ул гына армый-талмый...

Күзләрен
Уып килә!
Артымнан
Куып килә!
Икенче
Булып килә!

Әй йөгерәм, әй чабам—
Каралды күз аллары.
Алдан килдем!
Ул мине
Барыбер узалмады!

## Чүлмәк вату

Абыйлар һәм апалар
Кызып чүлмәк ваталар!

Сызганыла беләкләр!
Челпәрәмә килергә
Чират тора чүлмәкләр.
Ә колгада—
Бүләкләр!

Тик апалар, абыйлар
Чүлмәк вата алмыйлар:

Хәйләләшеп карыйлар,
Хәрәмләшеп карыйлар,

Чүлмәкнең кайдалыгын
Белергә тырышалар,
Күрергә тырышалар.

Әллә начар урыны?
Әллә чүлмәк ырымлы?—
Ватылмый да ватылмый,
Ваттырмый да ваттырмый!

Ватылмасын иде дип,
Алмаз да теләп тора.
Ә өстә, кызыктырып,
Бер кочак бүләк тора!

Алмаз бик чыгар иде,
Бер генә сугар иде!

Шуңа да ул мәйданга
Бер керә дә бер чыга.
Ләкин сукса, чүлмәкне
Ватармын дип борчыла...

Ә абыйлар,
Апалар
Һаман чүлмәк
Ваталар!

## Әтәчле сәгать

Минем әби нишләптер
Будильникка уянмый.
«Чыр-чыр-чыр-чыр» килсә дә,
Уяныргa уйламый.

Ул һаман авылдагы
Әтәчләрен сагына.
Уяна ул бары тик
Әтәч кычкырса гына.

Их, әтәч булса әгәр,
Булыр иде бик ансат...
Әтәч тавышлы сәгать
Булмый микәнни ясап?

## Малайлар сөйләшә

— Мин үскәч абый булам,
Аннары бабай булам!
— Ә мин бабай булгач та
Гел әйбәт малай булам!
— Мин үзем эти булам!
— Ә мин дәү эти булам!
— Үскәч кем буласымны
Мин әле әйтми торам!
— Мин батыр солдат булам!
— Ә мин космонавт булам!
— Ә мин Третьяк булам,
Капкада сакта торам!
— Ә мин корыч коючы,
Чуен коючы булам!
— Мин күз буучы булам!
— Ә мин аучы булам да
Көн дә йөрим сунарга!
— Ә мин белмим, әнидән
Онытканмын сорарга.
— Ә мин бик озын булам,
Үсәм әле тагы да!
— Ә мин начальник булам,

Йөрим «Волга»да гына!
— Ә мин кибетче булам
Яисә итче булам!
— Ә мин бик көчле булам,
Әтием төсле булам!
— Мин комбайнчы булам,
Кырда иген урырга!
— Ә миңа әни, үскәч,
Куша Кеше булырга!

## Хәрефләр буталганда

(*сүз уйнату*)

Башка малайлар кебек
Алмаз да укый белә,
Тик кайбер хәрефләрне
Аз гына бутый менә.

Шуңа күрә кайчакта
Сүзләрне дә бозгалый,
Хәрефләрнең урынын
Буташтырып узгалый.
Алыштырып та укый,
Ялгыштырып та укый:

— Безнең бозау боз ялый!
Юк ла, тозау боз ялый!
Әй лә, тозау тоз ялый!
Әй лә, юк ла, түгел лә,
Безнең бозау тоз ялый!

Алмаз белән еш кына
Шундый хәлләр булгалый:
Кайчак ул хәрефләрнең
Урыннарын тозгалый!

## Бик әйбәт минем эшләр!

Сез торасыз да сорыйсыз:
«Эшләр ничек бара соң?»
Ничек барсын?
Әйбәт бара!
Әйбәт бармый карасын!

Тик укытучы гына менә
Куйды бүген «икеле»—
Берне түгел,
Икене!
Әни бәлки ачуланмас?
Юк шул, белмим, икеле!

Кичә хоккей уйнаганда
Ертып кайттым күлмәкне.
Шул күлмәк өчен дә әле
Әниемнән эләкте!

Ә кичә песи өстенә
Түктем ялгыш ашымны.
Энем белән шаярганда
Тишә яздым башымны.

Аннары бозау чәйнәгән
Өр-яңа дәреслекне.
Кем кушкан аңа чәйнәргә?
Йә, шушы дөреслекме?

Әллә кәнфит ашаганга
Сызларга итә тешләр...
Шуларны чутламаганда,
Бик әйбәт минем эшләр!

Чыршы әйләнәсендә

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч, булачак
Котлаулар да, бүләк тә!
Яңа елда чынга ашар
Безнең бөтен теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!

Рәхмәт сиңа да, иске ел!
Матур ел булдың бит син.
Синнән алган бәхет-шатлык
Гомер буена җитсен!

Әти төсле!

Әти бик тә кыюсыз,
Бик бәләкәй һәм чандыр
Малай булган
Кайчандыр.

Соңга да калгалаган,
Шелтә дә алгалаган.

Бик яраткан уйнарга.
Кайда гына йөрмәгән,
Өйгә кайтып
Кермәгән!

Бик соң торган
Йокыдан,
Чөнки төннәр буена
Качып китап укыган.

Бервакытны тарихтан
Алган ул хәтта «өчле»...
Мин дә нәкъ
Әти төсле!

Рәхәт минем әтигә—
Бар исеме, бар даны!
«Кешелекле кеше!» дип
Мактыйлар бар да аны.

Минем әти мактаулы
Үзенең эшендә дә—
Өр-яңа орден балкый
Әтинең түшендә дә!

Гел әйбәт сүзләр йөри
Әтиемә карата.
Аны бар да хөрмәтли,
Аны бар да ярата.

Ул — Сабантуй батыры!
Ул—гайрәтле!
Ул—көчле!
Мин дә нәкъ
Әти төсле!

Мин — укучы әтисе!

Һич мактанып әйтмимен:
Улым укучы минем!

Әйбәт укый—
Тырышса!
Өй ялт итә—
Булышса!

Яратабыз—
Тыңласа,
Әйбәт—
Ялкау булмаса,
Киреләнеп
Тормаса...

Кирәк хәзер миңа да
Әйбәт кенә булырга:
Вакытында ятарга,
Иртән иртүк торырга!

Эшкә соңлап
Бармаска!
Кисәтүләр

Алмаска!

Бар көчкә
Тырышырга!
Өйдә дә
Булышырга!

Кибеткә дә
Барырга!
Тышта утын
Ярырга!

Кирәк икән, була ул!
Барсына да әзер мин!
Ни дисәң дә, укучы
Әтисе бит хәзер мин!

## Аяк тая тайгакта

(*сүз уйнату*)

Тая
Аяк,
Кая
Таяк?

Таяк
Кулда,
Көчсез
Ул да!

Бозы
Шома,
Тая
Шуңа,
Шуа
Шуңа.

Аяк,
Шума!
Юк шул,
Шуа!

Ярдәм
Итми
Бер та-
як та,
Ике
Таяк,
Дүрт та-
як та.

Йөрим
Шуңа
Дүрт
Аякта
Тай-

гак-
та!

Икесе дә мин үзем!

Вакыт табам мин көн дә
Шаярырга, уйнарга.
Кайчак, ташлап эшемне,
Чумам төрле уйларга.

Өлгерәм тик йөрергә,
Су керергә инештә.
Әнием бик ярата
Мине шушы килеш тә!

Кайчак әни эш кушса,
Елыйсы килә минем.
Килә шул!
Ни дисәң дә,
Төпчеге мин әнинең!

Әмма миңа таяна
Әнием һәр эшендә.
Ярата бит ул мине
Менә шуның өчен дә.

Ни кушса да мин аңа
Ярдәм итәргә әзер—
Теләсә нинди эшне
Эшли алам мин хәзер.

Әнигә ярдәм кирәк!
Ярдәм итмәс тә идем,
Ни дисәң дә, мин әле
Олы улы әнинең!—

Бердәнбере
Әнинең!

Арыган...

Хәлим бүген өйләренә
Кайтып керде кичкә генә.
Кайтып керде
Аякларын
Сөйри-сөйри көчкә генә.

Керегезче,
Күрегезче:
Ул бөтенләй хәлдән тайган.
Арыганын, алҗыганын
Белеп була әллә кайдан.

Әйтерсең лә көне буе
Күмер чапкан ул шахтада.
Әйтерсең лә көне буе

Басып торган ул вахтада.

Әйтерсең лә көне буе
Су ташыган чишмәдән ул.
Әйтерсең лә утын ярган,
Әлләниләр эшләгән ул...

Эшләмәсә, егет кеше
Шушы кадәр арыймы соң?
Көннәр буе бертуктаусыз
Эш эшләргә ярыймы соң?

Арымас иде дә Хәлим,
Яман эшкә тарыган ул:
Эшләгәнгә арымаган,
Эшсезлектән арыган ул!

## Кыш бабайны көткәндә

Яңа ел җитә инде,
Кыш узып китә инде!

Кышның эшләре яман—
Кар яумый бит, әй, һаман!

Кайда соң син, Кыш бабай?
Син, ахры, Яңгыр бабай.
Яңгырыңны яудырма,
Карыңны яудыр, бабай!

Кар күрергә зар булып,
Өйдә әнә тун, толып,
Бүрек һәм киез ката
Боегып эшсез ята.

Алыштырды ап-акка
Соры тунын куян да.
Төлкедән дә качалмый—
Күренә ул каян да.

Уҗымнарга юрган юк,
Чаналарга юллар юк.

Безнең болай тик яту
Сузылды бик күпкә дип,
Чаңгылар һәм чаналар
Сиңа бик нык үпкәли!

Чыннан да, ул чаңгылар
Түгел бит су чаңгысы.
Чыннан да, ул чаналар
Түгел бит су чанасы.

Аларның да киләдер
Кышкы юлдан чабасы!
Юкмы соң бер чарасы?!

Юкса алар төньякка,

Ап-ак карлар күп якка
Качып бетәрләр әле,
Бүрекләр дә, туннар да
Качып китәрләр әле!

Аларга да эш кирәк!
Аларга да кыш кирәк!

Их Кыш бабай,
Кыш бабай!
Менә шундый хәлләр бит.
Кайда соң син, хәбәр ит!

Килмәсәң, без үзебез
Сине барып алабыз.
Югыйсә барыбыз да
Яңа елсыз калабыз!

## Беркем узып китәлми!

Әй шуам мин чаңгыда!
Әй шуам мин—җилмени!
Минем кебек малайлар
Ярышларда җиңелми!

Югыйсә кичәгенәк
Көлгән булдылар миннән.
Имештер, ярышканда
Мин иң ахырдан килгән.

Әйдә, миннән кем көлә,
Бер карап торсын менә!

Мине бүген ярышта
Беркем куып җитәлми!
Мине бүген ярышта
Беркем узып китәлми!

Тиз-тиз барам-барам да,
Аз гына хәл алам да,
Рәхәтләнеп шуам мин
Берүзем бер яланда!

## Үзебез генә калгач

Абый укуга китте,
Әтиләр эшкә китте,
Кайтам, дип, төшкә тикле,
Әби кибеткә китте,
Кибеткә—иткә китте.
Мәчебез ауга китте...

Ә өйдә...
Гауга китте:

Булат белән икебез

Сугышып туялмыйбыз,
Беребезне беребез
Берничек тыялмыйбыз!
Икебез бит, икебез
Бер өйгә сыялмыйбыз...

Ә кич белән һәммәсе
Җыелды өебезгә.
Нишлиек,
Хәзер без дә
Кайттык үз хәлебезгә.

Булат белән икебез
Гаҗәпләнеп куябыз:
Икәү сыймаган өйгә
Бөтенебез сыябыз!

Телевизор...
тыңлыйбыз

Телевизорыбызның
Никтер бер дә рәте юк—
Тавышы да бер дигән,
Тик менә сурәте юк.

Күрсәтә иде башта,
Күрсәтми инде башка!

Алай итеп карадык,
Болай итеп карадык,
Якын килеп карадык,
Ерак китеп карадык,
Тик төзәтә алмадык.

Их, күрсәтсә, әлбәттә,
Яхшырак булыр иде.
Бер белгән кеше булса,
Бер генә борыр иде!

Без төзәтә белмибез.
Белмибез лә берни без!

Шуңа хәзер без аның
Бер җирен дә бормыйбыз,
Нишләтергә икән дип,
Бер план да кормыйбыз.

Аптырап та тормыйбыз:
Җыйнаулашып һәммәбез
Телевизор тыңлыйбыз!

Мультфильмнар тыңлыйбыз,
Киносын да тыңлыйбыз,
Хоккеен да тыңлыйбыз,
Футболын да тыңлыйбыз...

Без барын да тыңлыйбыз—

Күрсәтми дип тормыйбыз,
Төсле телевизорны
Рәхәтләнеп тыңлыйбыз!

Ишекне дә тыңлыйбыз—
Мастер килергә тиеш!
Вәт ул белергә тиеш!

## Рәсем

Куеп бөтен көчемне,
Калдырып бар эшемне,
Рәсем ясыйм!
Әллә мин
Ясамаслык кешеме?

Килеп чыкты бит менә!
Вәт ичмасам бу—рәсем!
Болай матур ясагач,
Мин рәссамдыр, күрәсең.

Сокланып туя алмас,
Караса да кем генә.
Белеп булмый тик менә
Нәрсә икәнен генә!

## Яз килгән бит!

Гел кышны
Ясап туйдым—
Шуңа күрә альбомга
Гөрләвек ясап куйдым.

Карадым-
Карадым да,
Кирәк булыр әле дип,
Ясадым корабын да!

Һәм сыерчык
Оясын!
Сыерчыклар килүгә
Калды бары буясым.

Ясадым мин инеш тә,
Ясадым талларын да.
Каз бәбкәләре йөргән
Зур ишегалларын да...

Яз килде
Альбомыма!
Үзем дә шаккаттым, әй,
Яз ясый алганыма!

Чү!
Ни бу?

Гөрләвегем
Чын-чынлап агып китте,
Мин ясаган корабны
Диңгезгә алып китте.

Яңа кайткан сыерчык
Сайрарга ук тотынды.
Ә инешнең сулары
Тирә-якны тутырды.

Яфрак ярды
Талларым...
Сөйләп тормыйм
Калганын.

Карасам тәрәзәгә,
Малайлар көлешкәнгә,
Исләрем китте—безгә
Яз килгән дөрестән дә!

Яз керде өебезгә!

Тәрәзәмне ачуга,
Безгә яз килеп керде,
Елмаеп-көлеп керде,
Керде дә
Гөлне күрде,
Күрде дә килеп кунды.
Килеп кунуы булды,
Гөл дә тиз
Җаен тапты—
Тотты да
Чәчәк атты!

Бөтен өйгә тулды яз:
Әнигә дә кунды яз.
Әнием дә үзгәрде—
Алсуланды йөзләре,
Матурланды тагын да,
Сыйлар артты табында!

Үземне дә сөйде яз,
Минем яныма килеп!
Тик торам менә көлеп!

Чөнки рәхәт, күңелле!—
Дөнья язга күмелде!
Әллә соң үзебезгә
Язны алып калыйммы?—
Тәрәзәне
Ябыйммы?
Ул чагында ул бездә
Озаграк торыр иде,
Өебездә ел буе
Яз гына булыр иде!

Әмма урамда бар да—
Кызлар да, малайлар да
Көтәләр яз көлүен,
Көтәләр яз килүен!

Юк, япмадым тәрәзне,
Шуларны уйладым да.
Язны тышка җибәрдем,
Аз гына уйнадым да!

## Љйрәнә

Энем йөрергә өйрәнә,
Тотынмыйча йөрергә.
Хәтта йөрергә дә түгел,
Исәбе—йөгерергә!

Матур гына атлап китә,
Бер атлый да абына.
Абына да торып китә,
Тик егыла тагы да.

Торырга кайчан өлгерә?
Егыла кай арада?
Егылып яткан була ул
Кайчан гына карама!

Көн дә шулай өйрәнә ул
Урамда да, өйдә дә.
Йөрергә өйрәнми лә ул,
Егылырга өйрәнә!

## Бабай белән абый

Озын куе мыегы
Бар безнең ак песинең.
Ул мыек тырпайсамы?!—
Коты оча күсенең!

Җилфердәп торган сакал
Йөртә безнең кәҗә дә.
Ул ак сакал кәҗәгә,
Әлбәттә, зур дәрәҗә!

Аларны бар да, бар да—
Кош-кортлар, җанварлар да:
— Саумы, Песи абый!—дип,
— Саумы, Кәҗә бабай!—дип
Сәламлиләр күргәч тә...

Кәҗә бабай—ике яшьлек!
Песи абый — бер яшьтә!

## Көтәм мин корабымны

Ясаган идем кораб,
Үзе йөзә торганны:
Хәтта үзе борыла,
Көтеп тормый борганны.

Ләкин гөрләвек белән
Китеп барды корабым.
Тотып калып булмады—
Йөгереп тә карадым...

Инде ничә көн торам
Диңгезгә карап кына.
Кораблар күп, күренми
Тик минем кораб кына.

Кайда йөзеп йөрисең?
Корабым, күрен инде!
Ә корабым нык иде,
Батарлык түгел иде.

Шулай да штормда
Аңа су тулуы бар.
Аның пиратларга да
Эләккән булуы бар.

Бәлки, ул бу турыдан
Инде узып киткәндер?
Ул инде әллә кайчан
Африкага җиткәндер!

Соң, әлбәттә, күптәннән
Ул узып киткән булган.
Ә мин аны ничә көн
Диңгездән көткән булам!

Капитан булачакмын!

Үсеп җиткәч, мин барыбер
Капитан булачакмын!
Корабымның штурвалын
Туйганчы борачакмын!

Кораб белән мин иң ерак
Илләргә барачакмын,
Диңгезләрдә ачылмаган
Утраулар табачакмын!

Яңа Гренландиядә,
Папуаслар илендә,
Юлбарыслы джунглида
Йөрисем бар минем дә!

Штормнар вакытында
Җиңел булмас!
Шулай да
Мин капитан булыр өчен
Күптән әзер бугай ла!

Диңгез давылына гына

Булыр иде түзәргә...
Ләкин башта ничек кенә
Өйрәнергә
Йөзәргә?!

## Күршеләрнең бакчасы

Күршеләрнең бакчасына
(Менә син дә карап тор!)
Керә дә китә безнең туп
Инде ничә кабаттыр!

Аннары шул туп артыннан
Керергә туры килә,
Кача-поса, кача-поса
Йөрергә туры килә.

Шунда, тупны эзләгәндә,
Алма күреп аласың.
Ә аннан соң бер-икесен
Кесәңә дә саласың.

Алмалары гына булсын,
Салыр урын табасың.
Ә анда алма җитәрлек—
Аларны кем санасын!

Алма күргәч, тубыңны да
Табалмый каңгырасың.
Кайчакта тупны бөтенләй
Онытып калдырасың.

Алмага керү—начар эш,
Үзебез дә беләбез.
Шуңа да алмага түгел,
Без бит тупка керәбез.

Ә бакчада ул алмалар
Коелалар тып та тып!
Нигәдер нәкъ шул бакчага
Иләште безнең туп.

## Кем дә елар иде!

Алмаз кайткан урманнан,
Тик елаган нигәдер.
Бәлки, аның ашыйсы
Йә эчәсе килгәндер?

Йә булмаса ул анда
Тапмагандыр бөрлегән?
Яки аңа берәр агач
Бүре булып күренгән?
Алмаз, бәлки, чыннан да
Курыккандыр бүредән?

Бәлки, бүренең өне

Янында йөргәндер ул,
Бүренең өненә үк
Ялгышып кергәндер ул,
Бүре өненә кергәч,
Бүрене күргәндер ул!

Бүре, явыз, Алмазны
Тешләргә теләгәндер!
Ә Алмаз куркуыннан
Нишләргә белмәгәндер!

Алмаз түгел, Алып та
Елар иде... курыккач!
Ничек курыкмыйсың, ди,
Шундый хәлгә юлыккач?!

Алмазның үзеннән дә
Сораштырдык шуннан без.
Тик менә Алмаз өчен
Без юкка борчылганбыз.
Алмаз ул еламаган
Бүредән шүрләгәнгә.
Елаган гарьлегеннән—
Бүрене күрмәгәнгә!

### Әниемә булышам!

Казан аэропортында
Без самолет көтәбез:
Әти белән икебез
Әбиләргә китәбез.

Озата безне әни—
Булган аңа әллә ни!

Нигә елыйдыр инде?—
Авыл бит ерак түгел.
Елыйбыз әни белән,
Ләкин мин елак түгел!

Әни елый, мин елыйм,
Ә әтием юата.
Туктарга да тырышам—
Елата да елата.

Әти миңа: «Тукта!»—ди,
Елавымны хупламый.
Мин бик туктар идем дә,
Әнием бит туктамый.

Әти белми микәнни?
Мин бит бары булышам—
Тизрәк туктасын, диеп,
Мин әнигә елашам!

### Кызыл төс

Бит очлары кызыл анның—
Бик килешә кызыл төс.

Аны күрсәм, мин кызарам—
Кызыл төс иң кызык төс.

Алмалар пешә кызарып—
Кызыл төс иң тәмле төс.

Алан тулы кызыл чәчәк—
Кызыл төс иң ямьле төс.

Кызыл кошлар сайрый анда—
Кызыл төс иң җырлы төс.

Учаклар яна кызарып—
Кызыл төс иң җылы төс.

Баш очында кызыл кояш—
Кызыл төс иң якты төс.

Кызыл төс иң кадерле төс—
Ул бит безнең яклы төс!

Көтү әйбәт көтелгән

Дөньяда иң кирәк эш
Авылның һәрбер эше.
Шуңа безнең авылда
Көтүче—һәрбер кеше!

Җәй җиттеме, өлкәннәр
Көн дә көтү көтәләр:
Берәм-берәм көтәләр,
Чират белән көтәләр.

Агрономнар, фельдшерлар,
Машина йөртүчеләр,
Бригадирлар, мөдирләр—
Һәммәсе көтүчеләр!

Хәтта мин дә—көтүче!
Беркемнән ким түгел мин:
Әти белән көнозын
Көтү көттем бүген мин.

Йөз ун сыер тугайда
Туйганчы ашадылар.
Йөз ун сыер туйгачтын
Чабыша башладылар.

Туйганчы чапты алар
Көндезгә чаклы алар!

Йөз ун сыер аннары
Туйганчы сөзештеләр.
Елгага төшеп аннан
Туйганчы су эчтеләр.

Туйгачтын да эчтеләр,
Мин бик оста сызгыргач.
Аннан суда тордылар,
Кояш бик нык кыздыргач.

Һәм койрыклары белән
Черки кудылар алар.

Без көткәннән канәгать,
Риза булдылар алар.

Ә кайткач, әни безгә
Җылы сөт савып бирде,

Иң олы чынаякка
Тутырып салып бирде.

Эчкән юк иде бер дә
Мондый сөтне гомердә!

Өлкәннәрнең чиратлап
Нигә көтү көткәнен
Белдем инде — алар да
Белә икән сөт тәмен!

Ә сөте бигрәк тәмле:
Изрәтте бөтен тәнне!
Әллә инде сөтеннән,
Шундук йоклап кителгән...

Көтү әйбәт көтелгән!

Беренчегә!

Алмаз бүген беренче кат,
Иртән беренче торып,
Иң беренче дәресенә
Китте беренче булып!..

Ул бит укучы булам дип
Җәйләр буе җыенды:
Китаплары көнгә мең кат
Таралды да җыелды.

Дәфтәрләре дә көн саен
Җыелды да таралды.
Өр-яңа киемнәре дә
Мең кат киеп каралды.

Өр-яңа портфелен дә ул
Мең кат алды кулына:
Тотып карады сулына,
Арыгачтын — уңына.

Портфелен алды әтисе,
Әлифбасын — әнисе,
Дәреслекләрен — абыйсы,
Буяуларын — әбисе...

Карандашларын — апасы,

Көндәлеген — бабасы...
Бар да булды! Калды бары
«Бишле» генә аласы.

«Бишле»се юк — мәктәпкә ул
Бер «бишле»сез барачак.
Борчылмагыз! «Бишле»ләрне
Алмаз үзе алачак!

## Үзем ясаган кораб

Бик матур бер кораб
Ясадым — күрегез!
Кем тели йөзәргә? —
Корабка керегез!

Аварлык түгел ул
Бернинди давылда.
Туктаталмый аны
Бернинди явым да!

Батарлык түгел ул,
Чөнки бит мин үзем
Ул матур корабны
Берүзем төзедем!

Әнием, син дә кер!
Әтием, син дә кер!

Туйганчы йөзегез
Корабта үзегез!

Ул сезне диңгезгә
Җиткерер — алдамыйм.
Ә үзем... үземме?
Сыймыйм шул анда мин!

## Светофор

*Авылдан шәһәргә беренче тапкыр*
*килгән малайларга-кызларга*
*махсус язылды*

1

Карап-карап торам да мин,
Уйлап-уйлап торам да
Куркып куям: ай-һай кыен
Йөрүләре урамда!

Урамның теге ягына
Мөмкин түгел үтүе:
Урам тулы троллейбуслар,
Машиналар көтүе.

Әллә кайсы җирдән генә
Трамвай яки машина,

Йә булмаса, мотороллер
Килә чыга каршыңа!

Йә сызгырта сыбызгысын
Милиционер абый.
Йөри белмәсәң урамда,
Ул әллә каян таный!

Ялт чыгасың тротуарга —
Сизелми дә калына.
Бигрәк авыр шул шәһәрдә
Авыл малайларына!

2

Алмаз исә уйламый да —
Ят түгел аңа кала.
Машиналы урамда ул
Туйганчы йөри ала.

Бу шау-шулы урамнарда
Алмаз да йөрми тормый,
Тик урам аша чыгулар
Алмазга берни тормый.

Башта сул якка карый ул,
Аннан уң якка карый.
Аннары миңа борыла:
— Хәзер чыксак та ярый!

Ни булды соң «Волга»ларга,
«ГАЗ»га, «МАЗ»га, «КамАЗ»га?
Выжлап килеп туктыйлар да
Юл бирәләр Алмазга.

Баксаң, алда светофор
Тора икән лә сакта.
Чыгалар икән урамнан
Яшел ут янган чакта.

Кызыл, сары ут янганда
Ярамый, ди, чыгарга.
Янганга кадәр яшеле
Кирәк икән чыдарга...

3

Безнең авылда да бар
Яшел утлы светофор!

Урамдагы яшел чирәм
Светофор кебек анда.
Нәкъ светофор шикелле
Чакыра безне алга!

Шунысы әйбәт, ул бер дә
Туктатып тормый безне.
Шунысы әйбәт, ул бер дә
Кирегә бормый безне.

Шуңа авыл урамында
Уйныйсы килеп тора.
Анда берни дә булмасын
Һәммәбез белеп тора.

Тиргәмиләр — урам аша
Ун кабат чыкканда да.
Минем йөз кат чыкканым бар —
Сүз әйтмиләр анда да...

Яшел утлы светофор
Безнең авылда да бар!

### Тырыш малай

Малайлар белән бергәләп
Озак уйналды бигрәк:
Әни тиргәгәнче
Тизрәк
Өйгә кайтырга
Кирәк!

Кайтмас та идем тиз генә,
Булмаса эш әгәр дә —
Әнигә булышасым бар
Дәрес әзерләгәндә!

### Яңа бүрек

Әллә зур,
Әллә таман —
Күземә
Төшә һаман,
Аптыратты ла
Тәмам!
Булмый карап
Йөреп тә,
Булмый берни
Күреп тә —
Ачу килә
Бүреккә!
Әй бүрек,
Болай булсаң,
Кызык итәм үзеңне —
Син капламасын диеп,
Йомып йөрим күземне!

### Чәкчәк

Әй матур соң —
Нәкъ чәчәк!
Өстәлдә тора
Чәкчәк.

Әгәр күпләп ашасаң,

Ул шунда ук бетәчәк!

...Капкаласак та
Чәк-чәк,
Ашалып беткән
Чәкчәк!

## Ничекнигәниөчен

Гөр китерә өй эчен
Ничекнигәниөчен!

Карыйм ачуланып та,
Булмый ләкин файдага:
Әйләнә дә куя ул
Кайчанничәкайдага!

Әгәр тагын тиргәсәм:
«Нигә туктыйм мин!» — ди дә,
Әйләнә дә куя ул
Кайчанничәниндигә!

Ничек теле армыйдыр?
Ни өчен туктамыйдыр?

Белмим, кайчан
Туктар ул?
Белмим, кайчан
Йоклар ул?

Тагын күпме такылдар?
Такылдар ул, такылдар,
Такылдар күп
Тапкырлар!

Ник туктамый, ни өчен
Кайчанничекниөчен?

Ә мин аның нигә
туктамаганын беләм.
Аның тизрәк үсәсе,
күбрәкне беләсе килә.
Хәер, барыбыз да
шулай бит инде!

## Мин әгәр икәү булсам...

Мин әгәр икәү булсам,
Әй рәхәт булыр иде.
Әни мин эшләгәнгә
Аптырап торыр иде.

Ул кушкан эшләргә мин

Шунда ук күнәр идем.
Ул эшләрне тиз генә
Икегә бүләр идем.

Беребез эшләгәндә,
Беребез уйнар иде.
Ә беребез өйгә эш
Турында уйлар иде.

Беребез елаганда,
Беребез көләр иде.
Әни нәрсә бирсә дә,
Икегә бүләр иде.

Абый фуражкасын да
Алмашлап кияр идек.
Беребез кигән чакта:
«Миңа да!» — дияр идек.

Кызыктырып күземне
Кавын тора табында.
Икегә бүленәчәк
Табындагы кавын да.

И-и-и... ул чакта миңа дигән
Ул кавын кими икән —
Телгә дә тими икән.
Юк икән лә,
Минем икәү
Буласым килми икән!

Кысла

(*сүз уйнату*)

Тыпырчынма,
Кысла,
Учта!
Кысарга син,
Ай-яй,
Оста!

Кысла, кысла,
Кызма,
Кысла!
Кысар идең,
Кайчың
Кыска.

Тик син минем
Кулны
Кысма.
Кысма, кысла,—
Без бит
Дус ла!

Юк, барыбер

Кыса
Кысла.
Мин курыкмыйм
Кысла,
Кыс ла!

## Кызганыгыз бүрене!

Көн дә мульти карыйбыз —
Берне түгел, унберне.
«Ну, погоди!» һәммәбезне
Йөзәр тапкыр көлдерде.

Белмим, ник
Көләбездер?
Мәзәк дип
Беләбездер!

Ә мультидә бүрене
Көлкегә
Калдыралар,
Утта да
Яндыралар,
Суга да
Батыралар,
Цементка
Катыралар —
Кагалар да
Сугалар,
Сугалар да
Кагалар,
Сугар сәбәп
Табалар!

Улый бүре,
Елый бүре,
Йөри бүре, сызланып.
Мин дә утырам
Сызланып,
Шул бүрене кызганып.
Ул, янәсе,
Ямьсез,
Юньсез,
Ул — әшәке,
Ул — тиле!
Бер дә андый түгелдер ул,
Туктатыгыз мультине!

## Черкиләр җыры

(*сүз уйнату*)

Без безсез яшәмибез,
Безсез без эшләмибез...

*Ш.Галиев*

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек...

*Халык җырыннан*

Без, без, без идек,
Без унике без идек,
Без, чыннан да, без идек.

Тик без без түгел идек,
Безсез дә түгел идек.
Сез без булмаган кебек,
Без сез дә түгел идек.

Ләкин шуны белегез:
Безле бит без үзебез,
Безнең дә бар безебез,
Без безсез дә безлебез!

Шуңа да без безлибез:
Без-без-без-без-без, дибез,
Без унике генә түгел,
Кирәк чакта — йөз, дибез.
Үзебез без булмасак та,
Борыныбыз — без, дибез.

Капсаң безгә —
Түз генә!
Без түгелбез
Без генә!
Булдырабыз
Без генә
Менә шулай безләргә.
Менә шуңа күрә без
Кызыкмыйбыз безләргә.
Чыктык дуслар
Эзләргә —
Без бит сезне
Эзлибез.
Телисезме —
Әйдәгез,
Бергәләшеп
Безлибез:
Без-з-з, без-з-з, без-з-з...
Кушылыгыз,
Әйдәгез-з-з-з...
Без-з-з...

Портта булган хәл

(*сүз уйнату*)

Диңгездә кораб торган.
Юк, портта кораб торган.

Корабта трап торган,
Юк, портта трап торган.

Шул порттагы траптан
Корабка кран менгән.
Корабтагы кран белән
Малайлар карп тоткан,
Малайлар краб тоткан!
Тик крабны карп йоткан,
Ә карпны краб йоткан!

Карпсыз калган кораб,
Крабсыз калган кораб,
Крабсыз калган карп,
Карпсыз калган краб...

Малайлар калган карап!

## Балыкчы

Үзебезнең инештән мин
Тоттым сазан баласын.
Минем бабам тоткан булган
Аның ерак бабасын!

Сез дә аптырар идегез
Мин каптырган сазанга —
Күпме генә тырышсаң да,
Сыймас иде казанга.

Юк, казанга гына түгел,
Әле бала килеш тә,
Әгәр җибәрсәң яңадан,
Сыймас иде инешкә!

Нәрсә, әллә
ышанмыйсызмы?
Тагын шундый зур бер
балык тотып күрсәтер
идем инде мин сезгә...
Тик менә берәү генә
иде шул андый
зур балык.

## Җил авырган бит әле!

— Җил нигә тынган? — диләр,—
Җил кая булган? — диләр.

Җил ята оясында —
Үзенең кыясында!

Җил бүген бик авырган —
Ул канатын каерган.

Әйбәт түгел лә җилсез,
Җилсез безгә күңелсез.

Каплап алган кояшны

Баш очындагы болыт! —
Җибәреп булмый
Борып.

Игеннәр дулкынланмый,
Учаклар ялкынланмый.

Тик торалар җилкәннәр,
Аптырыйлар өлкәннәр.

Җилфердәми керләр дә,
Җилсез — тынчу көннәр дә.

Җил, тизрәк терел инде!
Бер генә күрен инде!

Син әйт әле,
Җилме син?
Җилләт әле
Җирне син!

## Җил

Җилне сез
Уйнатмагыз!
Җилне сез
Уятмагыз!

Ул бит — буран малае!
Ул бит — давыл малае!
Ул — гарасат малае!
Ул — өермә малае!

Аның да бит киләдер
Үскәч буран буласы!
Яки давыл буласы!
Йә өермә буласы!

Аның да бит киләдер
Давыл булып дулыйсы!
Юри генә булса да,
Буран булып улыйсы!

Әгәр җилгә тисәгез,
Ачуын китерсәгез,
Ул чын давыл булачак,
Аннан буран булачак,
Һәм гарасат булачак,
Өермә дә булачак!

Сезгә авыр булачак —
Давыл-өермә белән
Бөтен авыл тулачак!

Бөтен дөнья, бөтен җир
Дер селкенеп торачак!
У-у-у-у-у-у-у-у...
Ж-ж-ж-ж-ж-ж-ж-ж-ж-ж...

У-у-у-у-у... урамга карасак,
Урам тулы өермә,
Урам тулы гарасат!

Күзне ачмалы түгел!
Болай гына, тиз генә
Җилне басмалы түгел!

Әйттем бит мин сезгә:
«Җилне уйнатмагыз,
Җилне уятмагыз!» — дип.
Ә сез тыңламаган
булдыгыз!

### Чишмә җыры

Челтер-челтер ага чишмә,
Һич тә тыймалы түгел.
Ә сулары шундый йомшак —
Эчеп туймалы түгел!
Эчеп туймалы түгел!

Без киләбез чишмәбезнең
Салкын суын эчмәгә.
Эчкәндә үзеннән-үзе
Баш иелә чишмәгә!
Баш иелә чишмәгә!

Чыңлый чишмә,
Җырлый чишмә —
Җилферди зәңгәр толым.
Чишмә җырын тыңлап ята
Зәңгәр толымлы болын!
Зәңгәр толымлы болын!

Чыңла, чишмә!
Җырла, чишмә!
Тынма, чишмә-чыганак!
Бу болыннар, уйсулыклар
Сиңа яшел чынаяк!
Сиңа яшел чынаяк!

### Безнең як крокодиллары

Булат бүген берүзе
Сөндә су кереп калган,
Таллык төбендә
Ике
Крокодил күреп калган!
Һәм чабарга
Тотынган,
Көчкә качып
Котылган!

Чапкан чакта, җитмәсә,
Ул бер талга абынган.

Икенче тал Булатның
Аягына кагылган.

Крокодил дип, Булатның
Тагын коты алынган.
Куркуыннан, ахрысы,
Тагын бер кат абынган.

Шул хәлдән соң Булатның
Бер генә сүз телендә:
— Ул усал крокодиллар
Әнә... әнә тегендә,
Әнә теге таллыкның
Әнә теге төбендә!

Ә малайлар көләләр,
Чөнки алар Булатның
Ни күргәнен беләләр.

Ләкин Булат сер бирми:
— Сез юкка көләсез,— ди,—
Белмисез бит сез берни!

Барыгыз да карагыз —
Таллыкта ята алар.
Бездәге крокодиллар
Кәлтә дип аталалар,
Белдегезме?!

### Мичкә ягылган мичкә

(*сүз уйнату*)

Әни бүген иртә белән
Мичкә яккан —
Ә мичкә ул искергән бер
Мичкә яккан.

Шул мичкәдән өй эченә
Җылы тулган —
Ул мичкәнең эче тулы
Җылы булган!

Яккандыр шул, мичкә үзе
Кибеп коргач,
Исеме үк: «Мичкә! Мичкә!»
Диеп торгач!

### Урманда

Бирелә кошлар, җәнлекләр
Читлеккә ябылмаган.
Урманы да койма белән
Уратып алынмаган.

Ул куяннар, ул пошилар,

Ул керпеләр, тилгәннәр
Казандагы зоопарктан,
Ахры, качып килгәннәр!

Алар безне күргәчтен,
Без урманга кергәчтен,
Тизрәк качып китәләр,
Тизрәк очып китәләр!

Юкса без ул җәнлекләргә,
Кошларга тиябезме?
Алар бит матурлый гына
Әйләнә-тирәбезне!

Без бит яратабыз гына
Аларны — белдегезме?!
«Курыкмагыз!» — дияр идем,
Белсәләр телебезне.

Белмиләр шул!
Алар шулай
Гел качарга торалар.
Зоопаркка ябарлар дип
Куркып качадыр алар!

Менә сиңа мә!

Безнең авыл өстеннән
Төнлә кар явып үткән.
Буран бабай Акбайны
Кар белән күмеп киткән!

Акбай
Туңгандыр инде,
Харап
Булгандыр инде!

Чү... Акбаем
Терелә —
Әнә башы
Күренә.

Әнә ул
Күзен ачты,
Ачты да
Торып басты!

Торып басты,
Кагынды.
Ур-ра! Акбай
Табылды!

Күреп
Елаганымны,
Үзен юллаганымны,

Акбай
Юата мине,

Ул миңа
Болай диде:

— Әйбәт урын таптым,— ди.—
Рәхәтләнеп яттым,— ди,—
Кар астында җылы,— ди,—
Тирләтте бу юлы! — ди,—
Рәхәт икән анда! — ди.

Беләм инде — алдалый!

Мине белми ди микән? —
Кар астында бит салкын.

Аңа — җылы,
Безгә — салкын!
Аңламассың
Эт халкын!

## Армас-талмас Барлас

Бер дә армас-талмас
Барлас,
Еламыйча калмас
Барлас,
Сер дә биреп тормас
Барлас,
Елаганнан гына
Армас!

Еламас ул юкка гына,
Сәбәпләрен табып елар.
Бер еласа, бар сәләтен,
Тырышлыгын салып елар!

Алай беркем елый алмас,
Әйтер Барлас күзгә карап:
«Моннан соң бер дә еламам,
Елыйм бүген соңгы кабат!»

Еласын ул соңгы кабат,
Үскәч бер дә
Елый алмас.
Йөзенче кат инде менә
Соңгы кабат
Елый Барлас!

## Кем соң минем Әби?

Минем Әби бик тә кызык
Кеше ул —
Ләбибләргә, Хәбибләргә,
Сәгыйтьләргә
Күрше ул.
Ул — әтинең Әнисе,

Апамның Дәү Әнисе.
Ул минем дә Дәү Әни,
Ул инде бик Дәү Әби.
«Сезнең җылы сүзегез
Минем өчен дәва»,— ди.
Бабам: «Карчык»,— ди аңа,
Ә әнигә — Биана.
Тик әнием: «Әни»,— ди.
Малайлар: «Бал Әби»,— ди.
Сәрби әби: «Яшьтәш,— ди,—
И Сәхипҗамалкаччаем,
Син һаман да яшь-яшь!» — ди.
Әбиләргә — Ахирәт ул,
Бар авылга — Авылдаш:
Бөтен авыл хәлен белде
Бервакытны авыргач.
Хәзер Хезмәт Ветераны,
Лаеклы Пенсионер,
Ә кечкенә чакта менә
Булган ул да Пионер.

Минем Әби
Сиңа кем була инде?
Соң үзе уйла инде!

### Мөгезборын белән озынборын

(*сүз уйнату*)

Мөгезборын!
Мөгезборын!
Мөгезборын
Мөгезенә,
Мөгезборын
Борынына
Килеп кунган
Озынборын.

Тапкан бит әй
Кызык урын:
Кызык мөгез,
Кызык борын!

Аптыраган
Озынборын:
Үзе — мөгез,
Үзе — борын!

Усалдыр бу
Сөзгәк мөгез,
Усалдыр бу
Сөзгәк борын!

Шуңа күрә
Озынборын
Очып киткән,

Мөгезборын
Сизмәс борын!

## Кайтабыз ла җиләктән

Кайтабыз ла ерактан,
Бик ерактан — җиләктән.
Безне йөргән дисезме
Әллә җиләк кирәктән?

Бер дә кирәктән түгел:
Бардык ашарга гына,
Күңел ачарга гына...

Акрын гына атлыйбыз,
Атлыйбыз — утырабыз,
Аннан киңәш корабыз,
Бераз ятып торабыз,
Аннан тагын торабыз...

Кузгалабыз аннары.
Кызган таба шикелле
Аякның табаннары.

Атлаулары бик авыр,
Күренми әле авыл.

Ә менә космонавтлар
Кызык итәрләр иде:
Күптән инде галәмнән
Кайтып җитәрләр иде.

Ә без һаман урманнан
Кайтып җитә алмыйбыз.
Оят инде — анысын
Үзебез дә аңлыйбыз.

Ахры, арганбыз бугай,
Бераз талганбыз бугай.
Без урманга җиләккә
Юкка барганбыз бугай.

Кайтып киләбез менә
Өебезгә соң гына,
Ашыйсы калган җиләкнең
Бакчадагысын гына.

## Айга очтык!

Беләсезме, нишләдек? —
Без ракета эшләдек.
Эшләгәч, көчкә-көчкә
Кереп утырдык эчкә.

Эчтә берни күренми,

Ракетабыз дерелди.
Гел очып китәр кебек,
Айга ук җитәр кебек!

Чыннан да җитүе бар,
Ни дисәң дә, кораб бит.
Очып китсә әгәр дә,
Безнең эшләр харап бит!

Әле генә аңладык:
Ашарга да алмадык.
Күлмәк кенә
Өстә дә.
Галәмгә очу безнең
Юк иде бит истә дә.

Чыннан да очып китсә?
Айга ук менеп җитсә?
Юлларыбыз уңмаса?
Җиргә төшеп булмаса?

Шуларны уйлыйм һаман —
Безнең эшләр бик яман...

Әле ярый ракета
Айга җитә алмады...
Очып китә алмады.

Очып китсә, әлбәттә,
Нишләргә белә идек —
Айга ук менә идек!

Без бит куркып торырга
Түгел малай-шалайлар.
Шулай да космонавт булу
Авыр икән, малайлар!

## Батырлык эшләр идем...

Ничек эшлим
Шәп батырлык? —
Бөтен дөнья
Шаккатырлык!

Батырлыкка
Сәләт кирәк.
Сәләтем бар —
Сәбәп кирәк!

Эзләп йөрим
Шул сәбәпне,
Иң бәхетле
Шул сәгатьне.

Тик сәбәпне
Табып булмый,
Тапмыйча да
Калып булмый.

Әрәм ята батырлыгым —
Уйланам шул хакта гына.
Үч иткәндәй, җае чыкмый
Иң-иң батыр чакта гына.

Батырлыклар эшләү җиңел,
Батыр булсаң, җайлы гына.
Батырлыклар эшләр идем —
Чыкмый әле җае гына.

## Тырышам

«Иген игү,— ди әтием,—
Мактаулы да, авыр да».
Нәкъ тырышлар, мактаулылар
Яши безнең авылда.

Алар басуда кышын да,
Язын, җәен, көзен дә.
Каникулда абыема
Булышкалыйм үзем дә.

И тырыша минем абый,
Үзем дә тырышкалыйм.
Шөрепләрен бик тырышып-
Тырышып борышкалыйм.

Мин тырышкач, комбайн да
Бик тырышып ура шул.
Тырышабыз — ипекәе
Бигрәк тәмле була шул!

## Әни кирәк

Көннәр якты
Булсын өчен
Әни кирәк!
Йокы татлы
Булсын өчен
Әни кирәк!

Җил-яңгырдан
Саклар өчен
Әни кирәк!
Усаллардан
Яклар өчен
Әни кирәк!

Ашлар тәмле
Булсын өчен
Әни кирәк!
Дөнья ямьле
Булсын өчен
Әни кирәк!

Безнең көннәр
Якты булу

Кирәк аңа!
Безнең йокы
Татлы булу
Кирәк аңа!

Җил-яңгырдан
Безне саклау
Кирәк аңа!
Усаллардан
Безне яклау
Кирәк аңа!

Безнең ашлар
Тәмле булу
Кирәк аңа!
Бөтен дөнья
Ямьле булу
Кирәк аңа!

Шуңа күрә
Ул бит Ана!

Оныткannardыр...

Сөн буенда көн бue
Уйнап соңга калынган,
Инде утлар кабынган.

Малайлар да таралды,
Бөтен дөнья караңгы!

Өйдә курыкканнардыр,
Мине югалтканнардыр,

Юктыр... оныткannardыр,
Йокларга ятканнардыр.

Әгәр онытмасалар,
Эзләп килерләр иде:
«Әйдә инде, кайт инде,
Улым!» — диярләр иде.

Өйдә мин булмаганга
Сөенеп торалардыр,
Минсез генә тәмле чәй
Эчеп утыралардыр.

«Алмаз өйдә булмагач,
Рәхәт инде,— диләрдер,—
Тузан тузмый, тавыш юк,
Рәхмәт инде»,— диләрдер.
Тагын әллә ниләрдер...

Әнием: «Бердәнберем!» —
Дигән була бит әле.
Ә бердәнбер малаен
Кеше шулай итәме?!

Болай булса, бөтенләй
Кайтмый калырмын әле:
Я БАМга, я КамАЗга
Китеп барырмын әле!

## Барыбер

Әтием дә, әнием дә
Мине һәрчак тиргиләр.
Шаярасы килгән чакта:
«Шаяр, улым!» — димиләр.

Әллә ниләр белә алар,
Ә мине өйрәтмиләр.
Ә кайчакта иң кызыклы
Кинога ияртмиләр.

Әле кинога йөрергә
Мин бәләкәй, имеш тә.
Кызгансыннар диеп, аннан
Елыйм малай килеш тә.

Бик теләгәч, елатсыннар,
Теләгәч, орышсыннар.
Минем алда усал, җитди
Булырга тырышсыннар.

Карасыннар минсез генә
Иң кызык киноларны.
Карасыннар...
Тик барыбер
Яратам мин аларны!

## Әйбәт булган!

Әнә теге куакта
Нидер селкенеп китте.
Ахры, куак астына
Нәрсәдер кереп китте.

Ул куакта, мөгаен,
Куян качып торадыр.
Куркуыннан дерелдәп,
Авыз ачып торадыр.

Белеп торам, куянның
Эшләре бик тә начар:
Бәлки, аны хәйләкәр
Төлкеләр тотып ашар.

Куянның каршысына
Йә бүре килеп чыгар,
Уйламаганда гына
Йә аучы атып егар...

Китте караңгыланып
Үземнең күз аллары.

Кисәтмәсәң хәзер үк,
Соң булачак аннары.

Акрын гына, тын гына
Киттем куак төбенә.
«Син сакланып йөр!» — диеп
Әйтим әле тегеңә.

Ләкин куак төбендә
Куянның юк эзе дә.
Юкка чыккан
Үзе дә...

Куян үзе сизенеп
Качкан булырга тиеш.
Болай булгач, эшләр шәп,
Бар да әйбәт, шул килеш!

## Белә икән

Олымы ул, кечеме ул,
Сөйләшсә дә кем белән,
Бөтен белгәне Айратның:
«Мин беләм!» дә «Мин беләм!»

Малайлар бергә җыелып
Сөйләшсәләр берәрни,
Тыңламый да әйтә Айрат:
— Беләм инде, беләм! — ди,—

Миңа акыл өйрәтмәгез,
Тыңларга да теләмим.
Сез белгәнне, сез күргәнне
Әллә кайчан беләм мин!

— Ни беләсең, Айрат? — дибез.
— Барысын да беләм! — ди.
— Берни белмисең бит,— дибез.
Айрат ике уйлап тормый:
— Анысын да беләм,— ди.

## Үч итеп!

Трамвайда мин гомергә бер
Билет алмаган идем.
Дөресрәге, алмадым дип,
Юри алдаган идем.

Шуннан Галләм күз ачырмый —
«Куян» да «куян», имеш.
Галләм аркасында гына
Йөрим мин «куян» килеш.

Әллә нинди шушы Галләм,
Әдәпне белми бер дә.
Космонавт буласымны ул,
Мөгаен, белмидер дә.

Космонавт булгач, күрерсез:
Бар галәмне гизәрмен,
Корабның тәрәзәсеннән
Мин сезгә кул изәрмен.

Космонавтлар отрядына
Мине алмый калмаслар —
Кирәк булачак бит әле
Аларга да алмашлар.

Әлегә алмый торсалар,
Үч итеп шул Галләмгә,
«Куян» булып булса да, мин
Очам әле галәмгә!

### Әллә мин Гаяз микән?

Минем
Исемем — Аяз,
Ә Гаязныкы — Гаяз.

Икебез дә көчле без,
Икебез бер төсле без.

Гаязның сөйләве дә
Минекенә тартымрак.
Тик менә Гаяз миннән
Бер хәрефкә артыграк...

Бер үк безнең яшебез —
Безгә дөрес дәшегез!
Юкса аералмыйлар,
Бутамыйча калмыйлар.

Гаязга — Аяз, диләр,
Миңа гел, Гаяз, диләр.

Берәр мутлык булдымы,
Гаяз шуклык кылдымы,

Инде кызык итәләр,
Миңа килеп җитәләр.

Күз ачарга бирмиләр —
Гаяз өчен тиргиләр.
Минем Аяз икәнне
Әйтерсең лә белмиләр...

Кайчак уйлап та куям:
Дөрестән дә, әллә дим,
Гаяз микән әллә мин?

### Күзләреннән аңлыйбыз

Безнең әни
Усал түгел,
Усалларга
Ул сан түгел.

Хәтта тәртип–
сезләнсәк тә,
Берөзлексез
Безләсәк тә,

Көнне эшсез
Уздырсак та,
Хәтта өйне
Туздырсак та,

Бер сүз әйтми
Әни безгә,
Юмарт түгел
Шул ул сүзгә.

Тик бер генә
Карап куя,
Шул бер карау
Ярап куя!

Шунда ук тын
Калабыз без,
Тынны тып-тын
Алабыз без.

Тиз аңлыйбыз
Әнине без.
Усал түгел
Әниебез!

### Бәрәңге алышабыз

Эш белән, хезмәт белән без
Якыннан танышабыз:
Басуда без өлкәннәргә
Бәрәңге алышабыз!

Кайберәүләр җыеп тора,
Берәүләр төяп тора,
Ә берәүләр капчыкларның
Авызын төйнәп тора.

«Бәрәңге малайлары» дип
Көлгән була абыйлар.
Көлсеннәр лә,
Алар безне,
Әйтерсең лә аңлыйлар.

Булышсак та, бәрәңгене
Яратмыйбыз әллә ни!
Кирәк чакта әни бездән
Кәнфитен дә жәлләми.

Ә шулай да булышабыз
Бернигә дә карамый.
Яңгыр ява, җилләр исә —
Ярдәм итми ярамый.

Бу җил Корчагиннарның да
Үзәкләрен өзгәндер,
Алар да салкын җилләргә
Безнең кебек түзгәндер!

Шундый салкын,
Ә эшлибез —
Без дә нәкъ алар инде.
Өлкәннәр кайтып беткәннәр,
Кайтсак та ярар инде.

Их, онытылган әнинең
Исенә төшерергә:
Онытмаса ярар иде
Бәрәңге пешерергә!

Юкка малай булганмын!

Их, кыз буласым калган!
Белмәдем шул мин алдан.

Кызларга — кадер-хөрмәт,
Эшләре бара гөрләп:

Бәйрәм саен аларга
Чәчәк бүләк итәсең.

Исәнләшеп үтәсең,
Ишек ачып кертәсең,

Хәтта портфельләрен дә
Күтәрешеп йөртәсең.

Троллейбуста барганда,
Автобуста барганда,

Алар утырып бара,
Ә син утырып кара!

Шунда ук күрәчәкләр,
Һәммәсе көләчәкләр,

Әдәпсез, диячәкләр,
Гадәтсез, диячәкләр.

Ә кызларга күңелле,
Йөриләр килештереп.

Үзләрен булмый хәтта
Шаяртып, ирештереп.

Хәтта толымнарыннан
Тарттырмаган булалар,

Чирттермәгән булалар —
Бигрәк иркә шул алар.

Ә үзләрен кайда да

Чиратсыз уздырасың...

Юкка малай булганмын,
Калган ла кыз буласым!

Моннан соң мин, күрерсез,
Акыллы булачакмын:

Яңадан тусам әгәр,
Кыз булып туачакмын!

## Дельфин да күрмәгән!

Күрдегезме сез Алмазны? —
Кайткан диңгез буеннан.
Ул кабырчык җыйган анда
Һәм көнозын коенган.

Коенган ул иртән, көндез,
Коенган ул кичен дә.
Кыскасы, бер ай буена
Яткан ул су эчендә.

Ләкин диңгез эченә үк,
Ахры, бер дә кермәгән:
Диңгездә бер ай ял итеп,
Бер дельфин да күрмәгән.

Диңгез буйлары матурдыр,
Анысын аңлыйм ла мин.
Тик бер дельфин да күрмәсәм,
Аңа атланып йөрмәсәм,
Диңгезгә бармыйм да мин!

## Уйлап табучы

Әлеге серемне минем
Белми әле беркем дә:
Уйлап табучылыкка
Әзерләнәм мин көн дә.

Ятам оза-а-а-ак уйланып,
Урында яткан килеш.
Уйлап табучы шулай
Гел уйланырга тиеш!

Ләкин уйлап табарга
Миңа ирек бирмиләр,
Өстәвенә тиргиләр:

— Юкка баш ватма! — диләр,—
Хәйләләп ятма! — диләр,—

Синнән уйлап табучы
Чыкмас,— диләр.
Көләләр.

Әллә уйлап табулар
Бик җиңел дип беләләр.

Башка фикер
Килгәндә,
Инде таптым
Дигәндә,
Киләләр дә
Керәләр,
Керәләр дә
Бүләләр!

Гел борчыгач,
Шаулагач,
Юри комачаулагач,

Миннән уйлап табучы,
Әлбәттә, чыкмаячак,
Мине бар да булдыксыз
Малайга чутлаячак.

Чутласыннар...
Минем сыман
Малай тумас кабаттан.
Җәл, кешелек мәхрүм кала
Өр-яңа бер талանттан!

## Пианино

Зу-ур, мату-ур пианино
Сатып алдылар миңа.

Хет көннәр буе уйна!
Хет төннәр буе уйна!

Мин, янәсе, шәп уйнарга
Өйрәнергә тиешмен.
Алай талантлы да булгач,
Мин, әлбәттә, килештем,

Тик талантым юклыгы
Минем бик тиз беленде:

Күңелләрем сүрелде,
Күнегүләр бүленде.

«Әнием, урамга чыгыйм,
Җибәр!» — диеп ялынам.
Юк, әнием җибәрми шул
Пианино яныннан.

«Минем улым талантлы
Булырга тиеш! — ди ул,—
Башкалардан аерылып
Торырга тиеш!» — ди ул.

Мин тырышам, мин өйрәнәм

Һәм эшләмим ни генә:
Чыга җанвар тавышлары,
Чыкмый бары көй генә.

Белмиләр лә хәлләремне! —
Хәлләрем начар минем.
Пианино булсам, күптән
Бу өйдән качар идем.

Их, качсын иде.
Барыбер
Уйный алмам мин аны.…
Әни мине интектерә,
Ә мин...… пианиноны.

## Нәкъ Чапай кебек чабам!

Атка атланып йөрим мин,
Үзем менәм ияргә.
Буладыр инде мине дә
Кавалерист дияргә!

Хәзер инде чапмыйм мин
Тик курка-курка гына:
Нәкъ Чапай кебек чабам,
Юк иңдә бурка гына.

Уйнап кала җилләр генә,
Очам мин — нәкъ карчыга!
Ярый әле дошманнар
Очрамыйлар каршыга.

Мин аларны ерактан ук,
Шунда ук таныр идем.
«Ур-ра!» кычкырып, аларның
Котларын алыр идем.

Алар мине күрү белән
Качып бетәрләр иде,
Калганнары, кул күтәреп,
Мине көтәрләр иде.

Минем алда һәммәсе дә
Куркып торачак иде,
Әгәр чынлап очрасалар,
Шулай булачак иде.

Алар миннән үзләре дә
Саклаunion
Каршыга очрамаганга
Шатланалардыр әле!

## Саныйлар

1

Җыелганнар утыргычка
Гөлнарлар, Санияләр.

Мактаныша-мактаныша
Нәрсәдер саный алар.

— Синең ничәү?
— Минем бишәү!
— Дүртәү генә минеке.
— Ә минем авызда — ике,
Ә кесәмдә — унике!

— Ә мин кичә энем белән
Егермене ашадым.
— Ә мин бүген берүземә
Унынчыны башладым...

Баксаң, кызлар көн дә шулай
Бәйрәм ясыйлар икән:
Алар шулай саный-саный
Кәнфит ашыйлар икән.

2

Бер ел үткән.
Утыргычта —
Гөлнарлар, Санияләр.
Әле булса мактанышып
Нәрсәдер саный алар.

— Минем әле унөч калды,
Кызыкмыйм артыгына.
— Ә минеке унбер әле,
Тик берсе ярты гына.

— Ә минеке берәү дә юк,
Нишлим инде, җәл дә соң.
Җәл булса да, җәлли-җәлли
Суырдылар һәммәсен...…

Баксаң, мактана-мактана,
Калдырып бар эшләрен,
Кызлар шулай саный икән
Исән калган...… тешләрен.

## Булышчы

Әниемә эш күп өйдә —
Мин шуңа да булышам.
Менә әле дә мин аңа
Чынаяклар юышам.

Булышам шул, юышам шул,
Мин бит инде булышчы.
Уф, арыдым! Һаман бетми!
Әнием, кил, булышчы!

## Мин әнигә ышанам

Апам миңа: «Син уңмаган
Малай бит»,— дигән була.

Җае чыккан саен шулай
Теңкәмә тигән була.

Ә менә: «Уңгансың!» — диде
Әнием миңа бүген.
Шулай булгач, мин бит инде
Уңмаган малай түгел.

Сез ничектер, ә мин үзем
Әниемә ышанам.
Чөнки әнинең сүзләре
Дөрескәрәк охшаган!

## Алмаш-тилмәш

Күрегез Алмазны! —
Мактанып, шатланып,
Ве-ло-си-пе-ды-на
Бара ул атланып!

Тормый ул вакланып,
Утырмый сакланып.…

Ай... руле шул мәлне
Аз гына борылды,
Алдагы коймага
Барып та орылды.

Чәчрәде очкыннар
Алмазның күзеннән,
Ә велосипедның
Чылбыры өзелгән!

Тәгәрмәчләре дә
Кыйшаган, тишелгән.
Алмазның аягы
Калайга киселгән...…

Әй юлчы иптәшләр!
Йөрегез сакланып,
Юлның уртасында
Тормагыз таптанып!

Тормагыз! Югыйсә
Калырсыз тапталып —
Велосипед килә
Алмазга атланып!

## Тәмле кычыткан

Кычыткан салып пешергән
Ашны әни иртәнгә.
Юри пешергәндер әле
Мине кызык итәргә.

Үзе берни булмагандай

Ашый кычыткан ашын.
Ничек чакмый ул әнине —
Шуңарга җитми башым.

Мин дә юри капкан идем,
Чакмый телне кычыткан.
— Сыйлачы, әни, мине дә,
Бигрәк тәмле кычыткан!

Тыңламаган өчен мине
Берчак кычыткан белән
«Пешергән» иде шул әни —
Шуңа тәмен шәп беләм.

Кызык булып китте әле
Шуны искә төшергәч:
Кычыткан да юашланган,
Тәмләнгән бит... пешергәч!

### Рррр белән Мррр

Яши безнең өйдә мәче.
Өй — мәченең биләмәсе.

Маэмай — ишегалдында.
Үз куышы аның да.

Маэмае Рррр исемле,
Ә мәче Мррр исемле.

Тик алар яши һаман
Эт белән мәче сыман.

Очратсалар бер-берсен,
Тотыналар, кем күрсен,

Туктаусыз ырылдарга,
Туктаусыз мырылдарга.

Алар бер эш кырмыйлар:
Көн дә шулай ырлыйлар,
Көн дә шулай мырлыйлар,
Кеше бар дип тормыйлар,
Әллә инде җырлыйлар,
Әллә инде
Берсен-берсе хурлыйлар.

Әрләшәләр, күр, ничек?!
Тыеп булмый берничек.

Тордым да уйлап кына,
Шаяртып, уйнап кына:

«Мин бит рррр,— дигән идем,—
Сезне мррр»,— дигән идем,
Тегеләр, шыпырт кына,
Шунда ук сыпырттылар!

Тиз аңлыйлар үзләре
Үзләренең сүзләрен.

Рррр да мррр дигән булып,
Ай-һай кызык иттердем,
Рәхәт икән белгәчтен
Мәче белән эт телен!

## Беркемгә дә охшамаган

Кайчагында мин үземне
Үзем аңламыйм:
Әниләрне кайчак тыңлыйм,
Кайчак тыңламыйм.

Тыңлаучан булып күренсәм
Алар күзенә,
Әни үзенә охшата,
Әти — үзенә!

Тыңлаусызлансам кайчакта
Мин әллә нигә,
Әни әтигә охшата,
Әти — әнигә!

Охшатсыннар! Әйтерсең мин
Юри тыңламыйм.
Үземә генә охшаган
Малайдыр ла мин!

## Крокодил йомыркасы

*Ләйлә Гаффаровага*

Бар минем диңгез төбеннән
Тапкан бер йомры ташым.
Әти әйтә: «Тапкансың,— ди,—
Крокодил йомыркасын!»

Бәй, мин бу таш йомырканы
Авылга алыйм әле,
Кайткач та тавык астына
Ояга салыйм әле.

Чыгарсын әле ак тавык
Чын крокодил баласын.
Авылдагы бар малайлар
Аптырашып карасын!

Тик ул бик усал булачак —
Чебиләрне тотачак!
Тотачак та
Йотачак!

Аннары тотып бетерер
Тавыкларны, казларны.
Алар беткәч, азык эзләп,

Пыр туздырыр абзарны.

Барын да йотып бетерер,
Карамас бернигә дә —
Килеп керер
Өйгә дә!

Яхшырак булыр ул ташны
Инешкә ыргытканым —
Күтәп ята алмыйм ла мин
Мине килеп йотканын...…

Һәм киттем инеш буена!
Чаба-чаба килешкә
Учымдагы йомырканы
Атып бәрдем инешкә!

Чебиләрне, тавыкларны
Йотмыйча торсын әле!
Йомыркасыннан тиз генә
Чыкмыйча торсын әле!

Үзем — шат,
Үзем инешкә
Күз салгалыйм сак кына.
Ташны суга ташласам да,
Шикләндерә чак кына.

Беләм инде
Крокодилның
Ташны тишеп чыкмасын.
Ә шулай да шикләндерә —
Кинәт кенә
Судан килеп чыкмасын!

Кайтмый калдык чак кына!

Таныштым мин бер фил белән,
Диңгез буена баргач.
Шундый дуслаштык, ул мине
Утыртып йөртте, аргач.

Өч кило кәнфит һәм шикәр
Ашаттым мин фил дуска.
Гел филгә атланып йөргәч,
Охшап беттем индуска.

Киткәндә дә филемне мин
Кәнфит белән сыйладым.
Безгә кайтмакчы иде дә —
Самолетка сыймады.

Кайта идем мин, әлбәттә,
Фил дуска да атланып.
Ул кадәр озын юл түгел —
Булса булыр атналык.

Сизелми дә калыр иде —
Аны гына беләбез.
Юлны белмәгәнгә генә
Кайтмадык фил белән без.

## Кайтыйк ла үзебезгә!

Диңгез матур,
Сүз дә юк.
Мондый диңгез
Бездә юк.

Ләкин теге ягына,
Ләкин теге ярына

Йөзеп тә чыгып булмый,
Төбенә чумып булмый.

Тотып булмый балык та,
Юк бередә таллык та.

Тозлы икән суы да —
Чистартмыйлар шуны да.

Эчкә үк кереп булмый,
Иркенләп йөзеп булмый:

«Кермә!» — диеп торалар,
Керсәң, кире боралар.

Кайтыйк ла
Үзебезгә —
Кечкенә
Сөнебезгә!

## Сөн буенда

Ятабыз Сөн буенда.
Барыбыз да — уенда.
Коену да кызыну
Барыбызның уенда.

Коенабыз иң башта,
Кызынабыз кояшта.

Кызынабыз комда да —
Көньяк кебек монда да.

Тотабыз аннан балык —
Тотабыз тәмен табып.

Шомырт, чия, бөрлегән,
Җиләк җыябыз аннан.
Телләр ачыта башлый
Кып-кызыл карлыганнан.

Тагын бер коенабыз,

Тагын бер кызынабыз.
Без кызынган арада,
Комда яткан арада,
Аяклар да, куллар да
Чуен кебек карала.

Ә абыйлар, апалар
Безгә карап көләләр,
Күзгә карап көләләр:

— Ну, булдыргансыз! — диләр,—
Негр булгансыз! — диләр.

Кызганган булып безне,
Күзгә карап торалар.
Юктыр ла, юри генә
Шаярталардыр алар...…

Көн буе су кердек Сөндә!
Бик күп кердек — җитәр лә!
Негр малае булганчы
Кирәк кайтып китәргә!

## Яңгырдан соң

Яшел яңгыр
Явып узды,
Яшь тамчылар
Җырын сузды:
— Без бит кояш кызлары!
— Без бит кояш кызлары!

Кагындылар
Таллары да,
Җыр башлады
Алары да:
— Без бит яңгыр кызлары!
— Без бит яңгыр кызлары!

Акчарлаклар
Җырладылар,
Әллә инде
Еладылар:
— Без ак болыт кызлары!
— Без ак болыт кызлары!

## Колын

Бөтерелә бөтерчектәй
Ул әнисе янында.
Әнисенә сыенасы
Киләдер шул аның да.

Әле бигрәк бәләкәй ул —
Чаба-чаба йөрисе
Бик килсә дә, үз янынnan

Җибәрмидер әнисе...…

Кечкенә, тик атландырмый:
Тешли, кешни, тибешә!
Аңа әле тешләшсә дә,
Тибешсә дә килешә!

Беркөнне мин ул колынга
Атланам дип мактандым.
Һәм сизми дә калды колын...…
Сикердем дә атландым!

Атландым да очтым гына...…
Яшел чирәм өстенә.
Менә сиңа нәни колын,
Менә сиңа кечкенә!

Ятам мин чирәм өстендә,
Булмый хәтта кузгалып.
Ә колыным: «Гафу ит!» — дип,
Тора мине кызганып.

## Нәни поши

Хәзер поши бездә яши —
Нәни генә поши ул.
Шундый әйбәт, шундый йомшак,
Акбайга да ошый ул.

Ул поши баласын әти
Карурманнан тапкан бит.
Әнисен...… усал абыйлар —
Браконьерлар аткан бит.

Мин теләмим бу турыда
Пошиемның белүен.
Шуңа әйтми йөрим әле
Әнисенең үлүен.

Еламасын, кайгырмасын,
Кайгырмасын — кирәкми...…
Ә теге усал абыйлар
Калмас әле эләкми.

## Атказанган сандугач

Ул сандугач — дус сандугач!
Көн дә бездә кунакта.
Минем өчен җырлар җырлый
Бакчабызда — куакта.

Сайрагач ул матур итеп,
Бик күңелле миңа да.
«Атказанган сандугач» дип
Исем бирдем мин аңа.

Аның ничек сайраганын
Тыңлатыр идем сезгә.
Сез үзегез дә ышаныр
Идегез минем сүзгә.

Ләкин җырчы сандугачым
Өйдә түгел — ул әле
Җылы якка гастрольләргә
Китеп барды шул әле!

Љзмәдем

Әллә яңгыр булганга,
Гөмбә тулган урманга.

Әкәмәт!
Шаккаттым мин —
Йөзләп гөмбә таптым мин!

Берсеннән-берсе эре,
Эрерәк тапкан бере!

Миннән ләкин көлмәгез —
Кайтып киләм гөмбәсез.

Тырысым буп-буш минем,
Ә күңелем хуш минем!

Тик йөрмәдем тик кенә,
«Тапмадым шул» дип кенә.

Чынлап гөмбә эзләдем,
Тик берсен дә өзмәдем.

Өзмәдем шул, өзмәдем.
Әй, көлгәннәр көлсен лә...

Гөмбәне яратканга
Өзмәдем мин берсен дә!

Акбай, Актүш, Актырнак

Беркөнне уйнап йөргәндә,
Килеп чыккан көтмәгәндә
Тау чаклы бер машина,
Өч көчекнең каршына.

Акбай, Актүш, Актырнак
Тормаганнар аптырап:
«Һау-һау-һау!» — дигән Акбай,
«Ау-ау-ау!» — дигән Актүш,
«Вау-вау!» — дигән Актырнак.

Өч көчек мәче баласын,
Мәченең дә кап-карасын
Очратканнар урамда,

Нишләргә дип торганда.

Акбай, Актүш, Актырнак
Калганнар, ди, аптырап:
«Һау-һау!» — димәгән Акбай,
«Ау-ау!» — димәгән Актүш,
«Вау-у!» — димәгән Актырнак.

Беркемнән дә курыкмыйлар,
Беркемне дә куркытмыйлар
Өч көчек, өч ахирәт —
Шулай булырга кирәк!

Акбай, Актүш, Актырнак
Үсә уйнап, җыр җырлап:
«Һау-һау!» — дип җырлый Акбай,
«Ау-ау!» — дип җырлый Актүш,
«Вау-у!» — дип җырлый Актырнак.

## Жираф

Жирафка җирдә
Яшәве кыен —
Кая куярга
Белми ул буен.

Гел комачаулый
Шул озын муен.
Жирафка — авыр,
Ә сезгә — уен.

Шуңа кино да
Күрә алмый ул,
Хәтта трамвайга
Керә алмый ул.

Бара алмый ул
Хәтта кунакка,
Кача алмый ул
Хәтта куакка.

Башкалар сөйли,
Ә ул ишетми.
Дуслары аны
Бер дә иш итми...…

Жираф булганга
Йөргән оялып,
Нишләргә белми
Йөргән уйланып.

Һәм жираф килгән
Шундый карарга
(Мин үзем бардым
Аны карарга):

Жирафлыгын ул
Инде ташлаган
Һәм кран булып

Эшли башлаган.

## Туган тел

«Туган тел» —
Иң әйбәт шигырь!
«Туган тел» —
Иң әйбәт җыр!
«Туган тел» —
Иң әйбәт китап!
Туган тел —
Иң әйбәт тел!
Туган тел
Әйбәт булганга
Шигыре дә,
Китабы да,
Җыры да
Иң әйбәттер!

## «Шираматан»

Әни миңа: «Матур итеп
Йөре атаң төсле,— ди,—
Югыйсә йөрисең, улым,
Шираматан төсле»,— ди.

Нәрсә соң ул Шираматан?
Сүзлекләрне актардым,
Сораштырып та карадым,
Тик барыбер тапмадым.

Кошмы, җанвармы соң ул?
Дөньяда бармы соң ул?

Әни аны әбисеннән
Ишетеп калган булган.
Ул, минемчә, булмаган да,
Булса да ялган булган.

Шираматан дип ул кадәр
Ник баш ватамдыр инде?
Шираматан булгачтын ул
Шираматандыр инде.

Тоттым да «Шираматан» дип
Мин этемне атадым.
Шираматан булып йөри
Хәзер Шираматаным.

— Шираматан!
Шираматан!
Маһ-маһ...…

## Карачкы-батыр

Безнең яңа бакчага
Яңа койма койганнар,
Ә бакчаны сакларга
Яшь карачкы куйганнар.

Чыпчыклар беткән качып,
Тора ул горур басып!

Сакчы булдым дигәч тә,
Хуҗаның тузып беткән
Эшләпәсен кигәч тә,
Мактанып торган була,
Авызын ерган була.

Аның килеш-килбәте
Ошамый Актырнакка:
Карый ул һау-һаулап та,
Карый бераз ырлап та.

Кара, кара, карачы:
Селкенми дә карачкы!

Актырнак аптыраган,
Башка өреп тормаган.

Куркыта алмаслыгын
Шунда гына төшенгән,
Уйлаган ул эченнән:

«Бакчага кереп йөрүне
Ныклап тыйганнар икән.
Карачкының иң батырын
Сайлап куйганнар икән!»

Акрын тәмамланучы
тиз шигырь

Әни мине тапты да,
Шунда ук туктатты да:
— Вакыт уздырмый гына,
Озакка сузмый гына,
Мыштырдамыйча гына,
Ялкауланмыйча гына,
Иренми — бик тиз генә,
Тиз генә, җитез генә,
Җилдәй йөгерек кенә,
Чабып-йөгереп кенә,
Җәһәт кенә, шәп кенә,
Шәп кенә, шәпләп кенә,
Елт кына, елгыр гына,
Ялт кына, өлгер генә,
Иң туры юлдан гына,
Елдам гына
Кибеткә
Бар әле, улым! — диде,—
Үзем барыр идем дә
Буш түгел кулым,— диде.

Берни түгел бу йомыш
Безнең кебек егеткә:
Ә дигәнче шунда ук
Чыгып чаптым кибеткә!
Чаптар атлар шикелле
Бөтен көчкә ыргылдым,
Ташландым, томырылдым,
Атылдым нәкъ ук кебек,
Очтым гына туп кебек,
Яшен кебек, ут кебек,
Каударландым, ашыктым,
Кабаландым, элдердем,
Җилдем генә, җилдердем,
Юл буйлап сыздым гына,
Армадым — кыздым гына,
Барсын да уздым гына,
Арттырдым тизлегемне,
Күрсеннәр әле диеп,
Минем җитезлегемне...…
Җиттем менә килеп тә
Әни әйткән кибеткә!

Тик ишеге — йозакта,
Ә йозагы — озакка!

Шун-нан кә-еф кы-рыл-ды,
Ниш-лим, ки-ре бо-рыл-дым,
Бо-ры-лып ки-теп бар-дым.
У-ф-ф-ф...…
Ар-ды-ы-ы-ы-ым!

## Җәяүле буран

Ишек ачылып киткәчтен,
Мин кем керә дип торам:
Малайларны да уздырып
Килеп керде ак буран.

Бераз аптырап торды да,
Тузгытып ак карларын,
Безнең аяк астына ук
Кереп качты аннары.

Куян кебек йомарланып
Бара ул тып-тын гына,
Кондуктор күрмәсен диеп,
Шым гына, мыштым гына!

Җәяүле буран да хәзер
Алдатмый — ай-яй оста:
Безнең кебек рәхәтләнеп
Йөри ул автобуста!

## Мөгезле болыт

Бер болыт өстә
Тора кукраеп,
Очлы мөгезе
Тора тырпаеп.

Бу болыт бик тә
Усал болыттыр,
Усал болытта
Усал холыктыр!

Йолдызларны ул
Чөеп атачак!
Йолдызлар җирдә
Аунап ятачак...

Бәй... китте болыт,
Калды мөгезе.
Мөгезе күктә
Калды берүзе.

Болыт өстенә
Ай кунган икән,
Мөгез дигәнем
Ай булган икән.

Мин аны күптән
Уйлаган идем,
Әйтергә генә
Кыймаган идем.

## Ай нәрсәгә охшаган?

Алмаз айны күзәтә:
— Ай туп кебек түгәрәк.
Кит, Булат, кит, өстеңә
Төшмәсен,— ди,— тәгәрәп!

Аптырамый Булат та:
— Мине алай алдама!
Охшамаган ул тупка,
Охшаган ул алмага.

Ай да алма шикелле
Кызарып пешәр әле.
Алдаласаң, башыңа
Өзелеп төшәр әле!

Түзми әбиләре дә:
— Ялганчы булмагыз! — ди,—
Сез мине тыңлагыз! — ди.—
Ай бит ул бабагызның
Фонаре иде элек,
Тузгач, агач башына
Калдырган иде элеп.

Малайлар сер бирмиләр,
Әбекәйне сыныйлар:

— Фонарь булгач, ник һаман
Сүнми ул? — дип сорыйлар.

— Космонавтлар керосин
Салып тора, күрәсең,—
Ди әби җитди генә,
Шаяртмый-нитми генә...…

Мин үзем бу сүзләргә
Ышанмыйм...…йә ышанам.
Ә сезнеңчә, егетләр,
Ай нәрсәгә охшаган?

«ДТ-75» тракторының
улына җырлаган
бишек җыры

Үсеп буйга җитәр ул,
Еракларга китәр ул,
Эш яратыр, эш сөяр,
Илгә хезмәт итәр ул!

Йокла, улым, матурым,
Ят, ял итсен моторың,
Бәләкәч тракторым!
Тыр-тыр-пытыр-тыр-тырым,
Пытыр-пытыр-тыр-тырым,
Йокла инде, күз нурым!
Тыр-р-р-р-р-р...…
Тыр-р-р-р-р-р-р...…

Иң беренче торыр да
Бар авылны уятыр,
Матур тавышы белән
Кош-кортларны кыйратыр!

Йокла инде, матурым,
Ят, ял итсен моторың,
Бәләкәч тракторым!
Тыр-тыр-пытыр-тыр-тырым,
Пытыр-пытыр-тыр-тырым,
Йокла инде, күз нурым!
Тыр-р-р-р-р-р...…
Тыр-р-р-р-р-р-р...

Басуларда, кырларда
Гөр-гөр-гөр-гөрләп торыр,
Сөрер дә чәчәр, урыр,
Олы трактор булыр!

Йокла, улым, матурым,
Ят, ял итсен моторың,
Бәләкәч тракторым!
Тыр-тыр-пытыр-тыр-тырым,
Пытыр-пытыр-тыр-тырым,
Йокла инде, күз нурым!
Тыр-р-р-р-р...…

Тыр-р-р-р-р-р...

## Ак ат

Бервакытны әтием
Ят бер атка тап булган.
Ул атка тап булуы
Гомердә бер кат булган.
Ат, чыннан да, ят булган,
Ят ат шундый ак булган:
Аяклары ак булган,
Тояклары ак булган,
Ә менә колаклары...
Колаклары ак булган.
Койрыгымы? Койрыгы...
Койрыгы да ак булган.
Ул ак атның сыртында
Кечкенә бер тап булган,
Ул табы да ак булган.
Ялкын төсле яллары...
Алары ап-ак булган,
Ә түше ак булмаган —
Актан да ап-ак булган.
Менә шундый ат булган,
Ул шундый ак ат булган,
Шундый ап-ак ат булган,
Ап-ак, ап-ак ат булган,
Актан да ак ат булган,
Актан да ап-ак булган,
Ап-актан да ак булган.
Минем әти күргән ат,
Ул атланып йөргән ат
Менә нинди ат булган!
Ат булуы хак булган,
Ак булуы хак булган,
Хак булуы хак булган.
Дөресе болай булган:
Чыннан да, ат — ат булган,
Чыннан да, ат — ак булган,
Чыннан да, ак ат булган!
Минем әтием менә
Шундый атка тап булган.
Менә бит ул ничек булган!

## Буранлы көн

Беркем чыкмый урамга,
Буранлы көн булганга.

Буран ала бөтереп,
Салкын ала өттерем!

Кошлар гына һавада

Чайкалалар һаман да.

Рәхәтләнеп очарга
Бик кыендыр кошларга.

«Ми-8А»

Самолетларда очмаган
Малайлар әздер бездә.
Нинди генә самолетлар
Эшләнми хәзер бездә.
Самолетларның «Ил»ларын,
«Ил-18», «Ан»нарын,
«Ту-154»ләрен,
Йә «Як-40А»ларын —
Беләсездер аларын.
Ә менә сез «Ми-8А»
Дигәнен беләсезме?
Көләсезме?
Андый самолетны бер дә
Ишеткән юк, дисезме?
Чыннан да, белмисезме?
Шаярусыз-нисезме?
Шулайдыр шул.
Аның әле
Буявы да кипмәгән.
Ул әле оста очарга
Өйрәнеп тә җитмәгән.
Аның әле пропеллерын
Алыштырырга кирәк,
Бер-ике җиренә кадак
Кагыштырырга кирәк.
Ул өр-яңа самолетның
Конструкторы мин булам.
Ә мин үзем «8» яшьлек
«А»лмаз «Ми»ңнуллин булам!

Мияулый торган ишек

Тавышлары
Әй әче,
Кычкыруы —
Нәкъ мәче!
Ачкан саен,
Мияу, ди.
Мин һәрвакыт
Уяу, ди.

Май бирмиләр
Миңа-ау, ди.
Мияулый да
Мияулый,
Хуҗалардан
Май даулый...

Ачканда да,
Мияу, ди.
Япканда да,
Мияу, ди.
Мияулап ул
Туялмый,
Мияулавын
Тыялмый.

Нәрсә соң бу?
Кем аңлый?
Алмазларның
Ишекләре
Бертуктаусыз
Мияулый!..

Мияуламый
Түзәчәк,
Мияулаудан
Бизәчәк,
Бер бизәчәк
Ничек тә,
Май бирсәләр
Ишеккә!

## Санарга өйрәнәбез

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Санарга өйрәнәбез.
Әллә никадәр сан белеп
Кайтабыз өйләргә без.

Без саныйбыз да саныйбыз,
Саный-саный арыйбыз.
Ялгышып та алгалыйбыз,
Тагын санап карыйбыз:

Берәү, икәү, өчәү... өчәү,
Аннары дүртәү, бишәү...
Алтау, җидәү, тугыз, унау —
Барысы була ничәү?

Санаган саен саннарым
Күбәя-арта бара.
Тик бу юлы ни өчендер
Бер бармак артып кала.

Берәү, икәү...
Әһә, белдем!
Качып калган бер «сигез».
Менә хәзер саннар белән
Бармакларым бертигез.

Ә дөньяда бөтенесе
Ничә сан була икән?
Бар санны санап бетерсәң,
Ничәгә тула икән?

Әйдә санап карыйк әле!
Куркаклармы әллә без?
Без теләсәк, бөтен санны
Санап бетерәләбез.

Ә сез теләсәгез,— унга,
Йөзгә, меңгә җитегез:
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Ягез, дәвам итегез!

Дәрестә

Дәресләрдә бөтенесен
Кирәк белеп калырга:
Тапкырларга да бүләргә,
Кушарга да алырга!
Әгәр тыңлап утырмасаң,
Өйдә дә укымасаң,
Дәресләрнең иң авыры,
Дәресләрнең и-и-и-иң авыры
Ма-те-ма-те-ма-ти-ка!

Күнегүләр эшлисе бар,
Мәсьәләләр, мисаллар.
Ә мисаллар кайчагында
Чишелмиләр — усаллар!
Эшләсәң өйгә эшеңне,
Кызганмасаң көчеңне,
Дәресләрнең иң җиңеле,
Дәресләрнең и-и-и-иң җиңеле
Ма-те-ма-те-ма-ти-ка!

Мәсьәләләр чишелми дип
Куркып торалармы соң?
«Икеле»гә я «өчле»гә
Укып торалармы соң?
Авырлыкка бирелмәсәң,
Уйларга иренмәсәң,
Дәресләрнең иң кызыгы,
Дәресләрнең и-и-и-иң кызыгы
Ма-те-ма-те-ма-ти-ка!

Үсик әле

Тышта чыдарлык түгел,
Хәтта чыгарлык түгел! —
Туңдыра, өшеттерә,
Кешеләр өшеп керә.

Мәктәпкә укырга йөргән
Зур-зур укучыларга
Рөхсәт итмиләр өлкәннәр
Урамга да чыгарга.

Аларга җай табылган —
Мәктәпләре ябылган!

Ә безгә берни булмый!
Берни булмый,
Чөнки безгә
Бакчага йөрми булмый!

Суыктан куркып торсак,
Өйдә генә утырсак,

Кибетләр ябылыр иде,
Заводлар туктар иде,
Сыерлар савылмас иде,
Трамвайлар йоклар иде.

Урамнар буш калыр иде,
Өйдән чыга алмасак.
Әллә ниләр булыр иде,
Без бакчага бармасак...

Шуңа күрә безгә әле
Бакчага йөрми булмый.
Укучылар ятсын өйдә,
Ә безгә берни булмый!

Укучылар булыйк инде,
Үсик әле тагы да,
Без дә шунда утырырбыз
Өйдә — җылыда гына!

## Югалган хәрефләр

(*Биш табышмак*)

1

Мич почмагын
Сөзә-сөзә,
Авыртуга
Түзә-түзә,
Ак маңгаен
Бәрә-бәрә
Үсә безнең
Бөдрә бәрә...

2

Табыныбыз
Ай-яй-яй бай:
Катык та сөт,
Каймак та май.
Бөтенесе
Кунак сые!
Рәхмәт инде
Сиңа, сые...

3

Әллә юри

Котыртмакчы,
Әллә инде
Куркытмакчы,
Булмаса да
Бер дә көче,
Өргән була
Безгә көче...

4

Оя дер-дер-
Дер-дер килә,
Әллә инде
Дер-дер көлә?!
Ахры, чак-чак
Куркып куя
Шул ояда
Батыр куя...

5

Бу — бүре дип
Уйламагыз,
Ә шулай да
Уйнамагыз!
Булмасам да
Үзем бүре,
Минем башта
Бүре бүре...

## Абый итеге

Юлларны ул
Мең кат узган,
Юлларда ул
Мең кат кызган,

Туздырган ул
Күпме тузан?!

Йөргән чакта
Тиз йә акрын,
Узгандыр ул
Йөз, мең чакрым!

Менә дигән
Үзе һаман,
Кала әле
Эзе һаман!

Тора һаман
Шык-шык итеп —
Солдатныкы
Шул ул итек!

Ә бит үзе
Иске итек —
Торам шуңа
Исем китеп!

Искермәгән
Иске итек!

## Әби белән Нәби

Нәби бик эшчән,
Курыкмый эштән:
Каз куа иртән,
Су ташый кичтән.

Әбисе аңа:
— Син уң кулым,— ди,—
Рәхмәт, улым,— ди,—
Дәү үс, улым! — ди.

Кибеттән чаптар
Алган да әби
Нәбигә бирә:
— Ал, улым, мә! — ди.

— Шәп ат! — ди Нәби.
Аннары өсти:
— Әби, зур рәхмәт,
Әби, дәү үс! — ди.

Шушы сүзеннән
Нәни Нәбинең
Түбәсе күккә
Тия әбинең.

## Алмазның гаражы

Алмазларның өендә
Бүлмә тулы машина:
Менгән диван өстенә,
Менгән шкаф башына.

«ГАЗ» да,
«МАЗ» да,
«КамАЗ» да,
«БелАЗ» да бар
Алмазда.

Алмаз менә ни өчен:
«Гараж бу!» — ди өй эчен.

Кирәк нинди машина?
Гаражда бар бары да:
Кызылы да, агы да,
Эресе дә, вагы да...

— Болар гына җитми,— ди.
Сорый әле тагы да.
Үзе йөри нигәдер
Велосипедта гына.

Сорасаң, җавап таба:
— Бик тә йөрер идем,— ди,—
Ярамый — шоферлыкка
Укыйсым бар минем,— ди.

## Кызык!

Иртәсен дә,
Кичен дә
Бармак — борын
Очында,
Җиң дә — борын
Очында!
Кызык алар!
Белмим, ник
Узыналар?
Белмим, ник
Сузылалар?
Белмим, ник
Кызыгалар
Минем шул
Борыныма?
Читкәрәк
Борылырга
Өлгерми
Борыным да.
Гаеп юк
Борынымда —
Ул гел үз
Урынында!

## Күңелле тәнәфес

Чылтырый кыңгырау
Дәрестән чыгарга.
Кыңгырау — тәнәфес
Яратучыларга!

Басыйк та бергәрәк,
Тән языйк бергәләп:
Бер, ике, өч...
Көчәйсен безнең көч!
Тик тормау — безнең эш.
Яшәсен күңелле
Тәнәфес!

Сафлансын бүлмәбез,
Чистарсын, ялт итсен!
Китаплар, дәфтәрләр,
Каләмнәр ял итсен!

Ял кирәк безгә дә,
Ял кирәк сезгә дә:
Бер, ике, өч...

Ә син, көч, тәнгә күч,
Уйнасын тәндә көч!
Яшәсен күңелле
Тәнәфес!

Көч кирәк укырга,
Көч кирәк һәр эшкә.
Чылтырый кыңгырау —
Монысы... дәрескә.

Ял итеп алдык без,
Сизми дә калдык без —
Ял тәмам ич!
Башлар — саф, тәндә — көч!
Бездәдер һәммә көч!
Яшәсен күңелле
Тәнәфес!

### Алмаз, үгез һәм мөгез

Алмаз күршеләрдәге
Үгезне күралмый,
Чөнки Алмаз аларга
Ялгызы keралмый.

Тик тамчы да курыкмый
Үгезнең ул үзеннән.
Кергән саен зарлана,
Күргән саен зарлана
Үгезнең мөгезеннән:

— Мине күрсә мөгезли,
Ай-яй усал мөгез,— ди,—
Мөгезен дә тыялмый,
Бигрәк юаш үгез,— ди.

### Дөнья балаларының кешелеккә әйтер сүзе

Дәшәбез сезгә, өлкәннәр,
Без — дөнья балалары!
Балаларның сарылары,
Аклары, каралары.

Әрни әле сугышлардан
Калган Җир яралары —
Төзәлсен иске яралар,
Булмасын яңалары!

Сез «чәчәкләр» дисез безне —
Аларны сулдырмагыз!
Сез бит көчле — сугышларны
Моннан соң булдырмагыз!

Өзмәгез ул чәчәкләрне —
Безсез нишләр Киләчәк?!
Без булмасак, Җиребез бит
Суыначак, кибәчәк.

Безсез ятим калачак Җир,
Әйләнәчәк җансызга!
Җансыз, үле планеталар
Галәмдә күп ансыз да.

Явызлык аркасында Җир
Газаплар күп күргәндер.
Өзгәләмәгез сез аны —
Ул болай да бердәнбер!

Бер югалтсак, булмас аны
Алышып яңасына —
Мәрхәмәтлерәк булыгыз
Җиргә — күз карасына!

Алсулансын алсу алма
Балаларның учында.
Җир байрагы — Алсу Кояш
Аллансын баш очында!

Кояшлы булырга тиеш
Безнең һәрбер иртәбез.
Без сездән ТЫНЫЧЛЫК белән
БӘХЕТ таләп итәбез!

Киләчәкнең зур сурәтен
Ясыйсы килә безнең.
Җырдан гөрләвен телибез
Әйләнә-тирәбезнең!

Ләкин әле җиребездән
Кан һәм яшь исе килә.
Юк, үләргә теләмибез —
Безнең яшисе килә!

Я-ш-и-с-е к-и-л-ә!!!

Минем сеңелкәшем!

Әни миңа кибеттән
Алып кайткан сеңелкәш...
Ә мин инде кайчаннан
Көткән идем энекәш!

Әнием алдалаган,
Ул мине аңламаган.

Мин бит өйдә берүзем
Уйнаудан туйган идем,
Энекәшкә исем дә

Әзерләп куйган идем!

Уенчыкларымны да
Аңа саклаган идем,
Хәтта машиналарны
Бер дә ватмаган идем.

Энекәш була диеп,
Шундый шатланган идем,
Хәтта малайларга да
Бераз мактанган идем.

Миңа сеңелкәш түгел,
Энекәш кирәк иде...
Әни кыз алып кайткан —
Бу әни бигрәк инде!

Үзе әле бәләкәй,
Үзе әле елак та!
Әни әйтә: «Малайлар
Елыйлар,— ди,— ыграк та!»

Ә сеңлемме?
Ята ул
Елаган булып кына,
Җырлаган булып кына...

Ә шулай да чаптыра!
Килми торсак чак кына,
Әтине дә чаптыра,
Әнине дә чаптыра
Һәм мине дә чаптыра!
Нәрсәләрдер таптыра.
Ә без килсәк —
Яктыра!

Җибәрми үз яныннан,
Янында гел сак тора.
Болай ук кирәкми лә —
Сеңлем бераз арттыра!

Сүз әйтмәгез —
Арттырсын!
Сүз әйтмәгез —
Чаптырсын!

Үземнең сеңлем бит ул!
Сөекле сеңлем бит ул!
Сөйкемле сеңлем бит ул!

Мондый сеңлем булгачтын,
Кирәкми энекәш тә —
Биш энекәшкә тора
Шушы бер сеңелкәш тә!

## Бабайлар нинди була?

— Бабайлар нинди була?

— Алар сакаллы була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар мыеклы була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар күзлекле була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар таяклы була!

— Юк шул, юк, алай булмый,
Юк, андый бабай булмый!

Менә минем бабамның
Сакалы да юк аның,
Мыегы да юк аның,
Күзлеге дә юк аның,
Таягы да юк аның!
Соң шулай булгач инде
Бабайлар нинди була?

— Алар сакалсыз була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар мыексыз була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар күзлексез була!

— Бабайлар нинди була?
— Алар таяксыз була!

— Бабайлар нинди була?

(*дәвам итегез*)

Без таган атынабыз!

Без таган атынабыз!
Биеккә атлыгабыз!
Кояшка атылабыз!
Без таган атынабыз!

Атындыр син
Безне, таган,
Кояшка һәм
Айга табан!

Без таган атынабыз!
Очып та китәр идек,
Ныгытып тотынабыз!
Без таган атынабыз!

Син бит, таган,—
Безгә канат,
Очырт безне
Кабат-кабат!

Без таган атынабыз!
Канатланып очабыз!
Без Җир шарын кочабыз!

Без таган атынабыз!

Әйдә, таган,
Канат кагын,
Атындыр син
Безне тагын!

Йөрибез!

Автобуста йөрибез,
Троллейбуста йөрибез,
Бигрәк оста йөрибез,
Җәй дә, кыш та йөрибез,
Билет алып йөрибез,
Күбрәк бушка йөрибез,
Теплоходта йөрибез,
Самолетта йөрибез,
Самокатта йөрибез,
Хәтта атта йөрибез,
Пар атта да йөрибез,
Корабта да йөрибез,
Утырып та йөрибез,
Тотынып та йөрибез.
Ябышып та йөрибез,
Ярышып та йөрибез,
Кысырыкта юри без
Кысылып та йөрибез,
Ниләр генә күрмибез,
Тик барыбер йөрибез,
Җәяү генә йөрмибез.

Ләкин барыбер күбрәк
Җәяү йөрергә кирәк!
Ник икәнен үзегез
Җәяү йөргәч күрерсез.
Шуннан соң үзегез дә
Күбрәк җәяү йөрерсез!

Күрерсез!

Без йолдызлар саныйбыз

Булат белән ятабыз,
Йолдызлы күккә карап,
Булат белән ятабыз,
Шул йолдызларны санап!

Булат белән йолдызларны
Без ярышып саныйбыз.
Ә иң башта йолдызларның
Эреләрен сайлыйбыз.…

Ул йолдызларны санап
Бетерәчәкбез тиздән:
Артты да менә йөздән,

Җиде йөздән, бер меңнән,
Ике меңнән, ун меңнән...

Бик күп лә бу йолдызлар,
Күпмелеген кем белгән?!

Ә йолдызлар нигәдер
Биешә башладылар,
Селкенә  башладылар,
Сикерә башладылар,
Җемелди  башладылар,
Дерелди  башладылар,
Чуалышып  беттеләр,
Буталышып  беттеләр.…

Курыкты бугай алар,
Санап бетерерләр дип,
Санап бетерерләр дә
Кызык иттерерләр дип.

Без дә санап тормадык,
Күзләр дә арган иде.
Юкса санап бетерергә
Аз гына калган иде!

Әни, мин көчек күрдем!

Әни, мин уйнаганда
Көчек күрдем урамда.

Әни, ул туңган иде,
Урамда кунган иде.

Әни, салкын яңгырда
Ул бик күшеккән иде,
Ул бик ачыккан иде
Һәм бик талчыккан иде.

Әни, ул улый иде,
Ул шулай елый иде,
Ул чынлап елый иде,
Ул ныклап елый иде —

Үзем ишеттем, әни.
Мин үзем карап тордым,
Шуңа кичектем, әни.

Мин аны бик кызгандым —
Яшьләре ага иде.
Әни, аның яшьләре
Асфальтка тама иде.

Аны, әни, яңгырда
Кемдер ташлап калдырган,
Алдаштырып калдырган,
Адаштырып калдырган...…

Әни, туңганга микән,
Ул бик дерелди иде.
Салкын тисә, ул көчек
Тышта терелми инде.

Нишләр инде ул анда,
Берьялгызы урамда?

Ул елыйдыр әле дә,
Дерелдидер тәне дә.
Иртәгә үк үләчәк,
Калдырсаң бу хәлендә...

Әнием, шул көчекне
Алып керик әле, ә?!

## Әниемә ял кирәк!

Әй, кызлар!
Әй, малайлар!
Тик торыгыз, тыныгыз!
Аз гына да чыкмасын
Сезнең  тавыш-тыныгыз!

Кошкай, син дә җырлама!
Пескәй, син дә мырлама!
Бозау, син дә мулама!
Акбай, син дә улама!
Шаулама син дә, тирәк! —
Әниемә ял кирәк!

Ул эшеннән
Туктасын!
Тизрәк ятып
Йокласын!
Ял итсен,
Көч тупласын!

Әнием, син болай да
Ял итәсең бик сирәк!
Сиңа да бит ял кирәк!

Арыгансың бит инде,
Әнием, ял ит инде —
Мине йоклат та тизрәк!

## Печән өсте

Авылда җәй.
Җәйге болын.
Печән өсте.
Печән чапкан
Абыйларга
Ай-яй эссе!
Печәнчеләр
Бу эсседә

Янып пеште.
Ярый әле
Аз булса да
Җилләр исте.

Печән исә
Биек кибән
Булып үсте.
Күренми дә
Биектәге
Кибән өсте.

Кибән өсте
Нәкъ тау төсле!
Качып кына
Менеп киттек
Кибәнгә без.
И уйныйбыз,
И уйныйбыз,
Кинәнәбез!

Тик кибәннең
Асты өскә
Килә язды.
Үзебезнең
Түбә күккә
Тия язды!

Безнең хәтта
Буй да бераз
Үсә төште —
Безнең якта
Бигрәк
Биек
Печән өсте!

Табышмак-шигырь

Нәкъ турист шикелле —
Кайда да йөри ул:
Юлбарыс шикелле
Тайгада йөри ул.

Нәкъ юлчы шикелле
Юлда да йөри ул.
Кырмыска шикелле
Кулда да йөри ул.

Трамвайга утырып,
Калада йөри ул.
Җәйраннар шикелле
Далада йөри ул.

Йә, атка атланып,
Авылда йөри ул.
Бернидән курыкмый —
Давылда йөри ул.

Абыем шикелле
Эштә дә йөри ул.
Әбием шикелле
Өйдә дә йөри ул.

Көндез дә йөри ул,
Төнлә дә йөри ул.
Нәкъ циркач шикелле
Стенада йөри ул.

Безнең белән класста,
Кинода йөри ул.
Кесәгә салгачтын,
Кесәдә йөри ул.

Нәкъ песи шикелле
Өстәлдә йөри ул.
Самолет шикелле
Өстә дә йөри ул.

Космонавт шикелле
Җиһанда йөри ул.
Читлеккә йозаклап
Куйсаң да йөри ул.

Водолаз шикелле
Суда да йөри ул:
Суга чулт итә дә
Чума да йөри ул.

Йоклаусыз йөри ул,
Туктаусыз йөри ул!

Арыдым дип тормас —
ул тиктормас!

Оча торган чаңгылар

Оча гына
Чаңгылар —
Алар гүя
Җанлылар!

Сикәлтәдән чаңгылар
Очып китә бик биек.
Шуңа тизрәк төшәбез,
Очып китмәсен диеп!

Әгәр җиргә төшмәсәң,
Очар алар ары да.
Бар икән чаңгыларның
Оча торганнары да!

Сез дә бәхетегезне
Берәр сынап карагыз!
Әти-әниегездән
Сез дә сорап карагыз!

Хәлегезгә
Керерләр,
Бәлки алып
Бирерләр?!

## Кем ничек өлгерә?

Өлгергәннәр
Карлыганнар —
Алар инде
Каралганнар!

Алсуланган
Алмалар да! —
Була өзеп
Алгаларга.

Яшелләнгән
Йөзләп кыяр! —
Әни тиздән
Тозлап куяр.

Кызарганнар
Җиләкләр дә! —
Кереп тора
Чиләкләргә.

Саргайганнар
Кавыннар да! —
Килер алар
Табыннарга.…

Саргаеп та,
Кызарып та,
Каралып та
Өлгерәләр.

Өлгердек дип
Белдерәләр,
Өзегез дип
Белдерәләр.…

Ничек җыеп
Өлгерәләр?!

## Сайрый торган агач

Мин агач утырттым,
Ул күккә чөелде.
Үземнән дә бигрәк
Кошларым сөенде.

Ул кошлар агачта
Туйганчы тирбәлде —
Агачым шатлыктан

Сайрап ук җибәрде!

Аптырап калдым мин
Агачны тыңлагач —
Утырткanмын икән
Сайрый торган агач!

Сандугачлы агач!

## Мин дә катнаштым!

Быел авылда
Мин басу күрдем.
Ипинең ничек
Үскәнен белдем.

Шофер абыйга
Утырып йөрдем,
Хәтта руленә
Тотынып йөрдем!

Иген кырына
Бардым мин көн дә.
Урып-җыюда
Катнаштым мин дә!

## Җәйнең яшел аты

Атландым да ялт кына
Җәйнең яшел атына,
Җәй буйлап чаптым гына
Мин талпына-талпына!

Малайлар, кызлар кала
Су буенда кайнашып,
Чишмәләр чыңлап кала,
Кошлар кала сайрашып.

Кул изи печәнчеләр,
Гөрләп кала болыннар.
Безнең арттан иярә
Болындагы колыннар.

Җәйнең матурлыклары
Кала күренеп кенә,
Аз гына күренә дә
Кала күмелеп кенә.

Их, атым арсын иде,
Акрынрак барсын иде!

Кире бормакчы идем,
Туктап тормакчы идем,

Тик җәй аты туктамый,
Туктап бер дә ял итми,
Туйганчы бер утламый...

Әй чабабыз!
Тик алда
Сары бер ут күренде.
Җәйнең аты кинәттән
Сарыга әверелде.

Бигрәк җитез барганбыз,
Сизмичә дә калганбыз —

Атым белән бергә без
Көзгә килеп кергәнбез!

## Болытлар

Болытлар безнең өстә —
Төрлесе төрле төстә,
Төрле-төрле рәвештә,
Килә алар әвеш тә,
Килә алар тәвеш тә.

Йөзәләр микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Сөзәләр микән алар?

Шуалар микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Куалар микән алар?

Очалар микән алар?
Әллә инде бер-берсен
Кочалар микән алар?

Ник шулай чабалардыр?
Мөгаен аралардыр!
Арыганда тиз генә
Җилгә утыралардыр.

Юкса арырлар иде,
Туктап алырлар иде,
Ял итә-итә генә
Җайлап барырлар иде.
Арыгачтын, бөтенләй
Туктап калырлар иде.

Ә болытлар һаман да
Очалар да очалар.
Җилгә утырып баргач,
Арымыйлар ич алар!

## Сабантуй кызык булды

Сабантуй кызык булды.
Сабантуй озак булды.

Без өч-дүрт кат чәйләдек.
Малайлар белән бергә
Унар сагыз чәйнәдек.

Эссе булган өченме,
Дүрт шешә су эчелде.

Чыннан да, эссе булды —
Нәкъ мунча төсле булды.

Шуңа күрә әйрән дә
Эчтек эссе бәйрәмдә.

Лимонад эчтек алдан,
Компотка күчтек аннан.

Шуннан квас эчтек без —
Шабыр тиргә төштек без.

Сабантуй ямьле булды.
Сабантуй тәмле булды.

Ул безгә бик ошады.
Көнбагыш белән тулы
Ике кесә бушады.

Ашадык йөз чикләвек,
Шуның белән чикләндек.

Аннан алма ашадык,
Бераз бал да ашадык.

Вәт ул тәмле бал иде.
Тагын исәп бар иде,

Тик инде күптән икән
Сабантуй беткән икән...…

Сабантуй мәзәк булды!
Җитмәде — әзрәк булды!

Кара инде бу гөлне!

Бөтен бүлмә
Ап-актан,
Гөлем ак чәчәк
Аткан!

Моңарчы ник
Атмаган?
Мөгаен, җай
Тапмаган.

Бүлмәдә бик
Күңелле!
Кара инде
Бу гөлне!

Хәйләкәрләнеп
Яткан,
Чәчәк атар чак
Тапкан —

Нәкъ әни
Туган көнне

Тоткан да
Чәчәк аткан!

Зоопаркта ниләр бар?

Зоопаркка бардык без,
Аптырашта калдык без:

Зоопаркның эчендә
Тыпырдаша
Тояклар,
Тырпаеша
Колаклар,
Тырпаеша
Тырнаклар,
Дөп-дөп итә
Аяклар,
Әй болгана
Койрыклар,
Әй селкенә
Мыеклар,
Ялкын төсле
Яллары,
Әй елкылдый
Йоннары;
Әй кызык
Борыннары,
Бормалы
Мөгезләре,
Сөзәм диләр
Үзләре,
Сузылганнар
Томшыклар,
Киерелгәннәр
Түшләр,
Тешләргә тора
Тешләр —

Зоопаркта
Шундый эшләр!

Диңгезләр нинди төстә?

— Кара диңгез бармы?
— Бар!
— Сары диңгез бармы?
— Бар!
— Кызыл диңгез бармы?
— Бар!
— Ә ак диңгез бармы?
— Бар!
— Зәңгәр диңгез бармы?
— Юк!

— **Кара** диңгез юкмы?

— Юк!
— **Сары** диңгез юкмы?
— Юк!
— **Кызыл** диңгез юкмы?
— Юк!
— Ә **ак** диңгез юкмы?
— Юк!
— **Зәңгә**р диңгез юкмы?
— Бар!

Серле кара маҗаралары

Бар җирдә серле кара,
Тылсымчы сәер кара!
Әгәр дә ышанмасаң,
Син әнә үзең кара!

Кара инде, кара дим:
Кара бит кара иде,
Хәзер әнә **кара**бин.

Һаман үзгәрә бара,
Үзгәрә тора кара,
Күпме генә карама —
Хәзер әнә **кара**ма.

Бер карасаң, **кара**гай,
Бер карасаң, **кара**гач,
Тагын бер кат карагач,
Була кара **кара**ндаш.

Яисә ул кинәттән
Әйләнә **кара**гатка.
Карагатка үрелсәң,
Әйләнә **кара**ватка.

Берчак ул әй каралды —
Булды куйды **кара**ңгы.

Кара, сизми дә торам:
Бу караңгы — кара төн.

Кермик кара артыннан,
Чөнки анда **кара**нтин.

Карачы син, карачы:
Җитмәсә, юл өстенә
Утырткannар **кара**чкы!

Ә кап-кара карачкы
Бигрәк усал кара ул —

Без керә башлауга ук
Кычкырачак **кара**выл!

Авылны уятачак,
Кергән, дип, безгә **кара**к!
Кермик инде — шигырь дә

Сузылды озак**кара**к!

Яле, исәпләп кара,
Шигырьдә ничә кара?

### Таш, чыпчык һәм алма

Агачка кунган чыпчык,
Алмага кунган чыпчык —
Минем иң зур алмага,
Алланасы алмага,
Балланасы алмага
Кунган бит ул
Чукынчык!

Гел карап үтә идем,
Пешкәнен көтә идем!
Чык бакчадан,
Чык, дим, чык!
Юк, кузгалмый да чыпчык!
Әмәлен ләкин таптым —
Агачка мин таш аттым.
Юк ла, алмага аттым,
Чынлап, аңа да аттым.
Юк ла, чыпчыкка аттым!
Ахрысы, юкка аттым...…

Ташым да очып китте —
Чыпчык та очып китте,
Алма да очып төште,
Ямь-яшел килеш төште.

Вәт кызарды,
Вәт пеште!..

### Боек үгез

Утарда яши үгез.
Беркемгә дәшми үгез.

Ул дөньяга
Ачулы,
Көтә капка
Ачуны,
Тизрәк чыгып
Качуны.

Басып тора
Ул оеп,
Бик күңелсез,
Бик боек.

Мөгезләргә
Эш тә юк,
Эш булмагач,
Көч тә юк.

Мондый тормыш үгезгә
Бөтенләй хаҗәт түгел,
Болай яшәү үгезгә
Бөтенләй мәзәк түгел.

Болай ул беркемгә дә
Күрсәтә алмый көчен —
Боек ул
Шуның өчен!

### Йөгәнсез чаптар

Чаптар ясадым беркөнне —
Җитез, көчле иттердем,
Ә ялларын диңгездәге
Дулкын төсле иттердем.

Елгыррак булып чыккан ла —
Үзен күпме сакладым,
Тик барыбер дәфтәремнән
Чыгып чапкан чаптарым!

Ясамаганмын йөгәнен,
Куймаганмын бәйләп тә.
Шуңа күрә качкан да ул —
Качуы бик әйбәт лә!

Әнә анда бер көтү ат
Утлап йөри болында.
Ә берсе уйный-уйнаклый,
Торалмый бер урында.

Шул елгыры, йөгәнсезе,
Мөгаен, мин ясаган.
Дәфтәр түгел, болын да тар —
Бер дә юкка качмаган!

Йөрсен, әйдә, рәхәтләнеп,
Йөгән әле табылыр.
Тик табылса да, йөгәнне
Кидертмәс ул барыбер!

Аңа беркем якын бармый,
Күргәч ничек йөргәнен!
Ярый әле кидертергә
Онытканмын йөгәнен!

### Канатлы ут

Килеп кунды кулыма
Якты бөҗәк — җанлы ут.
Кара төндә учымны
Яп-яктыртып янды ут!

Күпме ут күргәнем бар!
Җирдә яна төрле ут!
Диңгез буенда гына
Ул канатлы, тере ут!

Кечкенә фонарь кебек,
Канатлы фонарь кебек,
Яктырак янар кебек,
Ныграк үссә тагын да!

Очып кит син, җанлы ут,
Канатыңны кагын да!

Икенче килүемә
Үсеп зур булыр әле,
Зур фонарь булыр әле,
Тирә-якны тере ут
Яктыртып торыр әле!

Килгәч монда тагын да,
Мин аны шул чагында
Алып кайтырмын өйгә —
Чын фонарь чаклысын да.

Диңгезне сагынырмын
Мин аның яктысында!

## Яңгыр

Кешеләр
Яңгыр көткән,
Яумаган
Яңгыр күптән.

— Яңгыр кирәк! — дигәннәр,
— Ява сирәк! — дигәннәр,
— Яусын тизрәк! — дигәннәр.

Яңгыр
Ялындырмаган,
Көттереп тә тормаган.

Яңгыр
Ява башлаган,
Шактый явып ташлаган.

Ә кешеләр,
Өркешеп,
Этешеп тә
Төртешеп,
Чатырларын
Ачканнар,
Чатыр чабып
Качканнар!…

Ә яңгыр
Үпкәләгән,
Әз генә
Сипкәләгән,
Бер-ике тамган,
Аннан
Тиз генә

Китеп барган.
Кешеләр карап калган!

## Үзебез ясаган машина

Шәп машина ясадык:
Кабинасын ясадык,
Әрҗәсен дә ясадык,
Ясадык фарасын да.
Машинага ни кирәк —
Ясадык барысын да!

Ялт итте машинабыз,
Йөрергә ашыгабыз!

Машинаны без йөртеп
Карадык әле генә —
Тик йөрми әле менә.

Шуңа этеп йөртәбез,
Әй артыннан этәбез,
Этәбез дә төртәбез,
Арып-талып бетәбез,

Тик барыбер этәбез.

Йөрер өчен, машина
Тиеш йөри белергә.
Шуңа күрә без аны
Өйрәтәбез  йөрергә!

## Шүрәле

Ишеттегезме әле?
Сез белмисездер әле —
Бүген безнең кибеткә
Китергәннәр шүрәле!

Шундый кызык шүрәле,
Шүрәлене күргәчтен,
Рәхәтләнеп көлмәле!

Күрдем аны мин үзем:
Әй тырпайткан мөгезен,
Кимәгән эшләпә дә.
Бармакларын, мөгезен
Ул әллә нишләтә дә
Әй көлдерә өзлексез!
Үзе никтер күзлексез.
Ә шулай да ул шүрәле
Күзлексез дә бик ямьсез,
Күзлексез дә иләмсез.

Унбиш тиенлек кенә —
Түгел үзе кыйммәт тә.
Ә үземе?

Ә үзе
Чын шүрәле, әлбәттә!

Олылар һәм балалар,
Очсызга күрәме соң,
Кызыкка күрәме соң,
Чират торып алалар
Тукайның «Шүрәле»сен!

Җилләр исте куяннан!

Машинада барганда,
Бер дә уйламаганда,
Без бер куян
Күреп алдык,
Тик аз гына
Күреп калдык —
Әй тиз җилдерә иде —
Гүя җил генә иде!

Әти күреп калган икән
Колакларын,
Ә мин күрдем ул куянның
Аякларын.

Энем исә
Койрыгын да
Күрмәгән,
Күрергә
Өлгермәгән.

«Куян кайда, әйтегез! — ди.—
Яңадан күрсәтегез!» — ди.

Куянны без
Каян табыйк,
Куянны без
Каян алыйк?

Ничек тотыйк аны без?
Юк инде куяныбыз!
Борчылма бер дә, энем.
Ис китми менә минем.

Әле менә ул куянны
Уйлап куям:
Куян иде микән әле
Ул ак куян?!

Энекәш кирәк миңа!

Сезгә рәхәт!
Берегез дә
Минем хәлдә түгел сез.
Беләсезме?

Өйдә миңа
Кызык түгел, күңелсез.

Елыйсы да килә кайчак,
Уйлап ятам-ятам да:
Юк шул минем абыем да,
Юк шул минем апам да,

Сеңлем дә, энем дә.
Бергә-бергә уйныйсым
Бик тә килә минем дә.

Ә күршеләр гөр килә:
Уйныйлар, шаяралар.
Алар күп шул, күмәк шул —
Шуңа да шаян алар.

Бер иптәш кирәк миңа,
Энекәш кирәк миңа!

Яратыр идем мин аны,
Хәтта елак булса да.
Бакчага да илтер идем,
Хәтта ерак булса да.

Энем белән мин урамга
Уйнарга чыгар идем.
Әгәр мине тыңламаса...…
Ничек тә чыдар идем.

Әтиләр бит ничә кабат,
Алабыз, дип алдыйлар.
Бердәнбер малайларына
Бер энекәш алмыйлар.

Күңелсез өйдә миңа,
Уенчык нигә миңа?!

Бергәләшеп уйнарга
Бер иптәш кирәк миңа —
Берәү генә булса да,
Ямьсез генә булса да,
Елак кына булса да
Энекәш кирәк миңа!

Җайдаклар

Безнең якның малайлары
(Әйтү түгел мактанып)
Тәпи йөри башлау белән
Чаба атка атланып!

Атларда чаба малайлар —
Атлары да атлары!
Малайларның әле шулай
Чаба торган чаклары.

Атлана да чаба алар
Иярсез дә йөгәнсез.
Бу инде — безнең малайлар
Чын җайдаклар, дигән сүз.

Чаба алар, оча алар,
Калмый хәтта эзләре.
Канатлы әллә атлары,
Әллә инде үзләре.…

Кызыйлар кала кызыгып,
Энекәшләр — көнләшеп.
Әй оча, оча малайлар
Абыйларга тиңләшеп.

Кирәк булса, очар алар
Йолдызларга, айларга…
Кемдер атларга соклана,
Ә кемдер — малайларга!

Кызык кеше

Бәләкәй чакта мәктәптә
Ул бик әйбәт укыган.
Кызлар белән утырса да,
Бик тәртипле утырган.

Ә шулай да кайчагында
Дәресе калгалаган,
Аннан
Математикадан
«Өчле»ләр алгалаган.

Еларга яратмаса да,
Аны еш елатканнар,
Еш кына елатсалар да,
Үзен бик яратканнар.

Ул әле дә үзен кеше
Ярата диеп белә.
Килешмәсә дә, йөри ул
Эшләпә киеп кенә.

Бик аз сүзле —
Бер дә юкка
Бик көенми ул артык.
Шөгыльләнми спорт белән,
Шуңа бераз юантык.

Бераз гына юан булу
Аңа бик тә килешә.
Кызлар гына, аны күргәч,
Ни өчендер көлешә.

Ул бик озын буйлы түгел
Һәм бик үк кыска түгел.

Уйнаган була гармунда,
Ләкин бик оста түгел.

Бик оста уйнамаса да,
Ул күңел биреп уйный.
Һәм үзен, ни сәбәптәндер,
Талантлы диеп уйлый.

Балалар аны тиз таный,
Ә күбесе белми дә.
Шигырь укып көлдерә ул,
Үзе никтер көлми дә.

Сәхнәгә бер чыгып басса,
Сибә генә борчакны.
Ул үзе начар да түгел,
Шәп тә түгел ул чаклы.

Ул ипи дә бик ярата,
Үзе үстермәсә дә.
Хәтта кәнфит ашый!
Хәер,
Ансы башка мәсьәлә...

Шундый кызык бер кеше ул!
Кем дисезме?
Мин ул, мин —
Шагыйрь Роберт Миңнуллин.

### Качып калган яңгыр

Яңгыр явып
Үткән иде,
Күптән инде
Беткән иде,
Күптән узып
Киткән иде...…

Мин яңгырдан
Качкан идем.
Мин каенның
Төбенә үк
Баскан идем.

Шул каенга
Ялгыш кына
Тиеп киттем —
Нигә генә
Алай иттем?!

Каен куйды
Шыгырдап,
Яңгыр койды
Шыбырдап.

Калдым яңгыр
Астында.

Югыйсә бит
Качтым да...…

Хәйләкәр икән яңгыр,
Карачы, карасана! —
Качып калган булган ул
Яфраклар арасына!

## Сандугач белән малай

— Кунгансың
Куакка,
Кайттыңмы
Кунакка?

— Кайттым
Бөтенләйгә.
Әй лә...…
Бөтен җәйгә!

## Мияу!

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.

Йомшак синең йоннарың,
Җылы синең туннарың.

«Мияу, мияу!» бар сүзең,
Ялкау да әле үзең.

Белмим инде, ни өчен
Бернигә китми исең?

Кызыксындырмый ни ау,
Кызыктырмый ни уйнау.

Мияулау бөтен эшең.
«Мин сине мияу!» — дисең.

Нигә инде күз буяу? —
Үзем дә сине «мияу!»

## Тирәкләргә җил кирәк!

«Их, җил чыксын иде дә
Безне уятсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безне уйнатсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безне кузгатсын иде,
Их, җил чыксын иде дә
Безгә сүз катсын иде!..

Шыбыр-шыбыр —
Шыбырдап,

Шыгыр-шыгыр —
Шыгырдап
Сөйләшкән булыр идек,
Серләшкән булыр идек,
Җилләнеп алыр идек,
Сафланып калыр идек!
Җилсез булмый,
Җил кирәк!» —
Диеп уйлый тал-тирәк.

### Куркак туп

Тупның бөтен курыкканы
Кадак белән энә, без!

Ә менә без тупның нигә
Курыкканын беләбез!

### Очасым килә

— Әтием, минем
Очасым килә!
Ак болытларны
Кочасым килә!

— Син инде, кызым,
Очасың күптән.
Кайтып кермисең
Болытлы күктән.

— Кошлар янында
Тирбәнер идем,
Канатларым юк
Нигәдер минем.

— Канатларың бар,
Кызым, синең дә.
Син аны үзең
Сизмисең генә.

— Йолдызларга да
Менәсем килә.
Анда ниләр бар —
Беләсем килә.

— Гомер юлларың
Әле бик озын —
Йолдызларга да
Очарсың, кызым!

### Дер-дер куян

Куян ак туннан,
Ә үзе туңган.

Ул ап-ак булган
Әллә туңганга?
Ә-ә-ә, курыкканга.

Дерелди дер-дер......
Өшегәнгәдер,
Дерелди дер-дер......
Өреккәнгәдер.
Дер-дер киләдер
Шуңа күрәдер —
Дер-дер......

Әй лә,
Белмим лә.
Ник дерелдәвен
Үзе беләдер-
Дер-дер......

Љрә белүче шкаф

Барыбыз беткәч ятып,
Шкафыбыз бервакыт

Әй өрергә тотынды —
Алды бөтен котымны!

Өрә-өрә, туктамый —
Беребез дә йокламый.

Ачкан идем ишеген,
Килеп чыкты көчегем!

Койрык

Карале, кара, кара:
Бер койрык китеп бара.

Ул алан буйлап бара,
Уйнаклап, уйнап бара.

Боргаланган да була,
Сыргаланган да була,

Озынлыгын күрсәгез,
Йомшаклыгын күрсәгез,

Шунда ук таң калырлык,
Күзнең явын алырлык!

Ник йөридер кагылып —
Шул төлкегә тагылып!

Пешмәгән

Сатып алдым мин карбыз.
Тәмле микән? Карарбыз!

Турадым өйдә ваклап.
Ә эче...… эче ап-ак.

Тукта, тукта, туктагыз —
Пешмәгән бит бу карбыз...…

Ә бит күпме сайладым?!
Бик-бик күпне сайладым.

Чирткәләгән дә идем,
Төрткәләгән дә идем,

Каккалаган да идем,
Суккалаган да идем...…

Менә бит нишләгәнмен —
Үзем дә пешмәгәнмен!

## Туган тел

«Туган телем
Анам теле!» —
Дияр әле
Балалар.

«Туган телем
Балам теле!» —
Дияр микән
Аналар?

## Шигъри әлифба

### Ай

Елмая күктә ай.
Ай-яй биек бу ай!
Айга абыйның да
Буе җитми бугай.

### Әтәч

Күр әле,
Әтәч әнә
Сугыша,
Әтәчләнә.
Гел сугышып
Йөрмәкче,
Малайлардан
Күрмәкче!

### Болыт

Очып йөри
Өстә болыт.

Күренә ул
Аю булып,
Бүре булып,
Төлке булып —
Очып йөри
Көлке болыт.

### Велосипед

Велосипедым әй җитез,
Тиз генә әгәр йөрсәң.
Ул бит үзе йөри торган —
Педален әйләндерсәң!

### Гөмбә

Таптым мин бер зур гөмбә,
Ләкин юкка тигәнмен.
Әтиемнең эшләпәсе
Икән гөмбә дигәнем.

### Дага белән дуга

Атка кирәк дага да,
Атка кирәк дуга да.

Дугасы — җигәр өчен,
Дагасы — җиләр өчен.

Кайсыгыз җигә ала?
Кайсыгыз җилә ала?

### Елга

Чыккан да ерак юлга,
Ага да ага елга.
Чаба да чаба алга —
Елга туктамый ялга.

### Жираф

Жираф, сиңа
Кыенмы? —
Син бит озын
Муенлы!

### Җиләк

Тибрәндерә җил җиләкне —
Җил әллә җиләктәме?
Шулайдыр шул, җилдән дә

Килә бит җиләк тәме.

3

Үзе хәреф,
Үзе сан —
Бик аз гына
Санасаң.

Иләк

Алдым да кулга иләк,
Торам менә он иләп.

Пешерәм оннан коймак,
Чакырам аннан кунак!

Йолдызлар

Йолдыз балкый бүген дә
Татарстан күгендә.
Йолдыз балкый Кремльдә…
Һәм минем бүрегемдә!

Капка

Безнең олы капкага
Кем анда кат-кат кага?
Тормагыз инде басып —
Кечкенә капка ачык!

Лимон

Күзләремнән яшьләр чыкты,
Капкан идем лимонны.
Сары булгач, бик татлыдыр
Дигән идем мин аны.

Машина

Белми чама —
Тыз-тыз чаба,
И ашыга
Машина.
Узып китсен —
Сабыр ит син,
Чыга күрмә
Каршына!

Нота

Абый гармунда бер көй дә
Уйный алмый нотасыз.
Ә мин менә нотасыз да
Уйный алам хатасыз!

Үсми калган хәреф

Йөри, ди, **ң** каңгырып,
Йөри, ди, ул кайгырып.

Эшләре **ң**ның яман
Үсеп җитми, ди, һаман

Сүз башында торырга
Һәм баш хәреф булырга!

О

Үзе хәреф,
Үзе сан —
Бөтенләй
Санамасаң.

Љстәл

Бигрәк чиста өстәл өсте,
Кайсы шундый остадыр?
Мин сөрткән идем шул аны —
Өстәл шуңа чистадыр!

Песи

Әти, песи алыйк әле!
Һәммәбез карар иде.
Әгәр дә песи булмаса,
Мәче дә ярар иде.

Рәшәткә

Эшләр җайланган икән,
Бик уңайланган икән —

Алмага кереп була,
Турыдан йөреп була.

Әхәт чыккан рәхәткә:
Ауган чөнки рәшәткә.

Сөлге

Сөлге — сөртенер өчен,
Сөлге — көрәшер өчен,…
Сөлге ул — батыр өчен,
Күрсәтә алса көчен!

## Тук тукран

Тукран тукылдый туктаусыз,
«Тук-тук» бар белгән сүзе.
Тук та булгач, ник туктамый?
Ник корт чүпли соң үзе?

## Урындык

Әти кайтса, пиджагын
Киеп куя урындык.
Бик килешә үзенә —
Карап кына торырлык!

## Үгез

Бигрәк
Сөзгәк
Үгезегез!

Үгезегез
Төп-төз
Мөгез!

Куркасызмы
Ул мөгездән
Сез үзегез?

## Фонарь

Бер генә
Күзле үзе —
Ут булып
Яна күзе!

## Хат

Абый ерак җирләрдән
Солдат хаты җибәргән.

Җайлап кына утырдым —
Кычкырып хат укыдым.

Елап утырды әнкәм,
Тыңлап утырды әткәм.

Бик әйбәт хат — абыем
Миңа да сәлам әйткән!

## Һәйкәл

Басып тора биек һәйкәл
Безнең мәктәп алдында.
Әбиләр ник елый икән
Һәйкәл абый янында?!

## Циркуль

Циркуль сыза
Түгәрәк,
Сызык бара
Тәгәрәп.
Үзе кала
Сузылып —
Карап торам
Кызыгып!

## Чаңгы белән чалгы

Ул биек таудан шуарга,
Ярышырга, чабарга!
Бер хәрефен алыштырсаң,
Була печән чабарга!

## Шырпы

Тынычлыкны,
Зинһар, бозма!

Уйнап кына
Шырпы сызма!

Энеңә дә
Шырпы сузма —

Уйнап була
Шырпысыз да!

## Щетка

Щетка булса,
Чиста теш тә,
Чиста өс тә —
Бөтен төш тә!

Иренмәгән
Чакта мин
Итекне дә
Щеткалыйм!

## **ъ** билгесе

Үзе — хәреф, үзе — түгел,
Бу — катылык билгесе.
Ул һәрвакыт эшләп йөри
Нечкәлекнең киресен.

## Ыргак

Бер караганда — ыргак,
Бер караганда — кармак.

Зур акула кебегрәк
Зур булыр иде бигрәк

Ыргакка капкан балык!
Карыйммы суга салып?

## **ь** билгесе

Үзе — хәреф, үзе — түгел,
Ә хәрефне йомшарта.
Нечкәлек кирәк чагында,
Абруе бик еш арта!

## Эт

Этебез Акбай көн дә
Каршылый өрә-өрә.
Аның яратуы шул —
Өрә ул шуңа күрә.

## Юлбасар юлбарыс

Юлбарыс ачыккан, ди.
Шуңа юлга чыккан, ди.

Чыккан да юл басарга,
Әйләнгән юлбасарга.

## Ябалак

Белдем әле яңарак —
Төн кошы бит ябалак.

Караңгыда оча ул,
Төнлә генә күрә дә.

Сирәк үзен күрүче
Менә шуңа күрә дә.

## Журнал укучы жираф

Журнал, китап укырга
Жираф бик тә яраткан.

Ләкин укый алмаган
Югарыдан, еректан.

Башын иеп караган,
Күзлек киеп караган.

Тик берни дә күрмәгән —
Нишләргә дә белмәгән.

Кайгыга баткан жираф,
Уйланып яткан жираф.

Һәм укуның әмәлен
Барыбер тапкан жираф.

Утыра хәзер жираф
Гел журнал укып кына —

Укый жираф кулына
Бинокль тотып кына!

### Сөзәргә өйрәнә

Бәрәнебез,
Күрегез —
И бәргәли
Койманы,
Койманымы
Кыйнавы?
Әллә инде
Уйнавы?

Юк, өйрәнә
Сөзәргә,
Мөгезләрен
Төзәргә.

Маңгае бик тә
Сызлый,
Сызлавы һич тә
Узмый.

Туры килә
Түзәргә
Өйрәнгәндә
Сөзәргә.

Шунсыз булмый
Өйрәнеп,
Китәр әле
Көйләнеп.

Өйрәнер ул
Кәзләргә,
Әйбәт итеп
Сөзәргә.

Сөзешсен, әйдә,
Сөзсен,
Мөгезе генә
Түзсен!

## Сакчылар

Бар бакчада кишер дә,
Бар бакчада кыяр да.
Тик тәмлетамакларны
Ничек кенә тыярга?

Кермәкче алар бик тә —
Капкасында юк бик тә.

Тик бакчадан аларның
Алына ла котлары!
Көннәр буе бакчаны
Саклый шул бал кортлары.

## Белдерү

Баганада
Язу күреп,
Әле шыңшып,
Әле өреп,
Шул язуны
Укый бер эт.
Үзе укый,
Үзе уйлый —
Бу язуда ни икән?
Берәрсенә минем кебек
Көчек кирәкми микән?

## Черки, чабак, чуртан һәм чиләк

Черкине
Чабак
Тоткан,
Чабакны
Чуртан
Йоткан.

Чиләккә
Чумган
Чуртан —
Тотар
Идем дә...
Куркам!

## Кро!ко!!дил!!!

Крокодил ул, белсәгез,
Крокодил ул, күрсәгез,
Бик әйбәт,
Юаш җанвар,
Юк андый
Юаш җаннар.
Сөйкемле ул,
Ягымлы,
Өстәвенә,
Талымлы.
Койрыгына басмасаң,
Йә йокысын ачмасаң,
Күзләрен
Йомган булса,
Корсагы
Тулган булса,
Сызламаса
Тешләре,
Авыртмаса
Эчләре,
Уйламый да
Тияргә,
Мөмкин хәтта
Сөяргә,
Әгәр дә көчле булсаң!
Крокодилның
Нәкъ үзе төсле булсаң...
Тик... ни...
Бик үк ышанып
Бетмәгез лә сүземә.
Иң яхшысы — күренмәү
Кро!ко!!дил!!!ның
Күзенә.

## Ачык авыз

Күр,
Ак куян —
Куркак
Куян
Ята
Йоклап,
Куәт
Туплап.
Уян,
Куян,
Уйлан,
Куян —
Сиңа
Кыям
Капкын
Куйган!
Капкын —
Усал,
Капкын —

Явыз.
Каба
Күрмә,
Ачык
Авыз!

Көнгерә

Көнгер-көнгер-
Көнгерә
Әй йөгерә,
Элдерә.
Көнгерәгә
Өлгерәдер
Кемнәр генә,
Кем генә?
Көнгер-көнгер-
Көнгерә
Бөтенесен
Көлдерә:
Олы кесә
Тектергән,
Кесәсен зур
Иттергән.
Кесәдән кем
Күренә?
Кесәдән кем
Үрелә?
Ул кесәдә
Көн күрә
Кечкенә бер
Көнгерә,
Аңа шунда
Үсәсе!
Килми бугай
Төшәсе.
Монда үсәргә
Мөмкин:
Бигрәк иркен,
Бигрәк киң,
Бик тә җылы,
Бик җайлы,
Бигрәкләр дә
Уңайлы
Әнисенең
Кесәсе,
Килми шуңа
Төшәсе.…

Көнгер-көнгер-
Көнгерә...…

Төклетура

Бар микән ул берәр урман
Төклетурасыз? —
Әйтми-нитми чагып китте,
Вәт культурасыз!

## Бытбылдык

Балалар
Чыккач та,
Биеккә
Очкач та,
Сөенгән
Быт-был-дык:
— Күп бул-дык!
Күп бул-дык!

Сыйланып
Туйгачтын,
Туйганын
Тойгачтын,
Җырлаган
Быт-был-дык:
— Тук бул-дык!
Тук бул-дык!

Очрагач
Каршыга
Тилгән йә
Карчыга,
Кычкырган
Быт-был-дык:
— Юк бул-дык!
Юк бул-дык!

## Елан белән камчы

Минем елан күргәнем бар —
Ул нәкъ камчы төслерәк.
Ләкин абыйның камчысы
Еланнан да көчлерәк.

Елан шикелле уйнаклый
Камчы абый кулында.
Чыннан да, котың алыныр
Очраса ул юлыңда.

— Кулга ияләштерелгән
Елан ул,— ди абыем,—
Шуңа күрә озын, усал,
Елдам ул,— ди абыем.

Еланнан курыккан кебек
Курка аннан атлар да.
Еландыр дип уйлап куям
Мин дә андый чакларда.

Уйласам да, шикләнсәм дә,
Курыкмыйм ла тамчы да...
Сүзлектән үзем карадым —
Чын елан бит камчы да!

## Аю

Аю килгән Казанга,
Кереп чыккан базарга.

Килгән аю бал өчен —
Сизгән булган бал исен.

Тик юлы уңмаган, ди —
Акчасы булмаган, ди.

## Дөя

Өстенә йөк
Өя-өя,
«Йөгем авыр!» —
Дия-дия,
Шуның өчен
Көя-көя,
Кояшта да
Көя-көя,
Башын аска
Ия-ия,
Аннан өскә
Чөя-чөя
Чүлдән бара
Көяз дөя.
Дөя — чыдам,
Дөя — чая!
Бара икән
Дөя кая?

## Нарат

Нарат —
Харап! —
Бигрәк
Биек,
Болытларга
Тора тиеп!
Биектәге
Ябалдашын
Торам яшел
Болыт диеп!

## Чыршы

Канатларын
Сыгылдыра,

Ылысларын
Салындыра.

Җырлап тора
Сабыр гына —

Яңа еллар
Сагындыра!

## Имән

«Тамырларым
Тирән,
Түбәм
Күккә
Тигән!
Давылларга
Башны
Имәм!» —
Дигән
Имән!

## Алма

Алмасы да алмасы —
Өзеп кенә аласы!

Өзмим әле — баллансын,
Бераз гына аллансын!

## Тирәк

Тирәк,
Тирәк,
Син дәү
Бигрәк!
Синең  кебек
Олы булу
Минем теләк.
Ничек үсим,
Әйтче, тирәк? —
Дәү буласым
Килә тизрәк!

## Эт

Көн буе
Йөргән эт,
Төн буе
Өргән эт.

Йөргән эт
Тешләшеп,
Йөргән эт
Этләшеп.

Сизми дә
Калган эт —
Эт булып
Арган эт!

### Үрдәк

Бака кебек бак та бак,
Бак та бак килә үрдәк.
Менә шулай була ул
Бакадан алсаң үрнәк.

### Төнбоек

Үз матурлыгын
Тоеп,
Кояш нурында
Оеп,
Яфрагына
Баш куеп
Үсә күлдә
Төнбоек.
Төнбоек ул,
Көнбоек.
Өзмәкчедер
Малайлар —
Төнбоек
Шуңа боек.

### Ташбака

Таш урамда
Таш ята.
Таш түгел лә,
Ташбака.
Бар бакага
Баш бака.
«Нигә соң мин
Таш бака?» —
Дип, ташбака
Баш вата.
Ә кешеләр
Шакката —
Берәүләре
Ашата,
Берәүләре
Таш ата.
«Ярый әле

Таш бака
Булганмын!» — ди
Ташбака.

Йомран

Йомшак йонлы йомранның
Йомры башы күренде.
Йомрыланган үзе дә,
Нәкъ йон йомгак, күр инде!

Карлыгач

Өй түбәсендә —
Карлыгач,
Яр буенда —
Ярлыгач.

Сөн буена күчеп киткән,
Өй түбәсе тар булгач.
Яр буен да ташлап киткән,
Яр буйлары кар булгач.

Булса да үзе
Карлыгач,
Кар яратмый
Карлыгач.

Тилгән

Тилгән
Килгән!
Тилгән
Килгән!

Чеби эзләп,
Чеби күзләп
Килгән
Тилгән
Ерак илдән.
Чебиләрнең
Күп икәнен
Каян белгән
Икән тилгән?

Тилгән
Килгән!
Тилгән
Килгән!

Антилопа

Чаба гына
Антилопа...

Африкада —
Андыйлопа.

Үзен тыя
Алмыйлопа,

Болыннарны
Таптыйлопа.

Чәчәкләрдән
Атлыйлопа.

Нишли инде
Сантыйлопа?

Ник тик кенә
Ятмыйлопа?

Шуны аңлый
Алмыйлопа —…

Менә шундый
Антилопа.
Шүрәлеләр турында,
Тылсынчы бабай турында
һәм малайлар турында,
тагын шүрәлеләр турында
кечкенәкият

*Хөрмәтле аксакалыбыз — сынчы*
*Бакый бабай Урманчега багышлыйм*

Кырлай урманнарында

Яшәгән, ди... булган, ди...
Булган, ди, шул...
Булган, ди...
Ул шүрәлеләр белән
Бөтен урман тулган, ди.
Шүрәлеләрдән урман
Шаулап-гөрләп торган, ди.

Яшәгәннәр, ди, алар
Шаярып-уйнап-көлеп.
Юк шул, бүген түгел шул —
Моннан күп еллар элек.

Йөз елдыр инде минем дә
Шүрәле күргәнем юк.
Шүрәле кытыкламагач,
Туйганчы көлгәнем юк.

Кырлай урманнарында да
Шүрәлеләр беткән, ди.
Ул шүрәлеләр беткәнгә
Күптән инде, күптән, ди.

Шулай…урманны иң соңгы
Шүрәле дә ташлаган.
Малайларга да урманда
Кызык булмый башлаган.

### Шәһәр шүрәлеләре

Киңәшкәннәр малайлар —
Килешкәннәр малайлар.

Шүрәлеләр артыннан
Килгәннәр, ди, шәһәргә.
Шүрәлеләр табылса,
Үзләренә дәшәргә.

Кергәннәр алар музейга,
Күргәзмә залларына,
Килеп чыкканнар мәйданга,
Театр алларына.

Актарып чыккан малайлар
Тукай китапларын да,
Халык әкиятләрен дә...
Ничаклы бар — барын да.

Вәт әкәмәт —
Күр әле:
Казан тулы
Шүрәле!

Тик аларның берсе дә
Урманны өнәмәгән,
Кырлай урманнарына
Кайтырга теләмәгән.

Китап, сәхнә тормышына
Күнеккән инде алар.
Нәкъ шәһәр шүрәлеләре
Кебекләр инде алар.

Үгетләп тә караганнар —
Файда юк, ди, үгеттән.
Беләм инде — шүрләгәннәр
Былтыр дигән егеттән...

### Яшәгән, ди, Тылсынчы

Ә Казанда яшәгән
Аксакал бер Тылсымчы.
Тылсымчы гына түгел,
Дөньяда бер Тылсынчы!

Карап кына ала да
Агачка җан кертә, ди.
Бик теләсә, шунда ук
Тимерне терелтә, ди.

Теләсә кайсы ташны
Терелтә дә ташлый, ди.

Нәрсәгә кагылса да
Җырлый, бии башлый, ди.

Малайлар нәкъ әнә шул
Тылсынчыга килгәннәр.
Казанда яшәгәнен,
Белмим, каян белгәннәр?

— Коткарсагыз сез генә
Коткарырсыз! — дигәннәр.—
Бу афәттән сез генә
Аткарырсыз! — дигәннәр.

— Ярар! — дигән Тылсынчы.—
Уйлап карармын,— дигән,—
Борчылмагыз, малайлар,
Җаен табармын! — дигән.

Љр-яңа шүрәлеләр

Бераз уйланган Тылсынчы,
Ахырдан килешкән, ди.
Җиң сызганып, шүрәлеләр
Эшләргә керешкән, ди.

Шүрәлеләрне көн саен
Куя, ди, коеп кына.
Агачның артык урынын
Ала, ди, уеп кына.

Озын иттерә койрыгын,
Ясый мөгез аннары,
Кәкре-бөкре озын борын...
Тиз ясала калганы.

Бастыра, ди, әзер сынны
Һәм аңа җан өрә, ди.
Ниндидер сүзләр әйткәчтен,
Агачка җан керә, ди.

Шуннан соң әверелә, ди,
Агач сын шүрәлегә...
Тылсынчы йөзләп шүрәле
Эшләгәндер... әлегә.

Тик шүрәлеләр, нигәдер,
Калмаганнар янында.
Чөнки аларны урманнар
Көткән Кырлай ягында.

Берсе койрыксыз килеш
Урманга качкан, имеш.

Ә берсенең мөгезен
Өлгермәгән ясарга.
Тик барыбер җай гына
Көткән алар качарга...

Тылсынчы ясап торган,
Тегеләр качып торган.
Качсыннар дип, Тылсынчы

Ишеген ачып торган...

### Былтырга да әйтегез!

Сез дә барыгыз әле
Кырлай урманнарына.
Урманнарның шүрәле
Яши торганнарына.

Тик курка күрмәсеннәр —
Сез анда кычкырмагыз!
Бармакларын агачка,
Зинһар, дим, кыстырмагыз!

Былтырга да әйтегез —
Йөрмәсен ул урманда.
Шүрәлеләр шүрләрләр
Ул урманда булганда.

Югыйсә алар урманнан
Тагын качып китәрләр.
Кырлайдагы урманнарын
Тагын ятим итәрләр.

### Әкиятнең ахыры

Хәер, хәзер Тылсынчыны
Сез дә беләсез инде.
Шүрәлеләр кирәк булса...
Нигә көләсез инде?

Беләм инде
Мин сезне —
Ялганлый бу,
Дисезме?

Яшермим, моңа чаклы
Язганмындыр төрлесен.
Ә бу юлы, чынлап әйтәм,
Яздым мин чын дөресен!

Ялганлап торырга
бала-чага түгел лә мин.
Үз күзләрем белән күрдем
мин ул шүрәлеләрне.
Ышанмасагыз,
үзегез барыгыз да карагыз!
Җәяү йөрүче машина турында
кечкенәкият

### Булган, ди, бер машина

Булган, ди, бер машина —
Җитез, өлгер машина,
Бик тә елгыр машина.

Зур түгел һич кенә дә,
Түгел, ди, кечкенә дә —
Гадәти бер машина,

Гади тимер машина.

Яраткан ул йөрергә,
Ерак юллар кичәргә.
Машина булса да ул
Яраткан, ди, эчәргә.

Юк, аракы эчмәгән —
Килмәгән башына да.
Курыкмый кем утырсын
Исерек машинага?

Лимонад та,
Компот та
Эчмәгән ул
Бер кат та.

Кесәл эчәр иде дә,
Кесәлдән көче беткән.
Сөт тә эчәр иде дә,
Сөттән дә төсе киткән.
Чәй дә эчәр иде дә,
Чәйдән ни... эче киткән.
Сок эчсә дә чәчәгән...
Шуңа күрә машина
Бензин эчеп яшәгән.

Әй йөри, ди, машина

Бензинны ул яраткан:
Китмәгән, ди, төсе дә,
Бетмәгән, ди, көче дә,
Авыртмаган эче дә,
Теше дә —
Бер төше дә!

Хәтта җырлаган икән,
Җырлаганын, сокланып,
Үзе тыңлаган икән:

«Бензины да бензины!
Бигрәкләр тәмле икән.
Әллә бензин эчкәнгә
Дөньялар ямьле микән?»

Бензинын эчеп куйгач,
Бик тәмләп эчеп туйгач,

Әй йөри, ди, машина
Шәһәр урамнарыннан,
Шәһәр бульварларыннан,
Урам араларыннан.
Йөри, ди, әй типтереп,
Бөтен шартын китереп,
Төтен исе сиптереп.

Зәп-зәңгәр булган урам
Ул выжылдап узганда.

Тик сүз әйтүче юк, ди,
Саф һаваны бозганга.

Шәһәрнең кешеләре
Инде өйрәнгән икән,
Аларның борыннары
Шуңа көйләнгән икән.

### Китеп барган урманга

Шуннан бер ял көнне ул
Уйлап-уйлап торган да,
Бензин эчеп алган да,
Буш вакыты булганда
Китеп барган урманга.

Әй ашыга-ашыга,
Әй бара, ди, машина —
Төтен исе таратып,
Урман эчен каралтып.

Шушы төтен исендә,
Шушы төтен эчендә

Күбәләкләр,
Үләннәр
Авырганнар,
Үлгәннәр.

Кошлар да
Очмас булган,
Күзләрен
Ачмас булган.

Бөҗәкләр дә
Исергән
Шул машина
Исеннән...

Тик машина
Кинәттән
Тиз тизлеген
Киметкән.

Авыр сулап
Алган ул,
Тукталып ук
Калган ул.

Кашып куйган
Башын да —
Гүзәл бер чәчәксылу
Тора икән каршында.

### Гашыйк булган машина

Гашыйк булган машина
Ул чәчәкне күргәч тә —
Елмаеп бер көлгәч тә!

Ә чәчәккә сулавы
Авыр була башлаган —
Машина төтененнән
Кинәт сула башлаган.

Чәчәк көлмәс булган, ди,
Чәчәк йөрмәс булган, ди,
Күзе күрмәс булган, ди...

Эшнең нидә икәнен
Машина да аңлаган.
Үзе чәчәксылудан
Күзләрен дә алмаган.

Ул чәчәксылуны бик тә,
Бик тә, бик тә кызганган.
Чәчәк үлмәсен диеп,
Үлә күрмәсен диеп,
Урыныннан кузгалган.

Бик тә оялган икән ул
Бу хәлләрне күргән дә.
Һәм җәяүләп китеп барган
Моторын сүндергән дә...

Әкиятнең ахыры

Ул машина, әле булса,
(Чын микән, юри микән?)
Чәчәк искә төшкән саен,
Җәяүләп йөри икән.

Нигә? Андый машинаны
бер дә күргәнегез юкмыни
сезнең? Бар ул, бар
андый машина.
Игътибар беләнрәк карагыз әле,
бәлки, сез дә күрерсез.
Күрсәгез, миңа да әйтерсез, яме?!
Батыр куянның ничек итеп
куркак куянга әйләнүе турында
кечкенәкият

Яшәгән, ди, бер куян

Яшәгән, ди,
Бер куян —
Эре куян,
Көр куян!

Туса да ул
Урманда,
Торса да ул
Гел анда,

Ахры, туган
Көненнән
Куагының
Төбеннән

Ерак китмәгән булган.
Ерак китәр иде дә,
Йөрәк җитмәгән булган...

Ә инде үсеп җиткәч,
Йөрәкләнеп тә киткәч,
Гайрәтләнеп тә җиткәч,
Уйлаган ул беркөнне,
Тыңламыйча беркемне,
Азрак уйнап килергә,
Зур урманда йөрергә,
Бераз дөнья күрергә...

Әнкәсе күргәнче дип,
Әткәсе белгәнче дип,
Чапкан урман эченә,
Чапкан бөтен көченә.

Рәхәтләнгән
Иркендә.
Тыймаган, ди,
Беркем дә.

Урман шундый
Олы, ди.
Киек-кошлар
Тулы, ди.

Шаклар катып
Йөргән ул,
Әллә ниләр
Күргән ул...

### Кайтып килә, ди, куян...

Кайтып килә, ди, куян
Әллә каян —
Ерактан.

Шул чагында
Каршында
Зур бер җанвар
Очраткан!
Нишләргә
Бу очракта?

Тукталып калган куян —
Арыган-талган куян.
Бик дәү икән җанвары —
Җилферди, ди, яллары.
Караңгыланып киткән
Куянның күз аллары.

Ә җанвар
Юлга баскан.
Бер япкан да
Бер ачкан
Галәмәт зур
Авызын —

Тешләре, ди,
Әй озын!

Моның, ахры, исәбе
Куянны куркытырга,
Йә аны котыртырга,
Яки тотып йотарга!

Куянның кәефе киткән,
Тегеләй-болай иткән.
Акылга утыртырга
Моны ничек иттереп?
Һәм тормаган көттереп...

Ят җанварга куянның
Ачуы нык чыккан, ди —
Яңагына нык кына
Китереп тә суккан, ди.
Теге аңга килгәнче
Салган да
Еккан да, ди.
Ә аннары бөтенләй
Капкан да
Йоткан да, ди.

Бик ачыккан куянга
Бу бик тә ярап куйган.
Эчен сыпырган куян,
Иренен ялап куйган,
Тагын бер
Ялмап куйган.
Күренеп тора инде —
Куянның тамак туйган!

Каян белсен, ди, куян...

Моны күргән җәнлекләр
(Әй өркәкләр-гарьлекләр!)
Нишләргә
Белмәгәннәр,
Нишләптер
Көлмәгәннәр,
Кыскасы, куркышканнар —
Койрыкларын
Кысканнар,
Өннәренә
Посканнар,
Өйләренә
Качканнар...

Аннары көчкә-көчкә
Тынычлангачтын кичкә,
Куян янына алар
Җыелышып килгәннәр:
— И куян, йоттың бит син
Арысланны! — дигәннәр.

Белгәч кемне йотканын,
Куян киткән дерт итеп.
Караган ул аларга
Ике күзен дүрт итеп.

Нишләргә дә белмичә,
Чак-чак калган үлмичә.
Ул бик нык аптыраган,
Белмәдем, дип акланган.
Бик нык үкенгән куян,
Гафу үтенгән куян.

— Әгәр белсәм, мин аңа
Ташланмас  идем,— дигән,—
Әгәр белсәм, мин аны
Ашамас идем,— дигән.

Аның чын арысланны
Күргәне булмаган шул,
Арыслан тирәсендә
Йөргәне булмаган шул.

Аның көчле икәнен,
Казык тешле икәнен
Белсен, ди, куян
Каян?
Ай-яй, куян!
Ай наян!

Куркак куян

Шуннан бирле урманда
Куян күренми икән,
Урманда барлыгы да
Хәтта беленми икән.

Утыра, ди, арыслан
Ул куянның эчендә.
Кайчак батырлана, ди,
Менә шуның өчен дә.

Бик батыр булыр иде дә,
Куркаклыгы җиңә, ди.
Куркаклыгы аркасында
Куян җәфа чигә, ди.

Шушы хәлдән соң куян
Калган, ди, куркак булып.
Калган, ди, куркуыннан
Агарып, ап-ак булып...

«Куркак куян» дигән булып
Бөтен дөнья көлешә.
Ә шулай да,
Минемчә,

Арыслан йоткан куянга
Куркаклык та килешә!

Әкиятнең ахыры

Ә сез, дуслар, җанварларга

Бәйләнмәгез, тимәгез.
Арыслан булуы мөмкин —
Берүк якын килмәгез!

Сез — кыюдыр.
Бәйләнүен,
Анысы, бәйләнерсез...
Тик арыслан
Тотарсыз да,
Куян кебек
Йотарсыз да,
Куркакка әйләнерсез!
Куян йөрәкле бүре турында
кечкенәкият

1
Ә бит бүре куянны
Һаман тота алмый, ди,
Инде тоттым дигәндә,
Куян тагын алдый, ди.

Елмаймый,
Көлми бүре,
Нишләргә
Белми бүре!

Беркөнне ул куянның
Кайдалыгын
Белешә
Һәм хәйләгә
Керешә.
Уйлый-
Уйлый-
Уйлый да
Хат җибәрә
Кылыйга.

2
«Куянкаем,
Исәнме!
Бәләкәчләр
Үсәме?
Сиңа мәгълүм
Бүре мин,
Бүренең шәп
Төре мин.

Мин бик юаш.
Йөрим мин
Койрыкны
Кысып кына,
Качып та
Посып кына.
Килсәң әгәр кунакка,
Йөртермен
Кочып кына!
Бүреләрчә

Сүз бирәм:
Мин моннан соң
Үзгәрәм,
Бүгеннән үк
Төзәләм.
Телисеңме,
Тезләнәм.

Куянкаем,
Дускаем,
Кунакка кил
Үземә —
Матур булып,
Тәмле булып
Күренәсең
Күземә!»

3

Бүре хатын укыгач,
Кеткелдәп көлә куян.
Бүренең бу хәйләсен
Шунда ук белә куян.
Уйлый-
Уйлый-
Уйлый да
Җавап яза
Кылый да.

4

«Исәнме,
Иптәш бүре!
Симез һәм итләч бүре!

Куян гына булсам да,
Бик гайрәтле куян мин!
Бүренең кайдалыгын
Мең чакрымнан тоям мин!

Күп ашарга яратмыйм — -
Бер бүредән туям мин,
Бүрене бер утырып
Ялт иттереп куям мин!

Аннан ятып йоклыймын, -
Бер атнасыз уянмыйм.…
Менә шундый
Куян мин!

Мине куян дигәч тә,
Әллә куркак дисеңме?
Оят куян булуы — -
Алыштырам исемне.

Исememне арыслан,
Юлбарыс дип куштырам.
Бүрене үз янымнан
Мең чакрымга постырам.

Бүре энем,
Кил үзең. -
Минем сиңа
Шул сүзем!

Абзаңның кем икәнен
Шунда белерсең әле,
Менә күрерсең әле!
Ух, мин сине!..»

5

Бүре, шушы
Хаттан соң,
Ник бер генә
Мактансын.

Кылый хәзер бүренең
Төшләренә керә, ди,
Куянны ул төшендә
Ерткыч итеп күрә, ди...
Их бүре, бүре, бүре,
Бүренең
Куркак төре,
Куян йөрәкле
Бүре!
Бик масаеп
Йөрмә син,
Куян күрә
Күрмәсен,
Эләктерә
Күрмәсен!
Һайт!..

6

Бу хәл, бәлки,
Булгандыр,
Бу хәл, бәлки,
Ялгандыр... -

Мин аны
Каян белим?
Мин бары берәүнең дә
Усал булмавын
Телим!
Бозау белән көчекнең
дуслашуы турында
кечкенәкият

Ел ярым элек моннан
Бик яшь бер бозау
Булган.

Тик дуслары
Булмаган,
Булганыннан —
Уңмаган.

Ләкин бозау
Түзмәгән —
Үзенә дус
Эзләгән.

Беркөнне ул урамда
Көчек янына килгән,
Килгән дә ул:
— Му-у-у! — дигән.

Көчек бик
Аптыраган,
Әнисеннән
Сораган:

— Нинди телсез бу? — дигән,—
Нигә мулый бу? — дигән,—
Әнием, бу бозауны
Моннан тизрәк ку! — дигән.

Әнисе болай дигән:
— Әйбәт бозау бу! — дигән,
Ул бит сиңа: «Му-у-у! — дигән,—
Дус булабызмы-у-у?» — дигән.

Соңыннанмы?
Соңыннан
Көчек бик нык
Оялган,
Көчек бик нык
Уйланган!

Бозауны
Эзләп чапкан,
Бозауны
Эзләп тапкан,
Аның
Янына килгән,
Бар көченә:
— Һау-у-у! — дигән.

Тик бозау аңламаган
Көчекнең ни дигәнен.
Әйткән ул әнисенә:
— Мин бит аңа тимәдем!

Шулай булгач,
Ул көчек
Нигә миңа
«Һау-у-у!» — ди ул,
Миннән нәрсә
Даулый ул?
Ул миңа
Һауламасын!
Юк-барга
Шауламасын!

Ә әнисе аңлаткан:

— Көчек бит сиңа «Һау-у-у! — ди,—
Дус булырга риза-а-у-у-у!» — ди.

Бозау бик нык
Оялган,
Бозау бик нык
Уйланган!

Бозау белән ул көчек
Ахырда
Аңлашканнар,
Хәтта
Кочаклашканнар,
Кыскасы —
Дуслашканнар!

Ишегалды гөр килгән:
— Һау да, һау да,
Му да му!..

Бумы?
Бу —
Һәм бозау турындагы,
Һәм көчек турындагы
Чын әкият була
Бу!
Кечкенә көчек турында
кечкенәкият

Үсәр өчен
Сөт эчеп,
Яшәгән, ди,
Бер көчек!

Ул тәртипсез
Булмаган,
Ул әнисен
Тыңлаган.

Вакытында
Йоклаган,
Йоклаган —
Көч туплаган!

Юып йөргән
Ул көн дә
Битләрен,
Колакларын,
Колагының
Артларын...

Ни генә
Эшләмәгән,
Ә барыбер
Үсмәгән.

Башка
Көчекләр исә

Зур булган
Үсә-үсә!

Тик менә
Көчек кенә,
Үсим дип
Ничек кенә,

Эчә икән
Көн дә сөт,
Көчекләрдән
Көнләшеп!

Күпме генә
Эчмәгән,
Юк, барыбер
Үсмәгән...

Чөнки көчек
Үзе шундый
Үсми торган
Эт булган!
Туп тибәргә яратучы
малай турында
кечкенәкият

Бер малай
Туп уйнаган,
Туп белән
Күп уйнаган!
Әй уйнаган,
Туймаган!
Үскәчтен
Чын футболчы
Булам, диеп
Уйлаган.

Ул көн буе уйнаган:
Әнисенең сүзләрен
Колагына
Элмәгән,
Өйгә кайтып
Кермәгән.

Дәрес —
Әзерләнмәгән,
Өйгә эш —
Эшләнмәгән,
Мисаллар —
Чишелмәгән...
Ә дәрестә ул малай
Берни дә төшенмәгән...

Ошамаган бу
Тупка:
— Яхшы түгел бу,
Тукта!

Бу хәлләргә
Түзем юк,
Типсен иде,
Сүзем юк,
Үпкәләмәс тә идем
Яхшы малай типкәнгә,
Ачу килә, «икеле»
Алып мыскыл иткәнгә.
Син, малай,
Ялкау бигрәк,
Син, әйдә,
Төзәл тизрәк! —
Дигән ул туп малайга.

Ә малай
Тыңламаган,
Әйткәнне
Аңламаган,
Ул һаман да
Туп типкән.

Тик беркөнне туп аның
Үзен дә кызык иткән:
Теге малай тибүгә,
Бөтенләй очып киткән...

Икенче туп алганнар —
Ансы да очып киткән,
Өченче туп алганнар —
Ансы да очып киткән.

Барсы да
Очып киткән!
Барсы да
Очып беткән!
Малай
Килеп тибүгә,
Хәтта
Якын килүгә,

Туплар,
Сүз берләшкәндәй,
Оча да
Китә икән,
Ә малай
Көтә икән.

Белмим, хәзер ул малай
Бераз
Үзгәрде микән?
Бераз
Төзәлде микән?

Ләкин ул шул хәлдән соң
Туп тибүдән туктаган.
Хәзер инде күрсә дә
Курка, ди, ул туплардан!

Койрыксыз куян турында
кечкенәкият

Элегрәк шәһәргә дә
Көн саен килгән куян.
Килгәч «Яшелчә» дигән
Кибеткә кергән куян.

Кергәчтен дә чиратка
Баскан, ди, ул кишергә.
Икешәр пот алган, ди,
Калдырмыйча кешегә.

Өстәвенә, берәр пот
Кәбестә ала икән.
Әле ике шалканлык
Акчасы кала икән.

Куян шулай көн саен
Ишәк кебек төянгән,
Шул төянгән килеш ул
Урманына юнәлгән.

Ә урамда трамвайлар,
Машиналар — меңләгән!
Ләкин куян урамда
Бер дә йөри белмәгән.

Каян белсен — куянны
Берәү дә өйрәтмәгән.
Аннары ул кагыйдә
Куянга кирәкмәгән.

Куян шулай уйлаган —
Өйрәнеп вакланмаган.
Моңа чаклы бит әле
Машина таптамаган.…

Тик беркөн
Кинәт чаттан
Зур трамвай
Килеп чыккан!

Куян трамвай юлыннан
Тиз генә чыга алган.
Ләкин менә койрыгы —
Озын мамык койрыгы —
Аз гына соңга калган! —

Трамвай астында калган,
Бөтенләй шунда калган!

Куян шундый каушаган,
Куян шундый курыккан,
Куркуыннан койрыгын,
Кәбестәсен, кишерен
Алырга да оныткан.

Койрыгы да

Булмагач,
Комачаулап
Тормагач,
Әй шундый тиз чаба, ди,
Урманына таба, ди.

Койрыгы
Өзелгәнгә
Ул хәтта
Сөенгән дә!

«Озын койрык заманы
Узды инде,
Ә аны
Йөртсен лә
Төлке генә —
Хәзер ул
Көлке генә!

Вәт хәзер була инде
Бакчага керергә дә!
Болай булгач, хәзер мин
Тоттырмыйм бүрегә дә!

Җайлы хәзер
Чапканда,
Бүреләрдән
Качканда!

Ә инде ул шәһәрдә
Куянсыз да кеше күп.
Аннан куян абзаңның
Урманда да эше күп!»

Шуннан бирле шәһәргә
Йөрүен ул ташлаган.
Шуннан
Куян
Койрыксыз
Яңа тормыш башлаган!

Шуннан соңмы?
Шуннан соң...
Ансын инде менә сез
Үзегез дә беләсез!
Кояш буласы килгән
кызыл шар турында
кечкенәкият

Яшәгән, ди,
Кызыл шар,
Яшәгән, ди,
Кызык шар...

Шарны элеп
Куйгач та
Өскәрәк, биеккәрәк,
Охшаган, ди, кояшка!

«Син нәкъ кояш шикелле!» —
Дигәннәр, ди, ул шарга.
Шар үзе дә тырышкан
Шул кояшка охшарга.

Аңа ул сүз
Ошаган,
Ул сүзгә ул
Ышанган.

«Минем кебекләр
Сирәк!
Миңа һичкичекмәстән
Кояш булырга кирәк!

Килер ул эш
Көчемнән»,—
Дип уйлаган
Эченнән.

Әйткән әнисенә дә:
— Мин кояш булам! — дигән,—
Биеккә кунам! — дигән.

Ләкин әйткән әнисе:
— Син кояш булма! — дигән,—
Биеккә кунма! — дигән,—
Кайбер юньсез малайлар
Сине күргәч шаккатыр
Һәм шунда ук
Шартлатыр!

Йә булмаса, сине җил
Очыртып китәр! — дигән,—
Аннары бөтен җирне
Кояшсыз итәр! — дигән.—

Без кояшсыз
Калырбыз,
Аннан каян
Алырбыз?!

...Уйга калган
Шар шунда
Һәм аңлаган
Барсын да!

Ул әнисен
Тыңлаган —
Кояш булып
Тормаган.

Ул бик дөрес
Эшләгән,
Әйбәт бер эш
Эшләгән!..

Сез дә, дусларым, берүк,
Әйтсәләр дә
Күнмәгез —

Кояш була
Күрмәгез!

Хәтерсез балыклар турында
кечкенәкият

Су асты
Дөньясында,
Балыклар
Оясында
Беркөн барлык
Балыклар
Шауларга
Керешкәннәр,
Кычкырып
Сөйләшкәннәр,
Кычкырып
Киңәшкәннәр,
Кычкырып
Тиргәшкәннәр,
Кычкырып
Көлешкәннәр!

Су җанварлары
Башта,
Бәла килде, дип,
Башка,
Куркуга ук
Төшкәннәр.

Су астын
Шау-шу баскан.
Җанварларның
Күбесе
Су астын
Ташлап качкан.

Ә калганнар бу хәлне
Куркышып тыңлаган, ди.
Су астында моңарчы
Мондый хәл булмаган, ди.

Шулчак диңгез
Түреннән
Дельфин бабай
Күренгән!

Һәм ул әдәпле генә
Үтенгән, ди, алардан,
Ягъни шул
Балыклардан,
Сөйләшеп
Йөрмәүләрен,
Тиргәшеп
Йөрмәүләрен,
Кычкырып
Көлмәүләрен,

Су астында халыкның
Йокысын бүлмәүләрен!

Балыкларның барсы да
Дельфинны тыңлаганнар,
Барсы да тынган алар —
Сөйләшә белмәүләрен
Оныткан булган алар!
Бүренең кешеләр белән
дуслашуы турында
кечкенәкият

1
Кешеләр белән бүре
Яши гел
Дошманлашып,
Талашып,
Тарткалашып!

Бүре бер дә төшенми
Дошманлыкның сәбәбен.
Нигә алмый кешеләр
Бүреләрнең сәламен?

Нигә яратмый икән
Кешеләр бүреләрне?
Әллә инде бүреләр
Бик ямьсез күренәме?

Баласын: «Бүре килә!» —
Дип куркыта әнисе.
«Бүрегә илтеп бирәм!» —
Дип куркыта әбисе.

Көлә-көлә бүредән
«Ну, погоди!» карыйлар.
Ә этләр бүреләргә
Урамда теш кайрыйлар.

Малайлар шигырь укый
Усал бүре турында.
Корулы мылтык тора
Әтиләре кулында...

2
Авыл янына бүре
Килеп тә карый икән,
Тик бүрене кешеләр
Шунда ук таный икән.
Кешеләр, тану белән,
Куып җибәрә икән,
Сугып җибәрә икән,
Таш белән ата икән,
Мылтык шартлата икән.

3
Уйлый торгач, ахырда
Бүре бер җаен тапкан:

Зоопаркка килгән дә
Читлеккә кереп яткан!

Утыра, ди, ул хәзер,
Кешеләргә күз атып,
Малайларны күзәтеп.

Үзе бик аптырый, ди,
Бу чаклы күп кешегә
Гаҗәпләнеп карый, ди.

Зоопаркка килә, ди,
Бар да бүре күрергә.
Балалар да, зурлар да
Елмая, ди, бүрегә.

«Бу — әйбәт бүре!» — диеп
Мактый башлыйлар икән,
Сыйлансын әле диеп,
Кәнфит ташлыйлар икән.

Бүре белән кешеләр
Нинди дуслар, күрегез!
Кешеләр әйбәт икән
Дип уйлый, ди, бүребез.

Чөнки ул бу хөрмәтне
Күрмәгән төшендә дә.
...Бүре тик шул чагында,
Читлектә булса гына
Ошый шул кешегә дә!

Зур кабак турында
кечкенәкият

Ташлаган да бар эшен,
Бик тә зур булыр өчен,
Зур булып торыр өчен
Бакчада үскән кабак.
Зур үсәсе килгәнгә,
Зур үсәсен белгәнгә,
Көн дә су эчкән кабак.
Әмма шулай булса да,
Гел су эчеп торса да,
Кайгыга төшкән кабак!

Кабакның эше харап —
Койма аша бер карак
Кабакны йөргән карап,
Чыкмакчы булган талап!

Кара син әй каракны —
Урламакчы кабакны!

Тик охшаса да кабак,
Кире уйлаган карак.
Ул каракның башына

Фикер килгән... яңарак:

«Үссен кабак — зур булсын,
Урлармын мин зурысын.
Килермен әле кабат»,—
Диеп уйлаган карак.

Ә кабак җәй буена
Кабарынган, кабарган.
Көн саен, торган саен
Кабара гына барган.

Ул кукрайган, зурайган.
Күренгән әллә кайдан.
Әйтерсең лә ул зуррак
Зур кояштан, зур айдан.

Менә ичмасам кабак!
Бакчы, бак, кабакка бак!
Төрлечә, төрле яктан
Карак кабакка баккан.

Өскә таба караган,
Як-ягына каранган,
Башта йөзе агарган,
Аннан үзе каралган,

Колач җитмәле түгел,
Урлап китмәле түгел.

Карагыбыз алданган,
Ялгышканын аңлаган —
Кабат-кабат ябышса да
Кузгата да алмаган.

Карак шундый үкергән,
Үрле-кырлы сикергән,
Җикеренгән, җикергән...
Башта урламаганга
Карак бик нык үкенгән.

Ләкин инде соң булган.
(Бу хәл чынлап чын булган!)

Урлый алмаган карак.
Бакчада калган кабак.
Нәфесен тыймаганга,
Нәфесе туймаганга
Алган карак шәп сабак!

Кызык иткән бит кабак,
Әй карак —
Туймас тамак!

## Балыкчы булырга хыялланучы суалчан турында

кечкенәкият

Булган, ди, бер суалчан,
Булган, ди, ул оялчан.

Суалчанның
Балыкчы
Буласы бик килгән, ди.

Ул нишләргә белгән, ди —
Чөнки балыкчы абыйлар
Аларга еш килгән, ди...

Беркөнне
Таңнан диярлек,
Балыкчыларга ияреп

Киткән, ди, ул балыкка...
Җиткәннәр, ди, барып та

Иң балыклы бер төшкә.
Һәм тотынганнар эшкә.

Утырганнар, утырганнар —
Чиләкләрен тутырганнар...

Өстерәлеп көчкә генә
Кайтканнар, ди, кичкә генә.

Суалчан гына менә
Кайтмаган, ди, өенә...

Кояш, жираф һәм төлке турында
кечкенәкият

Кояш беркөн төлкегә
Калач булып күренгән.
Кызыгып тора торгач,
Ул кояшка үрелгән.

Ничек кенә
Итмәгән —
Ләкин буе
Җитмәгән!

Тик югалып калмаган:
Ул жирафны котырткан.
Дөресрәге, ул аны
Түп башына утырткан!

Уйлый торгач, кояшны
Жираф кабарга булган.
Ни булса да булыр дип,
Кабып карарга булган.

Юк, юк, ашарга түгел —
Белергә

Тәмен генә,
Тидереп
Телен генә!

Тидерүен тидергән,
Ләкин телен пешергән.
Телен пешергәч кенә
Алдануын төшенгән.

Ә төлкегә: «Әй тәмле,
Нәкъ калач төсле! — дигән,
Бераз суынсын инде,
Аз гына эссе!» — дигән.

Үзе болай уйлаган,
Шуны бер ай уйлаган:

Юк, кояш сүрелмәсен!
Калач диеп, кояшка
Берәү дә үрелмәсен!

Юкса башта комсызлар
Кояшта кызынырлар,
Ә суынса, кояшның
Үзенә кызыгырлар!

Без кояшсыз калырбыз.
Аннан каян алырбыз?

Жираф шулай уйлаган,
Шуны бер ай уйлаган!

...Төлке генә һаман да
(Чын микән, юри микән?)
Калачтыр, дип, кояшка
Кызыгып йөри икән.

Киләчәк буын хакына

(*1977 елгы балалар әдәбияты турында уйланулар*)

Безнең балалар әдәбияты—зур традицияләре, күренекле әдипләре, татар совет әдәбиятының алтын хәзинәсенә кергән әсәрләре булган бай әдәбият. Әмма соңгы елларда гомуми әдәбиятыбыз фонында ул тоныкланып, югалып калды шикелле. Чыннан да, менә ничә еллар инде бер тирәдә таптана. Алга да китми, артка да калмый. Тотып алып селкеп салырлык уртакул әсәрләр дөнья күрә торса да, күтәреп алып мактарлык, вакыйга, бәйрәм булырлык, бөтен союз укучысына тәкъдим итәрлек әсәрләр соңгы берничә елда бик сирәк күренә. Сүз дә юк, күренекле язучыларыбыз Шәүкәт Галиевнең, Ләбибә Ихсанованың актив эшләүләре, чын мәгънәсендә талантлы әсәрләр иҗат итүләре күңелне күтәреп җибәрә. Укучыларыбыз талантлы әдипләр—Ш.Рәкыйпов, Х.Халиков, А.Тимергалин, Р.Батуллин, Р.Мингалимов, Ф.Шәфигуллин язган әсәрләрне дә көтеп алалар, яратып укыйлар. Шулай да балалар әдәбиятының гомум торышы һаман да үзгәрешсез кала бирә. Сәбәп нидә соң?

Бездә, ни өчендер, балалар әдәбияты бары тик балалар өчен генә дигән караш яшәп килә. Чынлыкка мотлак туры киләме бу? Безгә калса, өлешчә генә. Әйтик, без әле булса Тукайның «Кәҗә белән Сарык», «Су анасы», «Шүрәле» әкиятләрен яттан беләбез. Перро, Андерсен әкиятләрен, «Мең дә бер кичә»не бирелеп укыйбыз, Гайдар әсәрләрен яратабыз. Ике-өч яшьлек малайларга-кызларга кушылып, «Крокодил Гена җыры»н җырлап йөрибез. Мультфильм күрсәтә башласалар, кырык эшебезне кырык җирдә ташлап, телевизор экраннарына капланабыз. Ә бит алар балалар өчен иҗат ителгәннәр. Аларга безнең бер

катнашыбыз да юк кебек. Күрәсең, чын сәнгать әсәре балаларга да, олыларга да бердәй тәэсир итә. Ә менә уртакул әйберләрне ни балалар, ни олылар кабул итә алмыйлар. Шуңа күрә балалар әдәбиятына «баласытып», кимсетеп карау бөтенләй хак түгел.

Балалар әдәбияты—балалар язучылары эше генә дип уйлау да бар әле бездә. Ә менә әдәбият тарихына күз салсак, моның киресен күрәбез. Татар әдәбияты классикларының күпчелеге балалар әдәбиятын зурлар өчен әдәбияттан аерып карамаган. Алар нәниләр өчен дә классик әсәрләр биреп калдырганнар. Тукайны гына алыйк. Без аның «Туган тел», «Шүрәле», «Ел фасыллары»н, «Бала белән күбәләк» һәм балаларга атап язган тагын бик күп шигырьләрен телебез ачылуга ук көйләп йөрмәсәк, ул шигырьләр безнең күңелләргә ана сөте белән кермәсә, Тукай безнең рухи дөньябызда бу кадәр олы булып, мәгъруր булып яши алыр идеме? Һәрбер татар укучысы Тукайның колач җитмәс иҗатына нәкъ әнә шул шигырьләр аша килә түгелме соң? Ә Галимҗан Ибраһимов? «Яз башы», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары»... Татар укучысы өчен Ибраһимовның бөеклеге шушы хикәяләрдән башлана лабаса! Укучы язучының зурлыгына, бөеклегенә ышана. Чөнки Ибраһимовның иҗаты кечкенәдән үк аның аңына, канына сеңгән. Ә инде кечкенә чакта укыганнар, ишеткәннәр, күргәннәр—алар гомерлек! Ә Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим... Рус әдәбиятыннан Пушкин, Толстойлар, Маяковский һәм башкалар... Дөрес, балалар әдәбияты, аеруча поэзия,— гаҗәп тә катлаулы һәм күпләрне куркыта торган өлкә. Хәтта Блок, Пастернак, Есенин кебек титаннар, балалар өчен язарга тырышып та, уңышсызлыкка очраганнар...

М.Горький балалар әдәбиятын зур бер «суверен держава» дип атаган иде. Күргәнебезчә, төп әдәбият белән әлеге «суверен держава» арасында тирән дипломатик мөнәсәбәтләр урнашып җитмәгән әле бездә. Ә инде ике держава арасында шул мөнәсәбәтләр урнашмаса, алар үзара янәшә сыешып яшәмәсә, нәтиҗәләр бер дә матур булмас шикелле.

Инде соңгы вакытта дөнья күргән әсәрләргә күз салыйк. Повестьларның күбесе «Яшь ленинчы» газетасы белән «Ялкын» журналында басылып чыкты. М.Хәсәновның «Шайтан малае», Җ.Рәхимовның «Девон хәбәрчесе», Ф.Яруллинның «Язмышлар язылганда», Ф.Шәфигуллинның «Бер малай, өч аргамак», Р.Хафизованың «Без әле кайтырбыз» повестьлары. Болар һәммәсе узган елда—Бөек Октябрьның 60 еллык юбилее елында дөнья күргән әсәрләр. Шунысы характерлы: повестьлар үзләренең вакыйгалары белән дә 60 елны иңлиләр, бер-берсен эзлекле рәвештә дәвам иттерәләр, вакыйга һәм фикер үсешләрен тулыландыралар, көчәйтәләр. Әйтик, «Шайтан малае» гражданнар сугышы чорын тасвирлый. Бәләкәй генә татар малаеның олы батырлыгын чагылдыра. Шушы кечкенә вакыйганы язучы шактый матур детальләр аша күрсәтеп бирә алган. Җ.Рәхимов исә үзенең «Девон хәбәрчесе» повестенда бүгенге нефть якларындагы сугыш алды елларын, сугыш чорын сурәтли. Андагы кечкенә геройлар—Напалиун, Питыр, Бытбылдык Әхәт, Нәби, Мәрди—авыр сугыш елларында үссәләр дә, бәхетле малайлар. Алар беренче булып буровойны күргәннәр, беренче булып вышкага менгәннәр, шуннан бөтен дөньяны күзәткәннәр, беренче булып нефть исен иснәп караганнар. Шөгер нефте тора-бара ул малайларның язмышына әверелгән. Гомумән, автор геройларының кичерешләрен, хыялларын җылы гына тасвирлаган. Бу бәләкәй повесть та Татарстан нефтенә багышланган әсәрләр рәтенә басарга хаклы.

Ф.Шәфигуллинның «Бер малай, өч аргамак» повесте сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган. Автор үзенең әсәрен укучыга түбәндәге юллар белән тәкъдим итә. «Бала чагыбыз басулары... Игеннәр хуш ис бөрки, чикерткәләр сайрый, юл читендә зәңгәр чәчәкләр балкып утыра— барысы да нәкъ безнең бала чактагыча. Тик хәзер инде монда башка малайлар урак урдыра... Дәһшәтле сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыр еллар икмәгенең кояштай балкып табынга килгәнче нинди юллар узуын беләләр микән дә тракторлар аз чагында җир эшкәртүнең, икмәк үстерүнең кыенлыкларын, кырыс романтикасын күз алдына китерәләр микән алар?

Бу әсәрдә сугыштан соңгы бер урак өстенең ике-өч кенә көне турында сүз бара. Бу әсәрнең асылында—икмәк. Шуңа күрә бәләкәй героем Рәсимнең уй-тойгыларына, кичерешләренә, аның кешеләргә, атларга, хезмәткә һәм, ниһаять, икмәккә булган мөнәсәбәтенә бүгенге укучылар битараф калмаслар дип өметләнәм». Авторның өмете акланды. Повестьтан соң авторга укучылардан бик күп хатлар килде. Язучының әлеге сүзләре дә әсәрнең идея-эчтәлеген, бөтен асылын ачып бирә. Ләкин хикмәт икмәктә генә түгел.

Повестьның уңышы ни белән аңлатыла соң? Иң элек, әлбәттә, татар совет әдәбиятының әлеге чорны чагылдыруда бай тәҗрибә туплавы беләндер. Аннары авторның материалны төгәл белүе, тирән кичерүе һәм әдәби осталыгы да үзенекен итә... Повестьның үзәк герое Рәсим—сугыштан соңгы авыл малайларының типик вәкиле. Дөньяга ниндидер бер ачу саклап яшәүче, шул ук вакытта ат кебек эшләүче Борһанны да без тиз арада танып алабыз. Күрәсең, һәр авылның үз Борһаны булгандыр. Рәсимнең әнисе дә, бригадир хатын да таныш шикелле. Аларның килеш-килбәтләре һәм сөйләшүләре дә хәтергә сеңеп кала. Гомумән, образлар истә калырлык һәм тулы канлы итеп сурәтләнгәннәр.

Яшь кешенең шәхес буларак формалашуы, гадәттә, мәктәпнең соңгы классларына туры килә дигән фикер яши. Ә баксаң, повесть герое Рәсим— дүртенче классны тәмамлаган бот буе малай— шәхес буларак инде өлгереп килә икән. Аның каты күңелле Борһан белән бәхәсләре—чын мәгънәсендә көрәш. Малайның теләк-омтылышлары, эчке каршылыклары оста тотып алынган. Ул Борһанның усал, кансыз икәнлеген дә, эшнең авыр буласын да белә. Ләкин сер бирми. Күңелендәге эчке бер омтылыш, үзенең батырлыгын исбатлау теләге малайны шунда этәрә. Нәтиҗәдә малай җиңүче булып чыга. Ә бит шул малайлар хәзер басуларда иген үстерәләр, КамАЗ төзиләр, тормышның төбенә җигелеп тарталар. Әсәрдәге психологик тирәнлек, нечкәлек сөендерә, ул үзенең табигыйлеге белән күңелне бөтереп ала. Аю егарлык кайбер малайлар, егетләр урамда бер эшсез трай тибеп йөргән бүгенге көндә бу әсәрнең актуальлеге, бәясе бермә-бер арта. Кыскасы, Ф.Шәфигуллин «Бер малай, өч аргамак» повесте белән үз иҗатын да, балалар әдәбиятын да бизәде диясе килә.

Ф.Яруллинның «Язмышлар язылганда» повесте туган җиргә, аның табигатенә, хезмәткә мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Ул бер чите белән демографик проблемага да кагылып китә. Авылларда яшьләр азайган заманда әлеге әсәрнең язылуы, әлбәттә, әһәмияткә ия. Аның сюжеты катлаулы түгел. Председатель кызы—лирик «мин»нең апасы—сигезенче классны бетергәч, башкача укырга теләми, авылда калып эшләргә була. Шул ният белән ул умартачылар курсында укып кайта. Умарталыкта эшли башлый. Аның энесе, ягъни лирик «мин», аңа һәрчак булышып йөри.

Умартачы кыз образы шактый кызыклы, шулай ук каршылыклы да итеп сурәтләнгән. Бар да тәртиптә кебек. Ләкин повестьтагы бер нюанс сискәндереп җибәрә. Һәм ул, әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр дәвам итеп, төп максатка нык кына басым ясаган шикелле. Ул да булса: лирик геройның акча белән артык күп мавыгуы, байлык белән кызыксынуы, бик күп матур әйберләрне байлыкка, материаль якка кайтарып калдыруы. Бу—кайберәүләр тормышында, бәлки, чыннан да шулайдыр. Әмма, ничек кенә булмасын, малайның мещанлык, комагайлык сыйфатлары (автор моны үзе дә сизми булса кирәк) күңелдә авыр тәэсир калдыра. Менә берничә мисал:

«Уйлап табучыларга премия бирәләр. Миңа нәрсә эләгер икән?..

Ә премиягә нәрсә бирәсең?..

Миңа зарплата язарсыңмы соң, әти?..

Рәйханә апаның умарталары баллый башласа, баербыз әле...

Маташып карармын, әмма бушка түгел, туйганчы бал ашатырсың...

Һәр елдагы кебек быел да сабан туе алдынгыларны бүләкләүдән башланды. Безнең өй эченнән генә беркемне дә андый бәхет көтми иде. Әти председатель булгач, үзен-үзе бүләкли алмый. Әни — врач, район кешесе санала. Врачларга премия дә, бүләк тә юк. Менә Рәйханә апага хет берәр яулык бирсәләр, ярап куяр иде».

Повестьның буеннан-буена малайның менә шундый фәлсәфәсе дәвам итә. Әсәрдәге кайбер конфликтлар да, кыз белән ата арасындагы бәхәсләр дә шул фәлсәфәгә корылган. Инде шушыннан чыгып, малайның кем булып үсәсе көн кебек ачык.

Роза Хафизованың «Без әле кайтырбыз» повесте да мөһим темага язылган. Пионер тормышы турында, пионер эшләре турында язу — гомумән мактаулы эш. Чөнки балалар әдәбиятының «күтәрелмәгән чирәме»—әле булса мәктәп, пионерия һәм укучылар дөньясы. Авторның бу темага тотынуы гаҗәп тә түгел. Ул мәктәпләрдә еш була, пионер проблемалары белән яхшы таныш, укучыларның уй-кичерешләрен аңлый, тоя белә. Әсәрдә вакыйгалар бар, материал бар, характерлары белән бик үк яңа булмасалар да, персонажлар да бар. Ләкин биредә әнә шуларны бергә укмаштыра торган җилем юк— илаһи сәнгать юк. Автор вакыйгаларны бер-бер артлы тезеп, сөйләп чыга. Әмма вакыйгаларның фәлсәфи эчтәлеген ачу юк, психологик тирәнлек җитми. Повесть бит нәни хикәя түгел, ул бер генә катлы булмаска тиеш. Анда төрле пластлар, катламнар булуы да шарт.

Повестьның теле дә мактанырлык түгел. Дөрес, һәркемнән Әмирхан Еники осталыгын яисә Хәсән Сарьян телен таләп итеп булмый. Әмма үзебезнең гап-гади татар телебез бар бит әле. Язучы үзенең туган телен яратырга, хөрмәт итәргә бурычлы! Әсәрдә игезәк алымнар, игезәк чагыштырулар, игезәк җөмләләр бик күп. Әйтик, менә мондыйлар: «Әти белән әни бездән көлеп җибәрделәр... Әни, елмаеп, башымнан сыйпады... Ул миңа карап елмаеп куйды... Әти аңа карап елмайды... Ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде... Әти белән Габдрахман абый көлеп куйдылар... Айсылу пырхылдап көлеп җибәрде... Үзләре рәхәтләнеп көлешә башладылар... Мостафа абый елмаеп җибәрде... Ул Фәүзия апага карап елмаеп куйды... Әни елмаеп куйды... Габдрахман абый көлеп җибәрде... Абыем көлемсерәп куйды... Абый шунда ук көлеп җибәрде...» Боларны укыгач, укучы да һич югында елмаеп куячак. Әгәр дә авторга нәшрият тарафыннан ярдәм булса, үзе дә җаваплырак караса, повесть, әлбәттә, уңышлырак чыгар иде.

Яшь буын бабайлар һәм әтиләр данын мирас итеп алды. Хәрби-патриотик тәрбия мәктәп елларыннан ук башлана. Һәм батырлык турында без балаларга һәрдаим исләренә төшереп торырга тиешбез. Ә батырлык һәрчак янәшәдә генә: игенче батырлыгы, эшче батырлыгы, солдат батырлыгы. «Комсомольская правда» газетасында чыккан «Бары дүрт секунд» исемле мәкаләне һәркем укыгандыр. Аның беренче битендәге моңсу йөзле, ләкин бөркет карашлы татар егетенең рәсеменә карап һәркем тетрәнгәндер. Үзенең гранатасы өстенә күкрәге белән капланып һәлак булган, ләкин үз гомере исәбенә иптәшләрен һәм командирларын коткарып калган совет солдаты ул. Газинурлар, Бари Шәвәлиевләрнең энесе. Балалар язучыларына өр-яңа материал. Ләкин батырлык темасына алынырга теләүче язучылар бездә күп түгел. Ә батырлык дәвам итә...

Ш.Рәкыйпов—батырлыкка баш ия, батырлыкка ышана торган язучы. Ул, бер үк темага язса да, әсәрдән әсәргә яңа формалар эзли, таба һәм шуның белән ота да. «Һәйкәлләр янында» повесте да үзенчәлекле формада язылган. Ул—татар халкының күренекле полководецы генерал Гани Сафиуллин батырлыгына багышланган киноповесть. Патетик-публицистик рухта, күтәренке тонда язылган бу әсәрне патетик поэма дип тә атарга булыр иде. Дөрес, ул бигүк йөгерек укылмый. Нишлисең, формасы шундый. Без киноповестьлар укып үсмәгән бит, ә экраннардан карап өйрәнгәнбез.

Хикәя жанрында исә, өлкән һәм урта буын язучылар белән бергә, яшьләр дә актив эшли. Мәсәлән, вакытлы матбугатта кызыклы гына хикәяләр белән Ш.Маннапов, Н.Әхмәдиев, Р.Низамиев, Р.Гыйззәтуллин һ.б. яшьләр катнашты. Һәркайсы үз темалары, үз стильләре белән килүче яшь хикәячеләрнең узган ел күренгән әсәрләре күңелдә өмет уята. Ә менә өлкәннәрдән Гариф ага Галиевнең соңгы вакытта аеруча активлашып китүе яшь укучылар өчен зур куаныч булды. Аның бигрәк тә «Безнең Сафуаныбыз» хикәясе күңелдә торып калган. Ул җан җылысы белән өртелгән. Язучы яшь буынга битараф түгел, балаларга хөрмәт белән, мәхәббәт белән мөрәҗәгать итә.

Ш.Бикчуринның «Табылдык» хикәясенә дә тукталып узасы килә. Фәрит исемле малай, мәктәптән кайтканда, машина астына кереп баручы көчекне, урамда йөрү кагыйдәсен бозып булса да коткарып кала. Аңа милиционердан шактый эләгә, әлбәттә. Малай көчекне өенә алып кайта һәм урамда йөрү кагыйдәләренә өйрәтә башлый. Этне өйрәтә-өйрәтә, ул үзе дә урамда йөрүнең бөтен кагыйдәләрен, юл тәртипләрен өйрәнеп бетә. Ә көчек, әлбәттә, шул килеш кала, бернәрсәгә дә өйрәнә алмый... Әсәр, табигый итеп, балаларча язылган, рәхәтләнеп укыйсың, рәхәтләнеп елмаясың. Нәкъ менә шундый хикәяләр җитми дә инде безгә.

Соңгы вакытта табигый агышлы, табигый диалогларга, табигый уйлануларга корылган хикәяләр языла башлады. Мәсәлән, яшь язучы Камил Кәримов теле, стиле, шигъри фикерләве белән башка хикәячеләрдән аерылып тора. Балаларның эчке дөньясын хикәя юлларына күчерә белүче бу егет киләчәктә әйбәт хикәяче булыр дигән өмет бар. Ә Р.Мингалимовның «Бүген төнлә күккә кара» һәм «Ансар» хикәяләре исә үзләренең хыялга бай, чишелешләренең көтелмәгән булулары белән яңача яңгырыйлар. Риф Мөхәммәтовның турыдан-туры мәктәп тормышына кагылышлы кыска-кыска хикәяләре шулай ук җылы гына тәэсир калдыра.

Балалар вакытлы матбугатында әкиятләргә дә мул гына урын бирелә. Араларында Җ.Дәрзамановның «Язбикә», Г.Латыйпның «Дөл-дөл дөя», Э.Касыймовның «Серле курай» әкиятләре кызыклы гына язылган. Ләкин әкиятләрнең күбесе — һаман да иске калыпка тутырылган «старомодный» әкиятләр, аларның авторларын «татар халык әкиятләрен язучылар» дип атыйсы килә. Фән-техника заманында мондый гына әкиятләр укучыларны һич тә канәгатьләндермидер.

Халкыбызның театр сәнгатенә аерым бер мәхәббәте, хөрмәте бар. Ул балалар арасында да шулай. Бер бәйрәм дә спектакльсез-тамашасыз үтми диярлек. Балалар өчен махсус пьесалар булмаса, зурларныкын алып куялар, «хан заманыннан» калган пьесаларны эзләп табалар. Ничек итсәләр итәләр, барыбер куялар. Укучыларга өр-яңа пьесалар белән очрашу бәхете еш эләкми эләгүен. Шулай да узган елда алар ике пьесалар җыентыгы алдылар: Т.Миңнуллинның «Иптәш командир», Батулланың «Пәһлеваннар иле» китаплары. «Иптәш командир» пьесасы сугыш чоры балаларының батырлыгына багышланган. «Кайда хаклык, кайда дөреслек?» исемле мажаралы комедия бүгенге мәктәп тормышын чагылдыра. Алар һәр икесе балаларның рухына туры килә, «балалар дулкынына» көйләнгән әсәрләр. «Гафият турында әкият» дигән пьеса-әкият тә җор тел белән кызыклы, мавыктыргыч итеп язылган. Аны укыганда туктаусыз көләсе килү хисен кичерәсең. Ләкин шуны искәртергә кирәк: биредә әкият жанры белән реаль тормыш вакыйгалары бутала кебек. (Бу Батулла әсәрләрендә дә сизелә.) Персонажлар әрепләшкән вакытта артык реалистик итеп әрепләшәләр. Бер-берсенә «карт җен», «хәшәрәт» һ.б. дип дәшәләр. Әйтик, пьесадагы җен карт та булсын, юхасы да бик кыяфәтсез булсын, ди. Ләкин әкияттә каргану да әкиятчә һәм, әлбәттә, мәдәни булсын иде. Әйтик, дию пәрие убырлы карчыкка «чибәрем» дип дәшсә, шүрәлене «акыллым» яки «фикер иясе» дип үртәсәләр, ничек җанлы чыгасы!

Батулла китабына курчак театрлары өчен дүрт пьеса кертелгән. Аларның икесе Казан курчак театрында уңыш белән уйнала. Бу үзе үк пьесаларның уңай якларын раслап тора. Шулай да авторның, кирәксә дә, кирәкмәсә дә, иске сүзләр белән артык мавыгуы сизелә. Гомумән телгә, сүзгә карата талымсызлык, әледән-әле очрап торган дорфалык һәм ясалмалык пьесаларның тәмен җибәрә. Алардагы җыр текстлары да, безгә калса, канәгатьләнерлек түгел. Әсәрләрне бизәмиләр, киресенчә, аерылып, әсәрдән бүселеп чыгып торалар алар.

Узган елда мәктәп яшендәге укучыларга кайбер публицистик әсәрләр дә тәкъдим ителде. Шуларның берсе—В.Ихсанованың «Тырыш хуҗалар илендә» исемле китабы. Ул укучыларны партиябезнең XXV съезды куйган олы бурычлар белән таныштыра, унынчы бишьеллыкка сәяхәткә алып чыга, бишьеллыкта эшләнгән һәм эшләнәчәк зур эшләр турында укучылар күңеленә барып җитәрлек итеп сөйли. Автор үзен иркен сизә, кем белән әңгәмә алып барганын яхшы аңлый, әңгәмәдәшләрен нәрсәләр кызыксындырганын яхшы белә. Китапның буеннан-буена авторның үткен телле публицист һәм тәҗрибәле педагог булуы сизелеп тора.

«Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китап М.Госмановның элекке әсәрләренә аваздаш. Укучыны ул ерак тарихка алып китә, Туваның бүгенгесе белән таныштыра. Азия үзәгенең экзотик гүзәллеге, кабатланмас табигате укучы күңелен шундук яулап ала. М. Госманов, галим буларак та, язучы буларак та, балалар өчен әйбәт китап язган.

Табигать турында, тереклек, кош-корт турында язганда балалар психологиясен, яшь спецификасын исәпкә алмаска да мөмкин дип санаучылар бар. Ләкин үзенең тормыш тәҗрибәсе белән баладан уздырган язучы табигатьне күрә белүе белән дә, табигатькә соклана, гаҗәпләнә белүе белән дә баладан калышмаска бурычлы. Аның табигатькә бала күзе белән дә, язучы күзе белән дә, табигать белгече буларак та каравы мәҗбүри. Табигать, кош-корт турында язылган һәр әсәр балаларны кешелекле итеп, гуманлы итеп тәрбияләүгә хезмәт итәргә тиеш. Бу җәһәттән, Г.Хәсәновның «Ялкын»да басылган парчалары матур тәэсир калдыра. Г.Шәрәфинең «Яшь ленинчы»дагы «Күрше малае» исемле хикәяләр циклы да кечкенәләргә атап язылган. Тереклеккә, табигатьтәге һәртөрле җан иясенә мәхәббәт хисләре җор тел белән язылган хикәяләрдә шулай ук зур урын алган.

Балалар өчен язылган шигырьнең беренче вазифасы—Туган илгә, кешеләргә мәхәббәт тәрбияләү, шул ук вакытта бала күңеленә туган телебезнең тәмен, тирәнлеген, нечкәлеген, шигърияттен сеңдерү. Бирелдә инде гадилек кирәк. Корней Чуковский үзенең «Икедән бишкә кадәр» китабында балалар шигыренең 13 хасияте бар дип искә ала. Менә шуларның берничәсе:

— Шигырьнең һәр строфасы рәссамга материал булырга тиеш. Ягъни шигырь юллары күз алдына килерлек булсын.

— Шигырь музыкаль булырга тиеш.

— Рифмалар мөмкин кадәр бер-берсенә якынрак булырга, ягъни янәшә булырга тиеш.

— Шигырьнең һәр ике юлы, һәр строфасы төгәлләнгән булырга тиеш һ.б.

Бездә әле К.Чуковскийның әлеге принципларын күпләр белми, белсә дә куллана алмый кебек. Кайсы гына балалар китабын алып укысаң да, алар традицион халык җырлары калыбына шыплап тутырылган булыр: 8 дә 7, 8 дә 7. Бу бертөрлелек нәниләрне, әлбәттә арыта, туйдыра. Өстәвенә рифмалар да янәшә түгел. Нәтиҗәдә шигырьнең динамикасы, тыгызлыгы, бөтенлеге югала. Андый шигырьне бала хәтерендә калдыра алмый. Ә инде хәтердә калмый икән, шигырьне балалар яттан сөйләп йөрми икән, шигырь үз максатына ирешмәде дигән сүз. Нәниләр поэзиясендә, образлар белән беррәттән, шигырь техникасы һәм шигъри тел дә зур әһәмияткә ия. Шигырь нәниләр өчен мавыктыргыч уенга әверелергә тиеш. Әмма уенга әйләнерлек, ритмик яктан төрле рәвешләр алган шигырьләр юк дәрәҗәсендә аз иҗат ителә.

Нәниләр өчен язылган шигырьләр туган телне өйрәнүнең беренче күнекмәләрен бирә. Шуңа күрә дә биредә сүзгә аеруча сак булу шарт. Шигырьдәге сүзләр зәвык белән сайлап алынган булырга тиеш. Сүз тезмәләре, шигырь юлларының ювелирларча эшкәртелгән булуы зарури. Чөнки бала нәкъ шул яшьтә үз теленең тәмен, кадерен белергә өйрәнә. Бу яшьтә аны үз телен яратучы, хөрмәт итүче итеп тә тәрбияләргә мөмкин, киресен дә эшләп була.

1977 елда Б.Рәхмәт, З.Туфайлова, Р.Мингалимовның сайланма шигырьләре укучылар кулына барып иреште. Нәшрият төсле рәсемнәр белән бизәлгән ике бөртек китап та чыгарды. Р.Фәйзуллинның «Көмәч пешерүчеләр җыры» исемле шигыреннән гыйбарәт булган уч төбе кадәрле китап һәм Р.Бәшәровның матур гына ун шигырьдән торган «Бәйрәм» исемле җыентыгы.

Балалар поэзиясендә өлкән шагыйрь Зәки Нури актив эшләде. Аның вакытлы матбугатта чыккан шигырьләре дә, «Уйлан да син, елмай да син» исемле яңа җыентыгына кергән сатирик һәм юмористик парчалары да Зәки Нурига гына хас чәнечкеле юмор һәм үткен сатира белән сугарылган. Алар укучылардагы кимчелекле яклардан көлә, матур гадәт һәм әхлакый нормалар өчен көрәшә...

Роза Хәлиуллинаның «Чүкеч—нәни булышчы» җыентыгында матур гына шигырьләр бар. Ләкин бик наив һәм эшләнеп бетмәгәннәре дә юк түгел. Мәсәлән, «Чүкеч» шигыре болай төгәлләнә:

Кулга чүкеч алганнар
Ташка кадак кагарлар,
Хезмәт кадерен белерләр,
Бәхетләрен табарлар.

Ә бит бала, бу сүзләрне укыгач ук, бәхетле булыр өчен, һичшиксез, кулга чүкеч алырга кирәк икән дип уйлаячак һәм әтисен кибеткә чүкечкә йөгертәчәк. «Ә чүкеч тотмаганнар бәхетсез буламы?»—дип тә сораячак.

Ә менә бу дүрт юллык шигырьне ни дип аңларга?..

Шырпы тартмасына сыйган
Нәп-нәни эт, һай, матур.
Бик үртәсәң, түш кесәңә
Керер дә... ырлап ятыр.

Нәрсә бу? Шигырьме бу? Ни өчен әлеге җыентыкка килеп кергән ул? Аңлашылмый.

Р.Мингалимовның «Бәхетле исем» китабына укучыга таныш шигырьләр белән күп кенә яңа әсәрләр дә тупланган. Кереш сүз авторы Х.Камалов болай ди: «Р.Мингалимов шигырьләре табигый килеп чыга, бернинди ясалмалылык, үз сүзен укучыга көчләп тагарга тырышу кебек нәрсә аңарда сизелми. Ул үгетләрен дә, мораль чисталыкка, сәяси сизгерлеккә өйрәтүен дә, артык нык сиздермичә, ләкин, күңелгә мәңгегә сеңеп калырлык итеп, сәнгатьчә тәкъдим итә белә... Аннары бала өчен шигырьнең мавыктыргыч булуы да бик кирәк бит әле. Бу яктан да Р.Мингалимов татар балалар поэзиясендә үзенә күрә ачышлар ясый. Ачышның асылы болайрак: автор баланың хыялга бай күңелен үзенә ияртә белә, табигый булмаган хәлне дә табигый итә ала һәм шул контраст-хикмәт белән бала күңелен җәлеп итә». Чынлап та, Рөстәмнең балалар поэзиясендә үз юнәлеше, табышлары бар. Аның киң колачлы фантазиясе, бала күңелендәге зәңгәр хыялга тәңгәл килеп, аның белән бергә үрелә бара. Ул баланың үз фантазиясе булып кабул ителә. Шагыйрьнең нәни геройлары бераз сәеррәк тә, хыялыйрак та. Әмма кайчакта шагыйрь үзе шул хыялый малайларны да уздырып җибәрә. Малайларның түгел, аксакалларның да күз алдына килмәслек образлар тудыра, үзе дә сизмәстән, хыял стихиясенә бирелеп китә. Аның шигырьләренең балалар күңеленә барып ирешүенә тоткарлык ясый торган бер «ләкин» дә бар. Ул—шигырь техникасының кайбер очракларда артык катлаулы булуында. Р.Мингалимов зурлар шигъриятендә үзе кулланган формаларны, шигъри техниканы, әйләнмәләрне турыдан-туры балалар поэзиясенә күчерергә тырыша кебек. Шигырьдә форма белән эчтәлек ярашмаса, балалар аны кабул итә алмыйлар—укый башлагач та абыналар да шигырьне әйләнеп үтәләр. Мәсәлән, Э.Межелайтис та — гаҗәп катлаулы шагыйрь. Үзе балалар өчен дә яза. Аның әнә шул шигырьләре шул- кадәр гади, самими, хәтта Межелайтис язганына да ышанасы килми. Күрәсең, бу ике поэзия бер-берсеннән халәтләре, хасиятләре ягыннан нык аерылалардыр.

Әдхәт Синегуловның «Чалгы җыры» китабындагы беренче шигырь үк сагайтып җибәрә. «Көнебез бакчада үтә, без әлегә—нәниләр» дигән юллар бар анда. Ә бит безнең беребез дә «мин—бәләкәй язучы» димәгән кебек, дөньядагы бер генә бала да «мин—бәләкәй, мин—нәни» дип әйтмәс. Бу сүз җыентыкта бер генә урында да очрамый әле. Ул— шагыйрьнең үз сүзе, бала сүзе түгел, ул—шагыйрьнең бала булып кылануы. Күрәсең, баланың кызык та, мавыктыргыч та дөньясына үтеп керә алмау, бала күңелен аңламау, белмәү авторга коры, ясалма шигырьләр тудырырга булышкан. Менә тагын «Уенчыклар уены» исемле шигырь. Ул түбәндәгечә тәмамлана:

Үгез ялгыш шулчакны
Сөзде екты курчакны.
Көлке булды шулчакны.

Бала булса, әлбәттә, бу усаллыктан курчакны жәлләп елап җибәрер иде. Кайгырыр иде, курчакны юатыр иде. Ә лирик герой, ягъни автор, шушы хәлдән авызын ерып тора. Әгәр дә чистартып, иләп, җилпеп чыгарсаң, әлеге җыентык сыйфаты ягыннан бу кадәр фәкыйрь булмас иде. Чөнки әйбәт кенә шигырьләр дә бар анда.

С.Шакирның «Яңгыр тамчысы» китабы гадәти шигырьләрдән тора. Арада җылы гына язылганнары бар, табышлар да очрый. Тик менә «Милиционер Ханнан» шигыре бераз гаҗәпкә калдыра. Степа дәдәйнең киресе буларак, ул кечкенә — йомгак кебек. Әмма кечкенә булса да, аннан бер дә ким түгел:

Көтүдәге үгез качкач,
Милиционер Ханнан

Аның мөгезеннән тотып
Җиргә аударып салган.

Көтүдән качкан үгезләрне дә хәзер милиционерлар эзли микәнни? Югыйсә аларга башка эш тә җитәрлек ләбаса! Аннары, качса да, үгезне нигә җиргә аударып салырга тиеш әле ул? Шигырь болай төгәлләнә: Ханнан Сабантуйда үзе хәтле ике пәһлеванны җиргә сала да мәйданнан чыгып китә. Аңа бүләк өяләр. Ләкин ул кул гына селти: «Мин—милиционер Ханнан, бурычымны үтәдем»,—ди. Бәй, теге пәһлеван дигәнебез хулиган яки рецидивист булып чыккан түгелме соң? Милиционерның бурычы нәкъ шуларны тоту бит...

Җ.Дәрзамановның «Солдат булдым» исемле җыентыгы И.Әхмәдиевнең матур рәсемнәре белән бизәлеп чыккан. Шагыйрьнең балаларны яратуы, аларга изге бер эш эшлисе килүе күренеп тора. Аның геройлары — тиктормаслар, шаяннар, беркатлылар һәм сөйкемлеләр дә. Җәүдәтнең шигырьләре якты, җылы, хәрәкәтчән. Аларда артык сүзләр, артык җөмләләр юк. Ул шигырьләрне оста итеп үрә белә, ритмик сиземләве көчле. Бер генә теләк бар: балалар дөньясына ныграк үтеп керергә иде. Балалар дөньясы үзе бер континент бит. Алар тимераякта яки чанада гына шумыйлар, балык кына тотмыйлар...

Безнең халыкта легендар геройлар бар: Алып батыр, Хуҗа Насретдин, Шомбай... Боларын халык уйлап чыгарган, ә бәлки, чыннан да булганнардыр. Шуларга өстәп, Ш. Галиев тә үз иҗатында күп кенә популяр геройлар тудырды. Сәйфетдин, Котбетдин мәргән, татар балаларының яраткан герое Хуҗа Насретдинның оныгы—Шәвәли, Хәлим, Сәлим, Мәсәлим... Шагыйрь, бу геройларын бергә җыеп, мөгаен, берәр күңелле шигъри пьеса да язар әле. Узган ел балалар шагыйрьнең яңа герое «Булат хикмәтләре» белән таныштылар. Бу малай белән дә укучылар чын-чынлап дуслашыр дип ышаныйк.

Х. Халиковның Леонид Ханбиков тәрҗемәсендә «Кәнфит агачы» исемле китабы рус телендә чыкты. «Яшь ленинчы»да шигырь белән язылган уеннары, яңа шигырьләре дә дөнья күрде. Авторның кечкенә уеннары җиңел тел белән язылган, һәрберсенә тәрбияви мәгънә салынган була.

Рәшит Әхмәтҗановның тирән эчтәлекле лирик шигырьләре, Ф.Яруллинның оптимизмга, батырлыкка әйдәүче әсәрләре, Н.Мадьяровның туган җиргә мәхәббәт хисләре белән язылган парчалары, И.Юзеевның «Бакчачы турында баллада»сы укучыларга менә дигән шигъри бүләк булды. Р.Гәрәй, Ф.Сафин һәм М. Әгъләмовларның балалар рухын тоеп, оста язылган шигырьләрен укып та шатланмый мөмкин түгел.

Балалар хәзер русчаны туган телләре кебек үк яхшы беләләр. Шуңа күрә дөнья әдәбияты тудырган шедеврлар алар игътибарыннан читтә кала алмый. Ләкин ничек кенә булмасын, укучыларыбыз (биредә авыл укучылары күздә тотыла) иң элек үзебезнең татар язучылары әсәрләрен укып баралар. Һәм, әйтергә кирәк, рәттән, сайламый-нитми укыйлар. Татар язучылары бу яктан горурлана ала. Ләкин әлеге рәттән укып баруның һәм уңай, һәм тискәре яклары бар. Күрүебезчә, яхшы әсәрләр белән бергә, әле өлгереп җитмәгән, зәвыксыз, татар әдәбиятының дәрәҗәсен, бәясен төшерә торган әйберләр дә укучылар кулына барып керә тора. Ә бит нәни яисә яшүсмер укучы аларның һәр икесен дә еш кына «саф алтын» итеп кабул күрә. Без бүген тәрбияләгән балалар—XXI гасырда яшисе кешеләр. Аларның интеллектлары, фантазияләре, күңелләренең сафлыгы ни дәрәҗәдә булыр? Бу кадәресе— безнең дә өскә төшкән олы җаваплылык. Балалар өчен язу—ул иртәгәсе көннең өлкән укытучыларын әзерләү, аларда эстетик зәвык булдыру. Әгәр дә без киләчәк буынны уртакул әйберләр белән генә тәрбияләсәк, аларның якты хыялларын, күңелләрен шул начар әсәрләр белән алдасак, аларның зәвыкларын тупасландырсак, алар безне бервакытта да кичермәсләр. Кичермәсләр!

*1978*

## Үз җырларын җырлатыйк!

(*Балалар җыры турында уйланулар*)

Һәркемнең үз җыры булырга тиеш. Шул исәптән балаларныкы да. Кызганыч ки, соңгы берничә елда балаларыбыз яратып җырларлык балалар җыры бөтенләй язылмады диярлек. Сүз дә юк, балалар өчен музыка өлкәсендә эшләнми түгел, эшләнә. Безнең инде беренче (әлегә соңгысы да) балалар операсы бар, беренче кантата язылды, беренче балалар балеты язылып ята. Концертларда, еш булмаса да, инструменталь әсәрләр дә яңгырый тора. Балалар музыкасын пропагандалауда телевидение зур эш башкара, радио буенча махсус тапшырулар алып барыла. Ләкин музыканың әлеге жанрлары, билгеле сәбәпләр аркасында, вакытында һәм һәрвакыт киң катлам балаларга барып ирешә алмый. Балаларга җыр да кирәк! Концертларда, бәйрәм тантаналарында, пионер сборларында, походларда җырлар өчен октябрятлар җыры,

пионерлар җыры кирәк. Күңелләрен күтәреп җибәрә торган, яңа җиңүләргә әйдәүче, шат күңелле, батыр йөрәкле саф-таза егетләр-кызлар булып үсәр өчен кирәк аларга җыр.

Балаларга теләсә нинди җыр түгел, үз җырлары кирәк! Аларның үз җырларын үз телләрендә бик тә җырлыйсылары килә. Бер генә мисал китерәм. Соңгы вакытта балалар өчен рус композиторлары тарафыннан бик матур җырлар иҗат ителде. Мин шуларның берсен—«Крокодил Гена җыры»н — татар-чага тәрҗемә иткән идем. Ул иң элек телевидение буенча «Әллүки-бәллүки» тапшыруында җырланды, «Яшь ленинчы» газетасында да нотасы белән басылып чыкты. Шуннан соң редакциягә укучылардан, башка шундый ук популяр җырларны да тәрҗемә итүебезне сорап, хатлар ява башлады. Нәтиҗәдә «Зәңгәр вагон», «Елмаю», «Кызыл калфак» кебек җырлар да татарчага тәрҗемә ителде. Аларны әле дә татарча җырлыйлар булса кирәк. Бу үзе генә дә— үзебезнең җырларга кытлык булуы турында сөйләүче факт.

Җырлар, билгеле, язылмый тормый. Радио аша да яңа җырлар яңгырап тора, балалар матбугатында да нотасы белән басыла бара. Алар профессиональ күзлектән караганда оста да язылгандыр. Әмма ничек кенә оста язылмасыннар, ул җырларның күпчелеген балаларыбыз җырламый. Җырлый да алмый. Җырлыйсылары да килми. Беренчедән, аларның күбесе җиңел кулдан гына, примитив язылалар. Аларның, гадәттә, көе дә, моңы да булмый. Икенчедән, тематик ярлылык үзен бик нык сиздерә: мәктәп, пионерия, поход, уку, тимурчылар... Булган кадәресе дә коры риторик сүз тезмәләреннән гыйбарәт. Шуңа күрә дә без аларны җыр тексты яки җыр сүзләре дип кенә йөртәбез дә. Ә бит алар, чынында, җыр шигырьләре булырга тиеш. Балаларның үз дөньяларыннан, үз уеннарыннан, үз шөгыльләреннән алып язылган җанлы, хәрәкәтчән, шаян җырлар җитми безгә. Шәүкәт Галиев үзенең бер чыгышында: «Безнең җырлар радио капкасына менеп кычкырудан ары китә алмыйлар»,—дигән иде. Бу сүзләр белән ничек килешмисең инде. Тик шунысы: җырларның күбесе радио капкасына да менеп куна алмыйлар, егылып төшәләр.

Балалар җырының дефицит булуы, мөгаен, бу өлкәдә махсус шөгыльләнүче композиторларның һәм шагыйрьләрнең булмавыннан киләдер. Күпчелек композиторларыбыз, мәсәлән, балалар өчен әйбәт-әйбәт әсәрләр иҗат итүләренә карамастан, балаларга җыр язуны икенчел эш итеп кенә саныйлар, берәр редакция, радио-телевидение сораган очракта гына язгалыйлар. Шундый композиторлар рәтенә Р.Яхинны, М.Яруллинны, Ф.Әхмәтовны, Р.Еникеевны, И.Якубовны, Ф.Әбубәкеровны кертергә мөмкин. Шагыйрьләрдән исә Р.Вәлиев белән Х.Халиковтан башка берәү дә юк шикелле. Һәрхәлдә, балалар өчен яңа җырларны без нәкъ менә шушы иптәшләрдән көтәргә бурычлыбыз.

Балалар җырының кризис кичерүендә бер композитор белән шагыйрьне генә гаепләргә ашыкмыйк. Аларны да аңларга мөмкин. Ярый, җыр язылды да, ди. Аны кемнән җырлатырга? Дөрес, кайбер мәктәп-ләрдә, музыка мәктәпләрендә шактый гына тәҗрибә туплаган хор коллективлары эшләп килә. Профессиональ дәрәҗәдә булмасалар да, алар үз вазифаларын үтиләр. Һич югында, алардан үтенергә мөмкин. Ләкин алар әле җырны кайчан өйрәнә, ничек җырлый, кайда һәм кайчан җырлый? Билгесез. Радио-телевидениенең балалар редакцияләре дә кызыгырлык хәлдә түгел. Андагы иптәшләр авторлардан ялына-ялына җыр яздыртып алалар. Аннары хор коллективларына, мәктәпләрдәге үзешчән сәнгать түгәрәкләренә, укучы балаларга мөрәҗәгать итәләр. Кыскасы, башкаручыны эзләү башлана. Табышлар, әлбәттә, еш булмый. Шуңа күрә дә күп очракта әлеге яңа җыр профессиональ җырчыга бирелә. Күз алдына китереп карыйк: радио буенча балалар җыры яңгырый. Бас, тенор яисә сопрано тавышлы җырчыбыз тырыша, бала булып кылана, тавышын баланыкына охшатырга тырышып карый, ләкин юкка гына. Җыр барыбер табигый ишетелми, көтелгән нәтиҗәне бирми. Әйбәт кенә җыр да, ни балаларныкы, ни олыларныкы була алмыйча, ике арада буталып кала. Әйе, бездә балалар җырын өлкәннәр җырлый. Ә менә балалар үзләре, ничек кенә парадокс булмасын, зурлар җырын ныграк яраталар. Күп мәртәбәләр укучылар концертында катнашырга туры килгәне бар. Иң элек берничә традицион пионер җыры башкарыла. Аннары кечкенә бер кыз, сәхнә уртасына чыгып баса да, «Беренче мәхәббәт»не сузып җибәрә:

Онтылмый беренче саф мәхәббәт,
Онтылмый Агыйдел сылуы...

Икенче җыр да мәхәббәт яисә яшьлек, яшьлекне сагыну турында булып чыга. Тамашачылар да моңа күнегеп беткән. Елмаймыйлар да хәтта. Ә бит елмаер урын бар. Бу очракта, әлбәттә елмаерга түгел, мәхәббәт турында җырлаган кызыйны кызганырга кирәк. Әгәр дә яратып җырларлык балалар җыры булса, җырламас иде ул аны.

Әйткәнемчә, балалар җырының язмышы композитор белән шагыйрьдән генә тормый. Башкаручы да кирәк. Бу исә, үз чиратында, музыкантларның, башкаручыларның энтузиазмына да бәйләнгән. Әлеге җәһәттән, талантлы музыкант, оештыручы һәм педагог Алсу Гарифуллинаны атап китү дә җитә. Ул оештырган «Ләйсән» ансамбле безнең балалар эстрадасына ямь өстәп, канат куеп җибәрде. Ул балалар җырларын башкару сәнгатен яңа төсмерләр белән баетты. Республикабызда үзешчән балалар сәнгатен

күпмедер дәрәҗәдә җанландырып җибәрүгә ярдәм итте. Кайбер композиторлар ансамбль өчен махсус җырлар яздылар. Гадәти генә булып тоелган, әле моңа кадәр сирәк кенә яңгыраган җырлар да «Ләйсән» башкаруында бөтенләй яңача яңгырый башлады. Ансамбль хәтта иске, онытылган җырларны да (мәсәлән, утызынчы елларда җырланган «Зәкәрия-Кәрия»не) яңадан сәхнәгә кайтара алды. Яңа коллектив хаклы рәвештә бөтен Союз күләмендә яңгыраш тапты. Без инде «Ләйсән»гә ияреп шундый ук яңа ансамбльләр ишәеп китәр дип көткән идек, ләкин алай булып чыкмады. Бу хәлне балалар эстрадасына, балалар җырына өлкәннәрнең игътибары җитеп бетмәүдән дип аңлатырга кирәктер, мөгаен. Казанда, мәсәлән, балалар коллективларының югары дәрәҗәдә оештырылган концертлары булганы бармы? Ә менә Мәскәүдә зур-зур бәйрәм концертларында да, телерадиотапшыруларда да балалар бик теләп катнашалар. Һәм концертларга ямь генә өстиләр. Чөнки балалар сәнгате дә—чын сәнгать. Сәнгатьнең исә олысы-кечесе булмый. Бәс шулай икән, безнең концертларда да, радио һәм телевидение буенча бирелгән концертларда да балалар башкарган җырларны кертеп җибәрергә мөмкин түгелмени? Балалар җыры музыка белгечләренең игътибарыннан да читтә кала бирә. Композиторларыбыз сирәк яза икән, халык җырларын карап чыгарга, аларны бүгенгә яраклаштырып эшкәртергә, аларга яңа сүзләр яздырырга булыр иде. Нигә сынап карамаска?!

Безгә калса, радио-телевидение каршында махсус йә балалар хоры, йә профессиональ ансамбль оештырып җибәрергә вакыт җитте булса кирәк. Бу мәсьәлә күптән өлгерде, һәм аны кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Казанның үзендә генә дә музыка  мәктәпләре, музыка училищесы, консерватория бар. Иҗат көчләре җитәрлек! Теләк, максат кына кирәк. Бәлки, балалар өчен иҗат итүчеләрне бергә туплаучы берәр үзәк (секция, совет, комиссия һ.б.) оештырырга кирәктер?! Анда ВЛКСМ өлкә комитеты, мәгариф һәм мәдәният министрлыклары, радио-телевидениенең балалар редакцияләре, балалар матбугаты катнаша алыр иде. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе каршында күптән түгел яңа балалар бүлеге эшли башлады. Бу мәсьәлә аның да турыдан-туры вазифасына керәдер, мөгаен. Ул чагында композиторлар һәм язучылар оешмалары да читтә калмас иде. Балалар җырларына күптән инде конкурслар да уздырылганы юк. Оештыруның ул формасын да онытып бетерергә ярамыйдыр. Болары—теләкләр рәвешендә әйтелгән фикерләр. Әмма әлегә теләк теләүдән уза алганыбыз юк. Балаларыбыз күбрәк һаман «Беренче мәхәббәт»не, «Крокодил Гена җыры»н, «Чебиләр»не җырлый. Без бәләкәй чакта малайлар этиләренең, абыйларының иске, олы бүрекләрен киеп йөриләр иде. Малайларның үзләренә бик ошагандыр ул: үзләрен этиләре, абыйлары кебек олы, батыр итеп хис иткәннәрдер. Әмма читтән караганда малайлар кызганыч һәм көлке булып күренгәннәрдер. Безнең бүгенге малайлар-кызлар да шундыйрак хәлдә түгелме соң? Әйдәгез, малайларга үз бүрекләрен кидертик! Кыяфәтләре белән дә, эчке рухиятлары белән дә матур булып үссеннәр алар. Матур күңелле булып үссеннәр өчен аларга матур җырлар да кирәк. Үз җырлары!

*1981*

## Ана сөте белән!

Ана сөте белән керә безгә шигърият. Әнкәйләрнең бишек җырлары белән. Әбиләребезнең уйнатканда, шаяртканда, сөйгәндә әйткән такмак-такмазалары белән.

Бала туу белән шигърият дөньясына килеп эләгә. Аның сабый күңеленә, аңына җыр-шигырьнең мәгънәсеннән бигрәк моңы, көе, ритмикасы барып ирешә. Ягъни шигырьгә баланың иң элек колагы күнегә. Ишекнең ачылып ябылуы да, әнисенең якынлашып килүче адымнары да, үзе белән көйли-көйли сөйләшүе дә... Болар барысы да баланы шигырьгә якынайта. Аннары инде, бераз үсә төшкәч, шигърият белән турыдан-туры танышу. Өлкәннәр укыган шигырьләр, рәсемле китаплар, радио-телевидение аша сөйләнгән шигырьләр аша.

Шигырьне һәр бала ярата. Чөнки үзе дә табигате белән шагыйрь әле ул. Табигать баласы. Аңы әле аның тормыш мәшәкатьләре, һәртөрле кирәкмәгән информация белән чуарланып өлгермәгән. Ул күбрәк тәэсирләр белән яши. Такмаклап, гап-гади сөйләмдә дә рифмалап сөйләшергә ярата.

Шунысы гаҗәп: балачакта әйтелеп йөргән такмаклар, җырлар, шигырьләр күңелгә шулкадәр сеңеп кала, алар һич уйламаган бер вакытта телгә килеп керәләр дә безне яңадан балачакка алып кайталар. Кечкенәдән күңелдә калган шигъриятнең әнә шундый тылсымлы сыйфаты бар.

Шулай. Шигырь яратмаган бала булмый. Тик аны сүрелдермәскә, сүндермәскә генә кирәк. Монысы инде—безнең уртак бурычыбыз. Ата-аналарныкы  да, укытучыларныкы да, тәрбиячеләрнеке дә, шагыйрьләрнеке дә—барыбызныкы да. Без аларга нинди шигырьләр укытабыз? Нинди шигырьләр тәкъдим итәбез? Газета-журнал битләрендә, китапларыбызда нинди шигырьләр бастырабыз? Кызганычыбызга диик, кайбер очракта балаларга һич тә кирәге булмаган, рухларына бөтенләй туры килмәгән, балалар дөньясыннан бик ерак торган шигырьләр булып чыга алар. Без еш кына, әдәби яктан да, педагогик яктан да зәгыйфь

шигырьләрне матур-матур төсле рәсемнәргә төреп, шул рәсемнәр артына яшереп чыгарырга тырышабыз. Газеталарның беренче битенә үк эре хәрефләр белән биреп карыйбыз. Үзебез дә сизмәстән, балаларда зәвыксызлык тәрбияләүнең игелексез юлларыннан файдаланабыз.

Кайбер дәреслекләрне генә алыйк. Әле ярый соңгы елларда алар яңа шигырьләр исәбенә шактый яңартылды, тулыландырылды. Әмма барыбер алар арасында әле әдәби яктан да, информацион яктан да, тәрбияви яктан да нык искергән шигырьләр очрый. Аларның күбесе—балалар поэзиясе үрнәкләре дә, олылар шигърияте дә түгел. Ике арада буталып калган кызганыч сүз тезмәләре генә. Бала шуларны укырга, хәтта ятларга мәҗбүр. Бу теше сызлаган балага кәнфит тоттырган кебегрәк булып чыга инде.

Гомумән, бала шигырьнең үзенә ошаганын сайлап алырга, ятларга тиеш. Дөрес, алар классикларыбызның шигырьләрен, һичшиксез, яхшы белергә бурычлы. Ләкин бөек шагыйрьләребезнең дә шигырьләре мәктәп хрестоматиясендәгеләр белән генә чикләнми бит. Әйтик, мондый күренеш. Класста — кырык бала. Аларның һәммәсе дә Пушкинның яки Тукайның бер шигырен билгеле бер дәрескә ятлап килергә тиешләр. Башта аны укытучы укып күрсәтә. Аннары шул ук шигырьне кырык бала бер-бер артлы ятлап чыга. Баланың һәрберсе аны кырык тапкыр тыңларга тиеш була. Бу, бәлки, ятлар өчен, истә калдырыр өчен әйбәттер дә. Ләкин биредә менә дигән шигырьнең дә тәме югалырга мөмкин. Әгәр дә һәр бала шул ук Пушкинның яисә Тукайның үзе яраткан шигырен ятлап килсә? Ул чагында укучыларның да шагыйрьгә булган кызыксынулары бермә-бер артыр иде, шагыйрьнең иҗаты да киңрәк колач белән өйрәнелер иде. Һәрхәлдә, биредә уйланасы әйберләр җитәрлек. Яңа мәктәп программалары көтелә. Шигырьгә булган мөнәсәбәт, бәлки, аларда үзгәрер?!

Аннары мәктәпләрдә моңа кадәр санаулы гына шагыйрьләр, санаулы гына шигырьләр өйрәнелде, нигездә классикларыбыз. Ә бүгенге көндә актив иҗат итүче күпме шагыйрьләребез читтә кала бирә. Дәрестә дә бер үк шигырь, бәйрәмнәрдә дә, төрле концерт-кичәләрдә дә бер үк шигырь яңгырый. Шуңа күрә дә, күпме генә шәп булмасын, шигырьнең тәэсир итү көче кими, ул ялкыта, туйдыра. Балага, һичшиксез, яңа, әйбәт шигырьләр кирәк. Әмма нинди шигырьләр кирәк соң аңа?! Иң элек, әлбәттә, Балалар Шигыре! Үзләре турында язылган шигырьләр. К.Чуковскийның балалар шигыре турындагы мәгълүм унөч хасиятенә туры килсә генә, бала шигырьне кабул итәчәк. Балалар белән эшләү тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: бала, чыннан да, шигырьгә мохтаҗ. Тик ул аны үзе укырга һәм ятлап алырга тиеш. Бу—балалар шигыренә куелган иң зур таләпләрнең берсе. Ләкин кайбер шагыйрьләрнең шигырьләрен балалар бөтенләй укый алмый. Беренчедән, алар кытыршы. Укый башлауга, абыналар, сөртенәләр. Икенчедән, шигырьдәге сүзләрнең мәгънәләренә алар тиз генә төшенеп җитә алмыйлар. Бала ятлый алмый икән инде, ул балалар шигыре түгел дигән сүз. Вакыйгасыз, предметсыз шигырьләрне дә бала авыр ятлый. Мин моны «Шигъри тәлгәшләр» тапшыруларын оештырганда еш сиздем.

Ә «Шигъри тәлгәшләр», гадәти тапшыру булудан бигрәк, балалар өчен шигърият дәресләре дә булгандыр дигән ышанычым бар. Балаларда шигъри зәвык тәрбияләүдә, аларда шигырьгә мәхәббәт уятуда, әдәбиятка якынайтуда әлеге тапшыруларның азмы-күпме файдасы булмый калмагандыр. Күп санлы хатларга, җәмәгатьчелек тарафыннан әйтелгән фикерләргә караганда, ул тапшыруларны телетамашачылар яратып карый. Аларның иң отышлы ягы шунда ки, анда шигырьләрне балалар үзләре укый. Шигырь табигый яңгырый. Балага ныграк аңлашыла, тизрәк барып җитә. Шуны да әйтергә кирәк: ул тапшыруларны тыңлаучылар гына түгел, анда катнашырга теләүчеләр дә бик күп. Моннан берничә ел элек без телевидениедә балалар тапшыруларында катнашырга теләүчеләргә конкурс уздырган идек. Анда берничә йөз бала катнашты. Бу үзе генә дә—балаларның шигърияткә ничек тартылуларын күрсәтеп торучы дәлил. Сүз дә юк, телевидение, газета-журналлар кебек үк, балалар шигъриятен пропагандалауда зур эш башкара ала. Ләкин өй түрендәге шигырь сөйләүче кыйммәтле телевизор безнең кадерле әбиләребезнең җыр-такмакларын алыштыра алырмы икән? Ай-һай!..

Бу техника заманында, табигатьне тимер кысрыклаган бер чорда, кешенең хисләре белән теләсә нинди машина идарә итә алырга мөмкин бер заманда кешегә, бигрәк тә балага, әгәр дә ул чын кеше булып үссен дисәк, кешелекле, хискә бай, ихлас шигырьләр кирәк. Ул аңа һава кебек үк, икмәк һәм су кебек үк кирәк. Югыйсә без алардагы иң матур кешелек сыйфатларын кире кайтарып ала алмаслык дәрәҗәдә югалтуыбыз бар. Әгәр дә кеше, үзе дә сизмәстән, табигатьтән ерагайган кебек үк шигырьдән дә ераклашса, кешенең хисләре тупасланыр, күңеле ташка әверелә барыр. Ә таш күңелне инде ул чагында бернинди шигырь дә эретә алмас.

Сүземне атаклы совет педагогы В.Сухомлинский сүзләре белән тәмамлыйсым килә. «Пушкин һәм Гейнены, Шевченко һәм Леся Украинканы яраткан кеше... тупас, әхлаксыз кеше була алмый».

*1983*

Күңелгә якын шигырьләр

Әдәбиятка соңлап килгән шагыйрьләргә ничектер сәерсенеп, сагаебрак карау гадәткә кергән. Ләкин шулай булуга карамастан безнең әдәбият тарихында да гадәттән тыш хәлләр булгалый. Шуларның берсе— балалар әдәбиятына Зәкия Туфайлова (1907—1977) килү булгандыр, мөгаен. Чыннан да, сәер хәл бит. Заһирә Байчурина (1890—1977), Гыйффәт Туташ (1895—1977), Зәйнәп Бәширова (1903—1984) кебек шагыйрәләребез, безнең көннәргә кадәр озын гомер кичерүләренә карамастан, яшь чакларында гына бер кабынып алдылар да олыгайган көннәрендә әдәбияттан бөтенләй читләштеләр. Аларның иҗатлары ерак тарих булып кына калды. Ә менә алар белән бер чорда яшәгән Зәкия Туфайлованың әдәби язмышы бөтенләй киресенчә булып чыкты. СССР Язучылар союзы членлыгына кабул ителгәндә, ул инде алтмыш бишенче яше белән бара иде. Әдәбиятта сирәк очрый торган уникаль күренеш бу, әлбәттә.

Ә ул әдәбиятны, китапларны һәм балаларны гомере буена яратты. Без моны аның шигырьләреннән генә түгел, тормыш юлыннан да ачык күрәбез.

Башкортстанның Кушнаренко районындагы Илморза авылында туган Зәкия Туфайлова кечкенәдән әдәбият белән танышып үсә, үзе дә шигырьләр яза. Әдәбиятка булган мәхәббәте аны утызынчы елларда Свердловск шәһәрендәге педагогия техникумына укырга илтә. Шагыйрәнең шуннан соңгы тормышы балалар, яшүсмерләр арасында—Уралдагы, Ленинград, Казан шәһәрләрендәге мәктәпләрдә, һөнәр училищеларында һәм В.И.Ленин исемендәге республика китапханәсендә уза. Бәлки, тормышындагы шушы хәлләр Зәкия апаны балалар әдәбиятына алып килгәндер дә. Ә күңелендәге кечкенәдән кабынган, еллар узса да сүрелмәгән шигырь уты яңадан дөрләп киткәндер.

Мин белгәндә Зәкия апа җитмешен тутырып килә иде инде. Өлкән яшьтә булуына карамастан, соңгы елларында ул аеруча активлашып китте, иҗат дәрте белән янып яшәде. Балалар әдәбияты секциясенең утырышларында еш катнашты. Безнең «Яшь ленинчы» редакциясенә дә килеп йөрде. Хәтеремдә, газетаның 50 еллык бәйрәмендә бик теләп, шатланып катнашкан иде. Бигрәк тә әдәбият бүлегенә кереп утырырга ярата иде Зәкия апа. Ул вакытта бүлек мөдире булып эшләгән Хәкимҗан Халиков белән уртак тел таптылар алар. Икесе дә балалар өчен генә яза, икесе дә элекке укытучылар, икесенең дә балалар әдәбияты өчен янып-борчылып йөрүләре. Сәгатьләр буенча мәктәп, балалар әдәбияты, балалар тормышы турында бирелеп сөйләшүләре истә калган. Иң хәтергә уелып калганы— Зәкия апаның итагатьлелеге, кече күңелле булуы, үзеннән яшьләр белән дә үз тиңе итеп сөйләшүе, һәрбер шагыйрьне, хәтта минем кебек яшьләрне дә, олы итеп кабул итүе. Шул гаҗәпкә калдыра иде мине. Ул чакта инде югыйсә Зәкия Туфайлова— балалар арасында киң билгеле шагыйрә. Аның иҗаты белән укучылар яхшы таныш. Унлап китабы чыккан. Хәтта кайбер шигырьләре «Туган тел» китапларына, дәреслекләргә кертелгән, «Нәниләр китабы»нда урын алган. «Яшь ленинчы»да да еш басыла иде. Шундый бер вакыйга истә калган. Бервакыт редакциягә бер малай шигырь язып җибәргән. Ахырда «үзем уйлап чыгардым» дип тә өстәгән. Укып карыйбыз. Менә дигән шигырь, ләкин үзенеке түгел. З.Туфайлованың «Кар кызлары» исемле шигыре. Әлеге малайны, әлбәттә, караклыкта гаепләргә булыр иде. Ләкин ничек ачуланасың инде аны. Кем белә, ул шигырь, бәлки, малайның күңеленә шулкадәр кереп калгандыр, шигырь язарга утыргач, ирексездән, шушы шигырь килеп чыккандыр. Шагыйрьнең шигырьләрен укучы үзенеке итеп кабул итә икән, шагыйрь өчен куаныч кына! Бер килгәнендә Зәкия апага шушы хакта әйткәч, ул чын күңеленнән аптырашта калып, сөенеп, ләкин теге малай өчен борчылып: «Берүк, ачуланып яза күрмәгез инде ул баланы!»—дигән иде.

Миңа калса, әлеге үтенечендә шагыйрәнең бөтен иҗат концепциясе, кешелеклелеге, педагоглыгы, балаларга булган олы мәхәбәте чагыла. Чөнки аның шигырьләре дә шул гуманистик принципка нигезләнеп иҗат ителгәннәр.

З.Туфайлованың чын мәгънәсендә талантлы шигырьләр иҗат итүе, балалар дөньясын тирәнтен аңлавы, аның талантлы шагыйрә булып формалашуына төрле сәбәпләр бардыр. Әмма иң төп этәргечләрнең берсе, һичшиксез, аның әдәбиятка аяк басуының бездәге балалар поэзиясенең яңарыш чорына туры килүендә. Ул беренче шигырьләрен күренекле балалар шагыйре Бари Рәхмәт иҗаты чәчәк аткан бер вакытта яза башлады. Озак та үтмәстән, балалар поэзиясенә Шәүкәт Галиев килеп керде. Балалар әдәбиятында гомумҗанлану чоры иде ул. Балалар яңадан чыга башлаган «Яшь ленинчы»ның беренче саннарын кулларына алдылар. Яңа ачылган Казан телевидениесе балалар өчен дә тапшырулар әзерләргә тотынды. Балалар әдәбиятына азмы-күпме игътибар артты. Яңа әдипләр килде. Тукай, Җәлил кебек бөек шагыйрьләребезнең балалар өчен язылган шигырьләре дә бөтенләй яңача кабул ителә башлады. З.Туфайлованың менә шушы уңдырышлы туфракта иҗат ителгән шигырьләре дә балаларыбызга яңа дөнья, яңа темалар, яңа шигъри образлар алып килде. Аның иҗат мирасы күләме ягыннан зур түгел. Кайсы гына китабын алып карасаң да, нигездә, унөч битле дә унбиш битле. Шигырьләрен бергә җыеп карасаң, барысы йөзгә дә тулмас. Ләкин ул шигырьләр арасында бер генә уртакул, буш шигырь дә тапмассың. Һәркайсы

җентекләп эшләнгән, балаларга тәгаен кирәклеген төгәл аңлап, белеп язылган шигырьләр. Алайга китсә, хикмәт сандамыни? Кайчагында кирпеч калынлыгы китаптан да ун шигырь сайлап ала алмый интегәсең. Ә Зәкия апаның шигырьләрен сайлап торасы юк. Аларны рәттән укыйсың. Аларның кайсын гына укысаң да: «Менә бу—«балалар шигыре» ичмасам!»—диясе килә. Арада аеруча матурлары, җылылары, саллылары бар. Аның «Туган ил», «Мин яңа сүз өйрәндем», «Әти дә көлеп торсын», «Әлифба», «Кечкенә капитаннар» кебек шигырьләре балалар психологиясен тирәнтен аңлап, поэтик образлар белән бизәп язылган. Аларны балалар әле дә яратып укый, яттан да белә. Аннары ул шигырьләрдәге иң игътибарга лаек үзенчәлек—тәрбияви булулары.

Әйткәнемчә, З.Туфайлова балаларыбыз өчен әйбәт шигырьләр язып калдырды. Шулар арасында минем һәрчак исемдә йөргәне, күңелемнән бер дә  китми торган берсе бар. «Әни» сүзе» дип атала  ул.

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга!

Балалар поэзиясенең алтын фондына керергә тиеш мондый шигырьне бары тик талантлы балалар шагыйре генә яза ала. Ә Зәкия апа Туфайлова нәкъ менә шундый шагыйрәбез иде!

*1987*

## Сөендерде дә, көендерде дә‡

Нindiрәк булды соң 1986 ел балалар әдәбияты өчен? Нинди табышлар, нинди югалтулар алып килде ул безгә? Нинди проблемалар тудырды? Олы әдәбиятыбыз фонында балалар әдәбияты ничегрәк булып күренде? Бу трибунадан чыгып сөйләрлеге бармы аның? Әллә инде, бик күп язучыларыбызның фикеренчә, балалар әдәбиятын әле һаман да бала-чага әдәбияты итеп кенә карыйкмы?

Ләкин ничек кенә карасак та, бер хакыйкать бар. Балалар әдәбиятын күпме генә кечерәйтергә тырышмыйк, аны күпме генә күрмәмешкә салышмыйк, ул инде барыбер үзенең чын әдәбият икәнен күптән раслады. Балалар әдәбияты бар! Һәм булачак! Димәк, сөйләр сүз дә булачак! Бигрәк тә бүген, бүгенге революцион үзгәртеп корулар чорында балалар әдәбиятыннан, олы әдәбияттан көткән кебек үк, күпне көтәргә хаклыбыз. Көтәргә генә түгел, таләп итәргә дә вакыт җитте. Мин шушы урында балалар әдәбиятының асылын, аның бүгенге тормышыбыздагы зарурлыгын аерым әйтеп узарга телим. Олы әдәбият белән балалар әдәбияты арасында аерма бармы соң? Бар, әлбәттә! Балалар әдәбияты яшь буынны тәрбияли. Ә олы әдәбият күп очракта яңадан тәрбияләү белән, ягъни перевоспитание белән шөгыльләнә. Дөресрәге, вакытында балалар әдәбияты, тиеш булып та, эшләмәгән, булдыра алмаган тәрбияне, кулдан ычкындырылган тәрбияне олы әдәбият яңадан бер кат тәрбияләү белән мәшгуль. Ә инде менә шушы перевоспитание белән шөгыльләнмәс өчен, балаларыбыз манкортка әйләнмәсен өчен, безнең талантлы язучыларыбызның әсәрләрен халкыбыз киләчәктә дә укысын өчен, нәниләр әдәбияты балаларыбызны бишектән, теле ачылганнан алып җитди рәвештә тәрбияләргә бурычлы. Балалар әдәбиятына әнә шундый олы, изге, хәтта, әйтер идем, бөек миссия йөкләтелгән. Әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт бары тик ана сөте белән генә керә ала. Балалар әдәбияты — ана сөте кебек шифалы, изге, саф булырга тиеш! Ләкин балалар язучылары үзләре генә, күпме генә талантлы булмасыннар, әллә ни эш кыра алмаячаклар. Аларның фикердәшләре-ярдәмчеләре дә бар: балалар рәссамнары, балалар композиторлары, укытучылар, китапханәчеләр, нәширләр, редакторлар, балалар матбугаты, әдәби тәнкыйть, театр, музыка-сәнгать мәктәпләре... Балалар әдәбиятының үзенчәлеге дә шунда ки, балаларга тәрбияне бары тик комплекслы рәвештә генә тизрәк һәм үтемлерәк итеп җиткерергә мөмкин.

Балалар өчен язылган әсәрләрнең олыларныкыннан тагын бер аермасы бар. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, аларның тәрбияви көче зуррак—алар балалар күңеленә ныграк сеңеп кала. Әйтик, өлкәннәр өчен язылган шигырьләр, хәтта уртакул, уртакулдан түбән булган очракта да, ул кадәр куркыныч түгелдер дип уйлыйм. Шагыйрь яза. Китап чыга. Укучы аны сатып ала. Алмаска да мөмкин. Алган очракта да, китапның беренче шигырен укып ачы итеп бер сүгенгәннән соң, атып бәрергә мөмкин. Бүре дә тук, сарык та 25—30 тиенлек кенә зыян күрә. Ләкин балаларга атап язылган әсәрләр белән хәл бөтенләй башкача. Әгәр дә балалар шигыре яки хикәясе матбугатта бер басылып чыкса, ул инде— балаларныкы дигән сүз. Аны бала үзе дә укый. Үзе укымаса, ата-анасы укый, йә булмаса, мәҗбүр итеп укыта. Балалар бакчаларында аларны тәрбиячеләр өйрәтә. Алар дәреслекләргә, күмәк җыентыкларга килеп эләгә, дәресләрдә өйрәнелә,

концертларда, сборларда яңгырый... Кыскасы, алар бала күңеленә үзе теләсә дә, теләмәсә дә сеңдерелә. Кызганычка, алар арасында чын әдәбият белән бернинди дә уртаклыгы булмаган язмалар да еш очрый. Андый төссез, хиссез, иссез, көчсез, тешсез әсәрләр балаларыбызның зәвыгын агулау, аларның рухын җимерү өчен язылады́р, мөгаен. Андый әсәрләрне халкыбызның киләчәге өчен тамчы да кайгырмаучы, кайгыртмаучы кешеләр генә яза ала. Биредә, әлбәттә, барыбызның да—«Яшь ленинчы» белән «Ялкын»ның да, китапларыбызның да, дәреслекләребезнең дә роле әйтеп бетергесез зур. Бер бездарный авторга яхшылык эшлибез дип, меңләгән балаларыбызга яманлык эшләгәнебезне уйламыйбыз. Балаларыбызның каргышыннан, алар алдындагы гөнаһтан да курыкмыйбыз.

Былтыр, мәсәлән, ике шигырь китабы дөнья күрде. Балалар өчен. «Гөрләвекләр кайда яши?» һәм «Торналы туп» исемле. Матур итеп чыгарылганнар. Рәсемнәрен дә кызганмаганнар. Шигырьләре исә—уртакул. Ике автор да—пенсия яшендә. Гомумән, хәзер балалар өчен карт шагыйрьләр беренче китапларын чыгарырга тотындылар. Үзләренә балалар акылы керә башлагач кына балалар өчен яза башлауда, бәлки берәр закончалык бардыр? Балалар өчен язарга алынгач, әйбәт тә кешеләрдер алар үзләре. Әмма, әйткәнемчә, авторлары яңа булса да, шигырьләре яңа түгел шул. Китаплары да авторларның үзләренә генә сөенеч китергәндер, мөгаен.

Мондый китапларның, публикацияләрнең тагын бер аяныч ягы бар. «Дурной пример заразителен»,— ди татарлар. Шушы китаплардан соң балалар әдәбияты секциясенә унлап пенсионерның кулъязмасы килеп керде. Барысы да—шигъри әсәрләр. Шунысы начар: алар әлеге китаплардагы шигырьләрдән бер яклары белән дә аерылып тормыйлар диярлек. Начар да түгел, яхшы да түгел. Артык та түгел, ким дә түгел. Һәммәсе дә—уртакул. Хәзер аларны шигырьләрен китап итеп чыгарырлык түгел икәненә ничек ышандырырга? Ул гына да түгел, алар, Бөек Ватан сугышы ветераннары буларак, ниндидер льготалар да сорыйлар. Ләкин нинди льготалар турында сүз барырга мөмкин? Аларга хөрмәтебез зур һәм тирән булган хәлдә дә, әдәбиятта беркемгә дә бернинди дә льготалар булмавын ничек аңлатырга үзләренә? Алар, әлбәттә, балаларыбызны түгел, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүчеләр. Әлеге пенсионерларның берсе әйткәнчә, китапны да алар татар балалары өчен түгел, ә үз балаларына истәлек өчен генә чыгарырга йөриләр. Бу, әлбәттә, кайбер Союз членнарына да кагыла.

Без шуны да онытмаска тиешбез: көнлекче әсәрләр бик тә озак яшәүчән. Безнең әле моннан 30—40 ел элек язылган халтуралардан да һаман котыла алганыбыз юк. Алар китаптан китапка, дәреслектән дәреслеккә күчеп йөриләр. Балаларны рухи гарипләндерүне дәвам итәләр. Тагын шунысы бар: талантлы балалар язучылары әдәбиятка сирәк килсәләр дә, кәсепчеләрнең урыннары бер дә буш тормый. Берәүләре китүгә, икенчеләре килеп кенә тора. Ул гына да түгел, алар әдәби процесста «погода» да ясарга мөмкин һәм ясыйлар да.

Балалар әдәбиятын тоткарлаучы тагын бер күренеш бар. Ул—уравниловка. Бездә бөтен язучыны да бер җепкә тезеп йөртү киң таралган. Язасың икән, бигрәк тә Союз члены булгансың икән, димәк, син беркемнән дә ким түгел. Язасың икән, димәк, язганнарың басылырга, хәтта мактаырга да хаклы. Әйтик, «Ялкын»да яисә «Яшь ленинчы»да Шәүкәт Галиев тә, Мөхәммәт Шәйхи дә елга бер бәйләм шигырь чыгарырга тиеш. Әгәр дә Ш.Галиевнең шигырьләрен ике тапкыр бассаң, кемдер сүз әйтүдән куркабыз. Ул кемдерне без белмибез дә. Ул—ниндидер бер мифик көч. Бәлки, гап-гади көнчелектер ул? Балалар өчен берәр җыентык, дәреслек, уку китаплары төзелә башласа да, Ш.Галиев кебек шагыйрьләрнең берничә генә шигыре керергә тиеш. Чөнки башкаларныкы да шулай гына керә. Арттырырга ярамый. Алай гына да түгел, талантсыз, начар шигырьләрне матуррак итеп, төсле рәсемнәрне җәлләмичә чыгару да киң кулланыла. Бу—гади бер хәйлә, укучыны алдау, күз буяу, начар әсәрләрне яхшы итеп күрсәтергә тырышу.

Р.Сверигинның бер мәкаләсе истә калган. Ул соңгы елларда Мәһдиев, Гыйләҗев, Фәттах, Ахунов кебек язучыларыбызның әсәрләре гомуми әдәбият фонында күмелеп калдылар дигән фикер әйтә. Ә бит балалар әдәбиятында да шул ук хәл. Ш.Галиевне гадәти бер шагыйрь итеп күрсәтү очраклары, Р.Фәйзуллин, Т.Миңнуллин, Р.Мингалим, Ф.Яруллин кебек язучыларның балалар өчен язган әсәрләрен күрмәскә тырышулар шул хакта сөйли. Күргән очракта да аларның әсәрләренә уртакул язучылар рәтендә генә бәя бирелә. Без аларның кайберләрен шуның белән балалар өчен язудан биздереп тә бетермәдек микән инде? Уравниловка — бигрәк тә әдәбиятта—куркыныч әйбер. Мондый мөнәсәбәт белән әдәбиятны, шул исәптән балалар әдәбиятын да үстереп булмаячак.

Балалар прозасы белән танышып чыкканнан соң, күңелдә шундыйрак хис кала: ни дисәк тә, балаларыбызга укыр өчен әсәрләр бар икән әле. Газета-журнал битләре, шөкер, чиста килеш, буш килеш чыкмый. Язучыларыбыз яза тора. Китапларыбыз чыга тора. Балаларыбыз укый тора. Күрәсез, эшлибез, тик ятмыйбыз. «Ялкын» журналы, мәсәлән, үзенең 6 санында укучыларына Шамил Рәкыйповның Жан турындагы яңа әсәрен, ә калган 5 санында Мәхмүт Хәсәновның «Зимагур» дигән повестен тәкъдим итте. Икесе дә данлы тарихыбызга— Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышланган. Батырлык, кыюлык,

ватандарлык хисләре тәрбияли торган әсәрләр. Берсе Советлар Союзы Герое Иван Кабушкин батырлыгы турында сөйли, икенчесе фашистларга каршы сугышкан бәләкәй татар малае Зөлфинурның батырлыгын тасвирлый. Укучыларыбызга тарихи тәрбия, интернациональ тәрбия бирү һичшиксез кирәк! Шул яктан караганда, әлеге әсәрләрнең файдалары, әлбәттә, булмый калмас. Кирәк китаплар алар! Тагын шундый китапларның берсе—Нәби ага Дәүлинең «Язмышка юл» әсәре. Аның беренче повесте аерым китап булып басылып чыкты. Анда ятим татар малаеның ачы язмышы бар, бүгенге өлкән буынның авыр да, гыйбрәтле дә балачагы бар анда. Повестьта геройның кичерешләре, күзәтүләре, кылган эшләре революцион чорның утлы вакыйгалары белән бәйләнеп бара. Малай күзгә күренеп үсә, үзгәрә, чыныга, ил белән бергә яңа тормышка аяк баса. Революция язмышы малайның да язмышын хәл итә. Повестьны укыганда шул чор күз алдына килә, образлары, вакыйгалары истә кала. Әсәрнең икенче китабын көтеп калабыз.

Тагын бер күләмле әсәр. Ул да булса—К.Кәримовның «Яшь ленинчы» газетасында басылган «Күрше авыл кызы» повесте. Чын мәгънәсендә укучыларның үзләре өчен укучы балалар турында язылган әсәр. Аның иң отышлы ягы да бүгенге балалар тормышыннан язылган булуында. Мәктәп, класс, пионер лагере, сборлар, өлкәннәргә ярдәм... барысы да бар анда. Ләкин повесть үзе—беренче мәхәббәт турында. Беренче саф хисләр, беренче кичерешләр, дулкынланулар турында. Шаянлык белән, лирик буяулар белән сугарылган бу әсәр авторның уңышы дип саналырга хаклы. Редакциягә килгән хатларга караганда да, повестьны укучылар яратып укыганнар.

Уңышлы китапларның күбесе кече яшьтәге балалар өчен язылган. Шатландырганнары Н.Кәримова һәм Р.Сәлимҗановның проза китаплары булды.

Яшь язучы Нәзифә Кәримованың беренче китабы күңелдә аеруча матур тәэсир калдыра. Аның балаларча теле бар. Балаларча фикерләве бар. Кыскасы, сәләте бар. Аңа балалар өчен һичшиксез язарга кирәк! Хикәяләреннән тапкырлык, җорлык, сүз тәмен тоюы сизелеп тора. Мәһдиевчәрәк сүз уйнатулар да очрап куя. Менә «Кое чыпчыгы» исемле кыска гына хикәя. Малайлар белән уйнап йөргән Мансур коега төшеп китә. Малайлар ах-ух килә! Ни дисәң дә, фаҗига бит! Ә Мансур үзе кое төбендә сөйләнеп утыра: «Малайлар, монда әйбер күп. Нурсамат абыйның югалган мотоциклы да монда икән». Ә озын бау тоткан Мансурның әтисе, кое баганасына тотынып басып торган Мансурның әнисеннән инде ничәнче мәртәбә: «Нигә безнең балалар гына коега төшә, нигә башкалар җирдән йөри?»— дип сорый. Курыкмагыз, малайга берни дә булмый. Тартып чыгаралар.

Р.Сәлимҗановның хикәяләре укучыларга хәтсездән таныш. Газета-журнал битләрендә ул хикәяләр күренә тора. Узган ел автор аларны бер китап итеп, «Күкеле сәгать» исеме астында бастырып та чыгарды. Әйбәт китап. Арада аеруча ошаганнары «Партизан Фәрит» белән «Әпәй бабай кабере» дигәннәре булды. Соңгысында тракторчы Әхмәтхан исерек баштан Әпәй бабай каберенең чардуганын җимерә. Дөрес, чардуганны айныгачтын төзәтеп куя куюын Әхмәтхан. Ләкин ул барыбер элекке булмый инде. Малай күңелендә барыбер җәрәхәт кала. Тирән мәгънә ята бу хикәянең асылында. Бу—халыкның үткәненә кул күтәрүгә ишарә. Бүгенге көндә бигрәк тә актуаль яңгырый торган проблема.

Ни җитми соң бүгенге балалар прозасына? Бик күп җитми. Иң элек урта һәм өлкән класс укучылары өчен, ягъни үсмерләр өчен әсәрләр җитми. Фантастик әсәрләр җитми. Детектив, маҗаралы повестьлар юк. Бүгенге мәктәп тормышыннан язылган хикәя-повестьлар кирәк. Публицистик накаллы, үсмерләргә үрнәк булырлык геройлары булган әсәрләр. Әхлак тәрбиясе проблемаларын күтәргән әсәрләр. А. Гыйләҗевның моннан 10—15 еллар элек язып «Яшь ленинчы»да бастырган «Күзгә-күз» повесте кебек әсәрләр. Кызганыч ки, узган елдагы балалар прозасында боларның берсе дә булмады. Прозабыз мәктәп каршында, үсмерләр алдында әле булса бурычлы булып кала килә. Ә проблемалар хәттин ашкан. Менә шуларның кайберләре генә. Әле һаман тормышка аша алмаучы мәктәп реформасы, гадәти мәктәпләрдә «өчле»гә укыган өчен генә килеп эләккән укучылар белән тулы ПТУлар, пионер оешмаларына кадәр үтеп кергән формализм, бюрократизм, күзбуяучылык. Балалар арасында киң таралган җинаятьчелек күренешләре. Әле кайчан гына үзебезнең хикәя-шигырьләребездә без, җиң сызганып, малайларның тәмәке тартулары белән көрәшә идек. Иң зур кимчелекләре, юньсезлекләре иде ул малайларның. Хәзер инде тәмәкене аны кызлар да тарта. Мәктәп ишегалдында да, мәктәп туалетында да. Ләкин, ни хикмәттер, бер дә гаҗәпләнмибез. Чөнки тәмәке тарту эчкечелек, токсикомания, наркомания кебек куркыныч күренешләр янында чүп кенә булып калды. Ул гына да түгел, урлашу, сугышу, кеше талау, кыйнау, көчләү балалар арасында кимеми, арта гына бара. Узган ел гына, мәсәлән, Казандагы 750 яшүсмер, хөкемгә тартылып, колонияләргә озатылган. Уйлап кына карагыз — аларның күпчелеге менә-менә Совет Армиясе сафларына китәсе, Ватаныбызны сакларга тиешле егетләр бит! Бу мәктәпнең, ПТУның, милиция органнарының гына эшләп җиткермәве түгел, ә безнең балалар әдәбиятының да көчсезлеге, булдыксызлыгы! Бу сан—кисәтү! Чаң кагарга вакыт җитте! Без балаларыбызның иң элек җанын тәрбияләргә, аларның рухын ныгытырга тиешбез. Җәмәгатьчелек балаларга, шул исәптән балалар әдәбиятына да йөз белән борылырга тиеш. Әдәбиятны яраткан, сәнгать

җанлы булып үскән бала бервакытта да җинаять юлына басмаячак! Моны һәркем аңласын иде. Язучылар үзләре генә түгел, балаларга мөнәсәбәте булган, балалар әдәбиятына кагылышы булган һәр кеше, һәр оешма, һәр җитәкче иптәш!

Кирәкле әсәрләрнең язылмавының сәбәпләрен дә аңлыйм мин. Җәмгыятебездә барлыкка килгән кире, тискәре күренешләр балалар тормышына да тәэсир итми калмады. Сүз эштән аерылды. Шул ук мәктәптә, пионер оешмасында, мәктәп комсомолы эшендә бернинди энтузиазм, романтика күренми. Монда, әлбәттә, балаларны гына гаепләп булмый. Иң элек гаепне үзебездән эзләргә кирәк. Язучыларга гына түгел, балалар журналистларына да эшләү, язу авырлашты. Шул дәрәҗәгә барып җиттек: Казан мәктәпләренә барып мәкалә язу өчен район мәгариф бүлекләреннән рөхсәт кирәк. Шунсыз сине кабул итмиләр. Без бу хакта Мәгариф министрлыгындагы иптәшләргә дә әйтеп карадык. Аптыраганнардыр, уңайсызланганнардыр дип уйласагыз, бик нык ялгышырсыз. «Андый очракта сез турыдан-туры безгә әйтегез, кайсы мәктәпкә барырга икәнен без үзебез әйтербез»,—дигәнрәк киңәш бирделәр безгә. Ә мәктәп тормышыннан повесть язарга йөрүче К.Кәримов берничә ай инде менә үзе кызыксынган мәктәпнең педсовет утырышына эләгә алмый йөри. Керергә рөхсәт итмиләр.

Менә шуңа күрә дә күп язучылар үзләренең геройларын, алдап-йолдап, мәктәп тормышыннан читкәрәк алып чыгалар, табигать кочагына, урман-кырларга, су буйларына алып баралар, укытучылар, тәрбиячеләр, вожатыйлар күзеннән читкәрәк алып китәләр. Чөнки алар анда үзләрен иркенрәк сизәләр, хәтта бәхетлерәк тә хис итәләр. Анда, мәктәптән читтә, уйнавы да, уйлануы да, хыяллануы да рәхәтрәк. Ә инде балаларны мәктәптән алып чыгарга көчләре җиткәннәр җәнлекләрне, киек-җанварларны балаларча сөйләштерә башлыйлар. Бу да, әлбәттә, ситуациядән чыгуның бер юлы. Җанварлар теле аша да фикерне, хәтта шактый усал фикерләрне дә әйттереп була. Ләкин балалар әдәбиятында төп герой барыбер бала булырга тиеш! Хәтта әкиятләрдә дә.

Әкият дигәннән, узган ел Батулланың чираттагы әкиятләр китабы басылып чыкты. Матур итеп бизәп чыгарылган китап. Күп әкиятләре электән дә таныш. «Казан утлары» журналында чыккан бер рецензиядә мондый юллар бар: «Алып батыр маҗаралары» исемле повесть-әкият Батулла иҗатында аерым, мөһим урынны алып тора. Аның зур уңышларының берсе дип уйлыйм. Ни өчен дип әйтсәгез, бу әсәрне укыганда, үзеңне туган телебезнең, халкыбыз тарихының бәйрәмендә йөргән кебек хис итәсең». Мин бу сүзләргә: «Үзеңне дә батыр итеп хис итә башлыйсың»,—дип тә өстәп куяр идем.

Узган ел әдәбиятыбызга тагын бер әкиятче өстәлде. Ул—Ф. Яруллин. Аның 4—5 әкияте балалар матбугатында басылып чыкты. Миңа калса, ул әкиятләр безнең татар әкиятенә яңалык алып килде. Без инде күптәннән заманча әкиятләребез юк дип зарланабыз. Батулла—тәҗрибәле һәм балаларның яраткан әкиятчесе булса да, ул бераз гына старомодныйрак әкиятче. Классик халык әкиятләре үрнәгендә язучы. Аның әкиятләрендә әлеге дә баягы аждаһалар, падишаһлар, вәзирләр мыжгып тора. Ә менә Фәнис алардан качарга тырыша. Аның әкиятләре чынбарлыкка, балаларның үзләренә якынрак. Заманча әкиятләр. Аннары Ф.Яруллинның теле сокландыра. Ул әкиятләрендәге һәр сүзен үлчәп, ювелирларча шомартып, шигырь кебек итеп яза. Бу, минемчә,—язучылык эшенә чын мастерларча мөнәсәбәт, намуслы мөнәсәбәт.

Ә.Гаффар әкиятләрен дә уңай яктан телгә алып узасы килә. Авторның үзе кебек бераз сәеррәк ул әкиятләр кыскалыклары, гадәти булмаулары белән башкаларныкыннан аерылып тора. Әхәтнең эзләнүләрен хупларга гына кирәк.

«Яшь ленинчы» белән «Ялкын»да соңгы вакытта әдәби фельетон жанры җанлану чоры кичерә. Турыдан-туры мәктәп тормышын чагылдыручы бердәнбер жанр ул бүгенге көндә. Әлеге жанрда нигездә өч автор—В.Нуриев, Л.Леронов һәм Р.Зәйдуллин эшли. Өчесендә өч төрле алым. Һәркайсының үз темасы, үз сүзе. Аеруча В.Нуриевның фельетоннары үзләренең үткенлекләре, тапкыр концовкалары, мавыктыргыч сюжетлары белән үзләренә җәлеп итеп торалар. Әгәр дә арагызда безнең газета белән журналны алдыручылар булса, ул фельетоннарны үзегез дә укып барасыздыр.

Узган ел балалар әдәбиятында иң олы вакыйгаларның берсе—6 яшьлекләр өчен чыгарылган «Әлифба» булгандыр, мөгаен. Ул—бөтенләй яңача уйланылган, чын мәгънәсендә бүгенге заман балалары өчен эшләнгән китап. Бигрәк тә рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов иҗаты югары бәягә лаек. Тексты да—элекке «Әлифба»лар белән чагыштырганда яңача язылган. Шуңа да карамастан минем кайбер киңәшләрем дә, тәкъдимнәрем дә, тәнкыйть фикерләрем дә бар. Ә менә рәссам балаларыбызга чын бүләк ясаган. Тышлыгын исәпләмәгәндә, әлбәттә. Китап хәтта бер тексты булмаса да аңлашылып тора. Анда шаянлык, җылылык, хәрәкәт, ачык төсләр балалар дөньясын ачып бирүгә хезмәт итә. Биредәге балалар элеккеге «Әлифба» лардагы ясалма, җансыз курчаклар түгел инде. Гомумән, әлеге «Әлифба» озын гомерле булыр дип уйлыйм. Балалар китабы нинди булырга тиешлекнең ачык үрнәге ул.

Гомумән, соңгы вакытта Татарстан Мәгариф министрлыгы һәм нәшриятның укыту-педагогика редакциясе дәреслекләрне яңарту буенча күп эш башкара, эзләнә, табарга тырыша. Миңа берничә яңа

дәреслекнең кулъязмасы белән танышып чыгарга туры килде. Алар барысы да—башлангыч класслар өчен. Ләкин, дөресен әйтим, алар әлеге камиллектән, заманчалыктан ерак торалар. Турыдан-туры балалар әдәбиятына кагылган өлеше турында берничә сүз әйтәсем килә. Дәреслекләрнең иң зур кимчелеге—сайлап алынган әсәрләрнең һәм өзекләрнең байтак өлеше бөтенләй диярлек балалар әдәбияты үрнәкләре булмавында. Моның, әлбәттә, үз сәбәпләре дә бар. Бездә озак еллар буена ни зурлар өчен булмаган, ни балаларныкы булып җитмәгән — ике арада буталып калган әсәрләр язылa килде. Һәм алар еллар буена әдәби китапларны да, дәреслекләрне дә «бизәп» килделәр. Бу бигрәк тә поэзиядә ачык чагылды. Чыннан да, балалар әдәбияты шундый булырга тиеш икән дигән гомум бер фикер туа башлады. Бу хәл балалар әдәбияты нечкәлекләрен, үзенчәлекләрен белмәүдән, балалар әдәбиятын тематик яктан гына кирәксенүдән, балалар өчен язган әсәрләргә дәреслек авторларының иллюстратив әдәбият итеп кенә карауларыннан килеп тугандыр, мөгаен. Чөнки әлеге хәлнең тууында дәреслекләрнең дә йогынтысы булмый калмагандыр. Дәреслек авторлары чыннан да әдәби әсәрләрне нигездә иллюстрация итеп кенә кулланалар. Әйтик, аларга җәй турында шигырь кирәк. Әйбәтме ул, аның эстетик художество кыйммәте бармы, бүгенге поэзиядә ул нинди урын тота, авторы кем? Профессиональ язучымы? Бу сорауларның берсе дә аларны кызыксындырмый. Нәтиҗәдә төссез, образсыз, чын поэзиядән ерак торган әсәрләр әле булса язылa тора, әдәбияттан ерак булган авторлар дәреслекләргә әле булса керә тора. Ул шигырьләр, проза әсәрләре балага, коры информациядән башка, бернинди эстетик тәрбия, әдәби зәвык бирә алмый. Ә инде эстетик тәрбия дә бирмәгәч, ул такмакларның нинди әһәмияте бар соң? Әмма, кызганыч ки, талантлы әдипләргә караганда әнә шул талантсызларга ни өчендер күбрәк урын бирелә. Ул гына да түгел, шушы еллар буена килгән талымсызлык балалар әдәбиятының псевдоклассикларын, ягъни мөтәклассикларын барлыкка китерде. Аларның үрнәкләрен әлеге дәреслекләрдә дә очратырга мөмкин.

Дәреслекләрдә мәктәп тормышыннан әсәрләр бөтенләй диярлек юк. Шаянлыкны, юморны, күңелле хәлләрне дәреслек битләреннән эзләп тә таба торган түгел. Ә бит без дәреслекләрдә балаларны оптимизмга, шаянлыкка, күтәренке күңелле булырга өйрәтергә тиешбез. Ләкин шаянлык, үткен сүзлелек, тапкырлык бездә күп очракларда тәртипсезлек белән беррәттән йөртелә һәм тәнәфесләрдә дә рөхсәт ителми. Телевидениедә озак еллар эшләү тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, кечкенә балалар әдәбиятта иң элек шаянлыкны, тапкырлыкны яраталар. Ләкин балалар дәресләрдә көлүдән, елмаюдан, шаянлыктан мәхрүм ителгәннәр. Телевизион тапшыруларга килгән балаларны табигый итеп сөйләштереп, елмайтып булмый. Монда безнең язучыларның да һәм, әлбәттә, дәреслекләребезнең дә кире йогынтысы бардыр.

Кыскасы, әлеге дәреслекләребез коры, төссез, «скучный» итеп төзеләләр. Ни өчен шулай? Гаеп программа төзүчеләрдәме, әллә авторларның үзләрендәме? Ни өчен яңалык сизелми? Болар хакында аерым бер сөйләшергә кирәк безгә. Киң җәмәгатьчелек катнашында. Мин, үз чиратымда, әлеге кулъязмаларга рецензияләр яздым,—киңәшләремне, тәкъдимнәремне әйтергә тырыштым. Авторлар колак салырлармы—әйтә алмыйм. Ләкин авторларның берсе миннән соң шактый эшләгәнен белдем. Рецензиягә кадәр анда минем дә берничә балалар шигырем кергән иде. Төзүче иптәш, кулъязманы яхшырту максатыннан, шуларны төшереп калдырган икән. Тагын нинди үзгәртүләр кертқәндер, китап чыккачтын күрербез. Һәрхәлдә, дәреслек шуннан соң шактый «яхшыргандыр» дип уйлыйм.

Инде шигъри продукция турында да берничә сүз әйтеп китик. Шигырьләр күп, китаплар да күп. Әйбәтләре дә күп, начарлары тагын да күбрәк. Мин шул әйбәтләреннән башлармын, ахры. Балалар өчен иң күп язучы шагыйребез Шәүкәт ага Галиев узган ел иң аз шигырь бастыручы булды. Аның «Яшь ленинчы»да биш шигыре басылды. Бер караганда, күп тә түгел. Икенче караганда, биш әйбәт шигырь аз да түгел. Бигрәк тә ул шигырьләр оста кулы белән язылган булса. Мин кайбер калын шигырь китапларын да укып чыктым, ләкин биш шигырь дә тапмадым. Ә Ш.Галиев шигырьләре художество эшләнеше ягыннан да, тематикасы ягыннан да бөтен балалар дөньясын үз эченә ала. Тынычлык темасы, мәктәп тормышы, сүз уйнату, шаянлык, дөнья турында уйлану. Дөньяны танырга өйрәтә шагыйрь үзенең шигырьләрендә. Бер шигыре аның менә болай тәмамлана:

Әни төсле җылы дөнья,
Туп шикелле йомры дөнья,
Суган сыман әче дөнья,
Алма кебек төче дөнья!

Әйе, баланы дөньяның төчесенә дә, әчесенә дә өйрәтә торырга кирәк. Кечкенә чактан ук баланың дөньяга күзен ачарга кирәк. Бу—шагыйрьләрнең турыдан-туры эше.

Х.Халиков өчен 1986 ел иң истәлекле ел булып калыр, мөгаен. Чөнки ул соңгы егерме елда беренче тапкыр «Ялкын» журналында үзенең шигырьләрен бастырып чыгарды. Хәзер чоры шундый бит. Элек чыгарылмый яткан шагыйрьләрне, язучыларны чыгару модада. «Ялкын»ның Х. Халиков иҗатына йөз

белән борылуын бездә барган демократик үзгәрешләрнең ачык чагылышы дип карарга кирәктер. Шагыйрьнең «Рәхим итегез!» исемле китабы да чыкты. Балалар поэзиясенең бик күп төрле жанрлары тупланган булуы белән кыйммәтле бу җыентык. Балалар андагы шигырьләрне, табышмакларны, шарадаларны, анаграммаларны, метаграммаларны яратып укырлар. Укытучыларга да файдалы кулланма булыр.

Балалар шагыйре Рәшит Бәшәрнең яңа җыентыгы да сөендерде. Шактый гына матур яза башлап та, берара, ни сәбәптәндер, сүрелебрәк калган иде ул. Ә бу китабында аның яңадан җанланып китүе, эзләнүләре, балалар дөньясына якынаюы сизелеп тора. Шагыйрь үз дөньясы, үз фикерләре белән яши. «Ярул абый», «Һавадагы абыйлар», «Яңа йорт», «Кызык булыр иде», «Кайтаваз», «Печән өсте», «Авазлар», «Дуслык хаты», «Гарәп малае Җәмил», «Тынычлык поезды» кебек шигырьләр китапның нигезен тәшкил итәләр. Аеруча соңгы өч шигырьне уңай яктан телгә аласым килә. Тынычлык өчен көрәш мотивлары безнең балалар поэзиясендә бик аз яктыртыла. Әлеге шигырьләр әнә шул бушлыкны тутырырга ярдәм итәчәк. Алар—заманча актуаль яңгырашлы әйбәт шигырьләр. Минем шуларга тагын «Малай турында баллада»ны да кертәсем килә. Лирик сурәтләргә бай публицистик баллада ул. Ул минем күңелне тетрәндерде. Балаларга да тәэсир итми калмас.

Аннары шагыйрьнең табигать һәм андагы җан ияләре турындагы шигырьләре дә матур тәэсир калдырды. Әмма иң куандырганы—тематиканың яңа булуы. Аның бик күп шигырьләре КамАЗга, аның кешеләренә, табигатенә, КамАЗ балаларына багышланган. Бу—күңелле хәл, билгеле.

1986 елның балалар әдәбиятына булган сюрпризы, мөгаен, Н.Измайлованың шигырьләр китабы булгандыр. Гомердә булмаган хәл: әлеге китаптан бер генә шигырь дә көндәлек матбугатта басылмаган. Ни «Яшь ленинчы»да, ни «Ялкын»да. Шуңа күрәдерме, әлеге китап көтелмәгәнрәк булды. Балалар шагыйрьләре сафына яңа шагыйрә килде. Балалар психологиясен төгәл сиземләүче, үзенең оригиналь язу ысулы булган талантлы шагыйрә моннан соң да җиң сызганып эшләсен иде. Балалар әдәбиятында хатын-кызлар болай да актив иҗат итә. Ләкин актив иҗат итү—әйбәт иҗат итү түгел әле. Мөгаен, З.Туфайлова белән С.Сөләймановадан соң балалар поэзиясендә мондый саллы итеп ирләрчә язучы Н.Измайлова—бердәнбер хатын-кыз шагыйрәдер. Афәрин, Нурия! Балалар әдәбиятына рәхим ит! Анда талантларга урын җитәрлек!

Узган ел тагын ике хөрмәтле шагыйрәбезнең— Э.Мөэминова белән Р.Вәлиеваның шигырь китаплары дөнья күрде. Икесе дә матур, икесе дә калын китаплар. Аларда әйбәт кенә шигырьләр дә бар. Ни дисәң дә, тәҗрибәле, әдәбиятта озак еллар эшләүче, күп китаплар чыгарган шагыйрәләр. Ләкин, кулны күкрәккә куеп әйтәм, әлеге китапларда начар шигырьләр дә җитәрлек. Менә Р.Вәлиева китабыннан бер шигырь: «Без—бакчачылар» дип атала.

Әти дә, мин дә
Бакчачы булдык.
Шуңа без бүген
Бик иртә тордык.
Элек бакчаны
Чүптән чистарттык,
Аннары җирен
Казып йомшарттык,
Тип-тигез итеп
Түтәлләр ярдык.
Сызыклар сызып
Орлыклар салдык.
Орлыкларыбыз
Шытып чыгарлар,
Кишер-кыярлар
Гөрләп уңарлар!

Үзегез дә чамалагансыздыр, бу юлларның поэзия белән бернинди бәйләнешләре дә юк. «Бакчачы киңәшләре» дигән китапка гына кертергә була бу язманы. «Могҗиза» исемле шигырь дә нәкъ шушы стильдә язылган, тик анда кишер-кыяр түгел, йөзем үстерәләр.

Э.Мөэминова китабыннан бер мисал. Рифмаларына игътибар итегез:

«Торрыйк-торрыйк!»—дип килә ул,
Килмидер һич китәсе:
Җылы туны юк шул аның,

Тәпиләре дә шәрә...
Салкын көздә җылы якка
Китмичә ни эшләсен!

«Бик сагынсаң, бик саргайсаң, аягыңны суга тык» дип бетә торган халык җыры искә төшә. Яисә тагын бер дүрт юл:

Эчендәге чын үрдәген
Чыгарыр өчен,
Бакылдык үрдәккәемнең
Тиштем мин эчен.

Үзе «үрдәккәем» дигән була, ә үзе эчен тишә. Бик үк аңлашылып бетми шикелле.

Балалар өчен поэмалар аз языла. Узган ел, «Ялкын»да Р.Харисның «Матур өй» исемле шигырь-поэмасы белән Хәйдәрнең поэмасын исәпләмәгәндә, истә калырлык поэмалар булмады да. Шулай да Р.Вәлиеваның БАМ төзүчеләр турында «Чын әкият» дип аталган поэмасы истә калды. Алар зур авырлыклар белән тимер юл салалар. Нинди авырлыклар соң алар? Төзүчеләр каршына куркыныч аюлар чыгып утыра. Салкын бураннар эшләргә ирек бирми. Учак ягып кына котылалар салкыннан. Ләкин иң зур авырлык—черкиләр. Черкиләр белән көрәш бигрәк тә уңышлы чагылдырылган поэмада. «Барам тирән уйга талып, хәйраннар калып» дип бетә поэма. Мин дә хәйраннар калып укып чыктым аны.

Нишлисең, шигъриятнең планкасы биегәйде. Ул планка аша һәркем дә сикерә алмый. Һәркемнең үз биеклеге. Шулай да андыйлар ишәя бара. Әмма бер күренеш күңелне борчый. Охшаш шигырьләр күбәйде. Шигырьдән шигырьгә, подборкадан подборкага, китаптан китапка таныш алымнар, таныш темалар, таныш образлар ияреп йөри. Шигырь бәйләмнәренең авторларын шәйләмәсәң, шигырьләренең кемнеке икәнен дә аеру авыр. Чын поэзиягә имитацияләр, подделкалар күбәйде. Бу—куркыныч күренеш.

Тематиканы гына алыйк. Безнең күп темалар: әнигә тәлинкә юышу, врачлы уйнау, яңа күлмәк, солдат булу, чебиләр, күбәләк. Аеруча песи җанлы, эт җанлы язучылар арта. Песи турында кемнәр генә язмый.

...Шаян песи тәрәзәдән
Карап тора исе китеп...
...Минем песием бик шаян,
Уенын таба каян?..
...Мырау авыр сулады,
Иреннәрен ялады,
Бик тәмләп киерелде,
Аннан сөткә үрелде...
...Сеңлемә бик матур бер
Песи алып кайтып бирдем...
...Төнлә генә чыга песи
Тычканнарны ауларга...
...Күрше әбинең песие
Ике бала китерде.
Тик шатланмады мәче —
Мәче халкы шул көнче...
...Маэмайны да яратам,
Песине дә яратам...
...Песи булсаң иде хәзер!
Әнә ничек
Берни белми ял итә...

Болары—песи турындагы шигырьләрдән кайбер фрагментлар. Балалар шагыйрьләрен тартып торучы «тәмле» урын—табын, аш-су... Ике шигырьнең берсе—ашау-эчү турында. Аларның барысын бергә җыеп, балалар өчен популяр кулинария китабы чыгарырга да булыр иде. Менә кайбер фрагментлар:

...Табында быел шикәрне
Тартынмыйча ашый ул...
...Әфлисун һәм мандарин ул,
Икесе дә бик тәмле...
...И беренче ашлыкның

Кабартмасы, коймагы.
Шундый тәмле! Аз булгач
Тамак кына туймады...
...Тәмләп кенә чәй эчкәндә
Яратам шул вареньены...
...Аш пешерә Бибисара.
Суын сала, итен сала...
...Дөньяда иң тәмле аш, ди,
Ипи белән бәрәңге...
...Эшләр беткәч, икәүләп
Чәй эчәрбез бик тәмләп...
...Печенье, торт,
Чәкчәк, компот,
Пирог, бәлеш, эремчек...
...Шул җиләк белән
Әти, мин, энем
Өчәү сыйландык...
...Үз ипиең тәмле була, ди әни.
Мәк бәлеше дә тәмле, бик тәмле...
...Кесәлнеме? Кесәлне
Кем яратмый кесәлне? һ.б.

Әлеге өзекләр бик күп шагыйрьләрдән алынды. Күрәсез, шактый җыела икән безнең «госприемка»дан узмаслык шигырьләребез. Ә бит үзебез бастырып чыгарган шигырьләр алар. Барыбыз да шушында утырабыз. Н.Кәримованың «Үтмәс товар» дигән хикәясе бар. Малай куян баласы тотып кайта. Ләкин аннан өйдә тиз туялар. Әтисе җае чыккан саен: «Малай, теләсә кая куй куяныңны!»— дип исенә төшерә. Күрше малайларына да биреп карый. Ләкин аларның әтиләре дә: «Малай, теләсә кая куй куяныңны!»— дип, кире биреп җибәрәләр. Куян үтмәс товарга әйләнә. Безнең бик күп шигырьләребез дә — шул ук үтмәс товарлар. «Малай, теләсә кая куй шигырьләреңне!»—генә диясе дә бит. Юк, алай дияргә беребезнең дә батырлыгы җитми. Үтмәс товар—мең алтын, дип, үзебезне юатабыз. Хәзер начар шигырьләрне укыган саен шул сүзләр искә төшә: «Малай, теләсә кая куй куяныңны!»

Бездә балалар өчен язучылар аз дигән фикер күптәннән яши. Җае чыккан саен шул хакта искә төшерәбез. Чыннан да шулай микән дип, мин юри генә «Яшь ленинчы» белән «Ялкын»ны һәм балалар китапларын актарып, барлап чыктым. Беренче карашка, чыннан да аздыр кебек. Ә саный башлагач, аптыраштарак калдым. Сүзләремнең дөреслеген раслар өчен сезгә дә санап чыгарга уйлыйм. Гаепләштән булмасын өчен алфавит буенча барам: Батулла, Ә.Баянов, К.Булатова, Р.Бәшәр, Ш.Галиев, Р.Вәлиева, М.Галиев, Ф.Гыйззәтуллина, Н.Гыйматдинова, Ә.Габиди, Д.Гарифуллин, З.Гомәрова, Ә.Гаффар, Р.Гаффаров, Н.Дәүли, Җ.Дәрзаман, Р.Закиров, Л.Зөлкарнәев, Р.Зәйдуллин, Ф.Зыятдинова, Л.Ихсанова, Р.Корбанов, Г.Кашапов, К.Кәримов, Н.Каштанов, Н.Кәримова, Н.Измайлова, Ф.Латыйпов, К.Латыйпов, Л.Леронов, З.Насыйбуллин, В.Нуриев, Р.Мөхәммәдиев, Р.Мингалим, М.Матшин, Г.Мөхәммәтшин, Г.Моратов, Р.Низамиев, Т.Нәбиуллин, А.Нигъмәтуллин, Ә.Мөэминова, Җ.Рәхимов, Г.Рәхим, Ш.Рәкыйпов, Р.Рәкыйпов, Б.Рәхимова, Г.Сабитов, Г.Садә, Ф.Садриев, Р.Сәлимҗанов, К.Сибгатуллин, К.Тимбикова, Р.Харис, Х.Халиков, Р.Хафизова, М.Хәсәнов, М.Хөсәен, Хәйдәр, Р.Фәйзуллин, Р.Юнысов, Г.Шәрәфи, М.Шәйхи, Ф.Яруллин, М.Әгъләмов, М.Әмирханов, Т.Әйди, Ш.Җиһангирова һәм Р.Миңнуллин. Әгәр кем дә булса ялгыш төшеп калса, төзәтә, өсти аласыз. Күрәсез, балалар өчен барыбыз да яза, язып карый, басылып карый, китап чыгарып карый.

Съездларда, ел йомгакларында, башка җыелышларда балалар әдәбиятына багышлап күпме докладлар, чыгышлар ясалгандыр? Аларда күпме мәсьәләләр күтәрелгәндер? Ул инде М.Җәлилләр, А.Алишлар, Ф.Кәримнәр чорыннан ук килә. Ләкин анда сөйләнгән сүзләр, күтәрелгән проблемалар шушы трибунада кала бирә. Ә бит һәр чыгыш теркәлеп барыла, игътибар белән тыңланып утырыла, кайбер фикерләрне каләм очына да алып баралар. Ләкин файдасы, практик файдасы булмый диярлек. Бәлки, безгә сүздән эшкә дә күчәргә вакыттыр?

*1987*

Уртак уйга чакыру

Әле кайчан гына татар әдәбиятының урта буыны дип йөртелгән әдипләребез күз алдында өлкән буынга әйләнделәр дә куйдылар. Сизми дә калганбыз. Язмышлары, талантлары белән дә, холык-фигыльләре, кылган хезмәтләре белән дә бер-берсенә һич кенә дә охшамаган язучыларны, шагыйрьләрне берләштергән бу буын—әдәбиятыбызның горурлыгы, йөз аклыгы. Кайсына гына мөрәҗәгать итсәң дә—зур шәхес, кайсын гына алып укысаң да—зур талант. Әдәбиятыбызның олылыгын саклап калган, халкыбыз язмышын чын мәгънәсендә кайгырткан әдәбият арысланнары алар, халкыбызның газиз уллары. Кызганыч, кайчагында игътибар да җитеп бетмидер аларга, ихтирам хисләре дә һәммәсенә тигез төшмидер. Югыйсә гап-гади җылы сүзгә дә, ихтирамга да, кадер-хөрмәткә дә хаклы, бик хаклы алар. Иң өлкән язучыларыбызның фатихаларын алып калган әлеге әдипләр турындагы фикерләремне Сибгат ага Хәким сүзләре белән ныгытып куясым килә. «Без сугышта чакта үсеп җиткән буын. Безнең белән ул-бу була калса, алмашка хәзерләнеп торган буын. Мусаларга, Фатих Кәрим, Алишларга алмашка әзерләнеп торган буын. Муса да, Алиш та, Кәримнәр дә кайтып очрашырга тиеш булган буын. Халыкның настроениесен әкренләп җыйган, сугыш авырлыгын, батырлыгын, фидакарьлеген җырлауны үз өстенә алган буын. Тыл ачык калмаган, сугыш еллары аларны гариплэндереп бетерә алмаган, йөрәкләр сау калган, күңелләре киң, табигатьләре бай калган... Шул буын керде... Шәүкәтләр, Илдарлар... буыны. Иманнары нык, иманнары Тукайча...»—ди ул үзенең «Яшә, борчулы җаным!» исемле китабында. Сүзем—шушы буын вәкиле Шәүкәт Галиев турында.

Табигате белән авыл кешесе ул, эчке һәм тышкы культурасы, үз-үзен тотышы ягыннан—интеллигент, таланты, фикерләве буенча чичән. Кыяфәтенә караганда, авыллыкның чалымнары бөтенләй диярлек калмаган. Ә менә иҗатындагы, сөйләшендәге тапкырлык, җорлык, табигыйлек аның мотлак авыл малае булуын әйтеп тора. Шагыйрь үзе дә авылга бик тә мөкиббән һәм бик тә рәхмәтле. «Авылда туып-үсүем белән үземне бәхетле саныйм. Халык иҗаты әнкәйнең бишек җырыннан, әбкәм әкиятләреннән башлап, әткәйнең тапкыр, шаян сүзләренә, авылдашларның хикмәтле кыйссаларына хәтле тере, җанлы килеш, туган тел аһәңе белән күңелгә сеңгән. Авыл мохите, әхлак, зәвык, фикерләүдөньяга караш формалашуның табигый мәктәбе булган»,—ди шагыйрь үзе дә.

Җәмгыятьтә, әдәбиятта үз урынын табу этисе Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган авыл малаена җиңел булмагандыр. Тормыш юллары шактый гыйбрәтле аның. Бормалы-бормалы, сикәлтәле-сикәлтәле ул сукмаклар, ул юллар. «Минем беренче китабым сигезенче класста укыганда басылып чыкты»,—дип шаяртырга ярата шагыйрь. Чынында исә бу—бер дә шаярту түгел. Кичке урта мәктәптә укыганда чыга аның беренче китабы. Казанга килеп «Чаян» журналында эшли башлаганга кадәр ул туган авылында гади колхозчы, бригадир ярдәмчесе, хисапчы, район үзәгендә статист, шундагы газетада җаваплы секретарь булып эшли. Шуннан соң нибары җиде класс белеме булган Шәүкәт Галиевкә район газетасы редакторы вазифасын йөклиләр. Шактый еллардан соң шагыйрь Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып кайта, Татарстан китап нәшриятында эшли. Күрәсез, Ш.Галиев—башка бик күп язучыларыбыз кебек Казан университетында түгел, Тормыш университетында укыган, Тормыш университетының этисезлек, мохтаҗ балачак, кырыс яшьлек факультетларын тәмамлаган шагыйрь.

Ш.Галиев үзенең иҗатын лирик шагыйрь булып башлады. Лирика—сугыштан соңгы чорның иң популяр жанры. Халыкның җылы сүзгә, җырга сусаган чагы. Шуңа күрә дә лирик шигырьләр җыр белән үрелеп бара. Шагыйрь күңелендәге лирик хисләр җырга, моңга әйләнә. «Раушаниям-бәгырем», «Утыр әле яннарыма», «Тамчылар тамар чаклар», «Күпме күзләр күреп онытылган», «Сөенечкә дисәм» кебек җырлар күптән инде халыклашып бетте, буыннан буынга күчеп, халыкның үз җырларына әверелде.

Шагыйрь лирикасының иң югары ноктасы—«Әткәйгә хат» поэмасыдыр, мөгаен. Каләмдәшләре дә, тәнкыйтьчеләр дә шулай диләр. Әлеге поэма— шагыйрьнең балачагы, ятимлек әрнүләре, тормыш дәресләре, үзенең генә түгел, үз буынының биографиясе. Шуның белән кадерледер дә ул безгә.

Алты ел рәттән «Чаян» журналында җиң сызганып эшләү шагыйрьне лирик юлдан яздыра. «Чаян»лык чире, шаянлыкка әверелеп, Ш.Галиев иҗатына да йога. Сатира-юморны тансыклаган укучылар шагыйрьнең бетмәс-төкәнмәс җорлык, шуклык белән сугарылган шигырьләрен кул чабып, авыз ерып каршылыйлар. Алтмышынчы-җитмешенче елларда язылган шигырьләре шигърият сөючеләр күңеленә, сәхнәләр түренә менә. Профессиональ артистлар да, үзешчәннәр дә рәхәтләнәләр генә әлеге шигырьләрне укып. Ул елларда сәхнәләрне сатирик Гамил Афзал белән юморист Шәүкәт Галиев тотып тора. Алай дисәң, сатира-юмор өлкәсендә аларны уздырырлык шагыйрьнең әле булса күренгәне юк. Шул чорда язылган шигырьләрдәге проблемалар бүген дә актуаль яңгырыйлар.

Шуклыклары, шаярулары шагыйрьне нәниләр дөньясына алып килде. Шаянланып кына, уйнап кына башлаган иде дә, уйламаганча җитди, кирәкле жанр булып чыкты балалар шигърияте дигәннәре. Биредә

инде ул үзенең бөтен мөмкинлекләрен, талантының әлеге кадәр файдаланылмаган, ачылмаган якларын күрсәтә башлады. Нәниләр поэзиясен бала-чага шигыре генә дип кимсетмәде, балалар шагыйре генә мин дип кимсенмәде. Балалар әдәбиятының олылыгын, зарурлыгын, әһәмиятен вакытында сизеп алды, иң мөһиме, балалар әдәбиятына үзенең кирәклеген аңлады. Һәм алданмады. Балаларны да алдамады. Малайларыбыз-кызларыбыз үзләренең күптәннән көткән үз шагыйрьләрен таптылар, шагыйрь исә үзе кебек үк шаян, тапкыр, җор дусларына тап булды.

Ш.Галиев балалар поэзиясенә берсеннән-берсе хәрәкәтчәнрәк, берсеннән-берсе тиктормасрак, тынгысызрак, берсеннән-берсе тапкыррак малайларны, кызларны китереп тутырды. Балалар шигырендә моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән җанлылык башланды. Быргы кычкыртып, барабан кагып, тигез сафларда йөрүче тәртипле, үтә дә инсафлы, эшчән геройлар урынына хыялый Хәйдәрләр, кикриге шиңгән Ирекләр, Хәлим, Сәлим, Мәсәлимнәр, басмалар санаучы Әсмалар, Шәвәлиләр килеп керде.

Әлеге балаларның иң шаяны, әлбәттә, Шәвәли булып чыкты. Аны бездә белмәгән малай-кыз юктыр. Хәтта заманында «Шәвәли» исемле китап чыкканнан соң, Сибгат ага Хәким дә: «Балалар өчен «Шәвәли» кебек бер китап та язып булмады»,— дип уфтанган иде. Шәвәлинең пропискасы—шагыйрьнең китапларында һәм «Яшь ленинчы» газетасында. 25 яше тулуга да карамастан, ул һаман да шук, һаман да шаян малай килеш. Малайларыбызның һәм кызларыбызның һаман да сердәше, фикердәше, яшьтәше, киңәштәше. С.Михалковның дядя Степасы, С.Вангели китапларындагы Гугуце кебек үк, Белмәмеш һәм Чиполлино кебек үк популяр ул безнең Шәвәли. Мине бер генә әйбер гаҗәпләндерә. Башка халыкта булса, күптән инде Шәвәлинең курчакларын, значокларын ясап чыгарырлар иде, аның исемен балалар кафеларына, балалар бакчаларына кушарлар иде. Казанның үзендә генә дә унар-унбишәр «Солнышко», «Ласточка», «Сказка», «Березка» исемнәрен йөртүче яслеләр, бакчалар җитәрлек. Нигә шуларның берәрсенә «Шәвәли» дип исем бирмәскә?

Шәүкәт Галиев килүгә, безнең балалар шигърияте планкасы кинәт кенә югары күтәрелде. Шагыйрьнең яңа иҗаты яктысында кайберәүләрнең язганнары тоныкланып, төссезләнеп калды. Конкуренциягә түзә алмыйча, балалар өчен язуларын ташлаучылар да булгалады хәтта. Нишлисең, була торган хәл. Шагыйрь татар әдәбиятының алтын хәзинәсен үзенең күп санлы шигъри җәүһәрләре белән генә баетып калмады, балалар поэзиясендә үзенең шигъри мәктәбен дә тудырды. Шул ук вакытта ул үзенең тәэсир көче белән безгә күпмедер «зыян» да китерде. Ш.Галиевкә ияреп, йөзләгән шигырьләр языла башланды. Ш.Галиев шигърияте белән сихерләнеп, исереп, шуннан айный алмый, шуның аркасында үзләрен таба алмый калганнар да байтак булды. Без, яшьрәк буын балалар шагыйрьләре, барыбыз да Шәүкәт Галиев «шинеленнән» чыкканбыз. Безнең белән утыз яшендә арабыздан киткән талантлы Афзал Нигъмәтуллин да бар иде. Аның өлкән шагыйрь турында язып калдырган сүзләре бөтенебезнең дә мөнәсәбәтен ачык чагылдыра шикелле: «Шәүкәт абый Галиев мине, үзе белән тиң күргәндәй, балалар әдәбиятында икенче тапкыр кирәкле кеше булуыма ышандырды... Беренче мәртәбәсендә ул мине үзенең шигырьләре белән әдәбиятка тарткан иде...»

Яшьләр димәктән, Ш.Галиевнең яшь алмаш тәрбияләүдәге хезмәтләрен дә искә алып китү урынлы булыр. Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү комиссиясе председателе буларак, шагыйрь Илдар Юзеев белән бергә, ул озак еллар буе яшьләр арасында булды.

Шагыйрьнең иҗаты җәмәгатьчелек тарафыннан да, хөкүмәтебез тарафыннан да югары бәя алды. Балалар өчен язылган шигырь китаплары өчен ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Аңа республикабызда беренче булып ВЛКСМ Үзәк Комитетының Гайдар исемендәге билгесе тапшырылды. «Заяц на зарядке» исемле китабы өчен шагыйрь Халыкара премия—Г.-Х.Андерсен исемендәге Почетлы диплом белән бүләкләнде, авторның исеме Г.-Х. Андерсенның Почетлы исемлегенә кертелде. Бу бүләк шагыйрьгә үз иҗатында югары гуманизм идеяләрен, тормыш оптимизмын тирән чагылдырганы өчен, балаларда тормышка актив, иҗади караш тәрбияләгәне өчен бирелде. Без моны, беренчедән, татар совет әдәбиятына зур ышаныч һәм хөрмәт дип, икенчедән, Ш.Галиевне илебездә генә түгел, дөнья күләмендәге күренекле балалар язучылары белән янәшә кую, аның зур балалар язучысы булуын тану дип кабул иттек. Дипломда шагыйрьнең әлеге китабы балалар әдәбиятының «халыкара әһәмияте булган күренекле үрнәге» диелгән дә.

Кызыклы, бик тә үзенчәлекле шагыйрьләр бар балалар әдәбиятында. Рус шагыйрьләре Сергей Михалков, Агния Барто, Борис Заходер, Валентин Берестов, болгар Асен Босев, бельгияле Морис Карем, поляк Ян Бжехва, латыш Ояр Вациетис, молдаван Григоре Виеру, төрекмән Каюм Тәңрекулиев һ.б. Шушы күренекле шагыйрьләр рәтендә татар шагыйре Шәүкәт Галиевнең дә лаеклы урыны бар. Аның китаплары Мәскәүдәге «Детская литература» һәм «Малыш» нәшриятларында чыгып тора. Ләкин, миңа калса, шагыйрь әлеге иҗаты белән Мәскәүдә дә, СССР халыклары телендә дә күбрәк, ешрак басылырга хаклы, илебез укучыларына ул тагын да киңрәк билгеле булырга тиеш.

Ш.Галиев—чын мәгънәсендә профессиональ язучы. Күп эшли, туктаусыз иҗат итә. Аның кесәсендә һәрвакыт блокнот булыр. Җыелышта булсын, мәҗлестә, идарә яисә секция утырышларында, очрашуларда булсын, ни дә булса языла, өр-яңа фикерләр теркәлә. Авылларга чыкса да блокнотлары үзе белән. Андый блокнотлары йөзләгәндер аның, мөгаен. Әгәр шулар булмаса, шагыйрьнең «Әз-мәз мәзәк» һәм «Илһамым-мәхәббәтем» исемле китаплары туар иде микән? Әлеге ике проза китабы шагыйрь иҗатында гына түгел, әдәбиятыбызда да яңа бер жанр буларак кабул ителде. Ул жанрның исем-атамасы да юк әлегә. Автор үзе аларны «язмалар» дип кенә атый. Хәер, хикмәт исемдәмени. Китабы булгач, атамасы гына табылыр анысы.

Әлеге ике китапта—шагыйрьнең утыз еллык күзәтүләре, халыкның үзеннән алынган детальләр, күренешләр, вакыйгалар, гыйбарәләр... Халык җорлыгы, халык педагогикасы, халык эстетикасы, халык фәлсәфәсе... Аларда—шагыйрьнең уйланулары, борчылулары, сызлanулары, әрнүләре...

Гаҗәп бер чорда яшибез, заманалар үзгәрә, карашлар үзгәрә, тарихка, әдәбиятка мөнәсәбәт үзгәрә. Кайчандыр кеше күзеннән ераккарак яшереп куелган әсәрләр дөнья күрә. Ш.Галиев тә үзенең архивыннан шундый әсәрләрен эзләп тапты. Заманында редакциядән кире борылган шигырьләре «Казан утлары»нда басылып чыкты. Җәмәгатьчелек, акрынлап булса да, балалар бакчаларына, мәктәпләргә йөз белән борыла. Туган тел, халык язмышы турында борчылулар реаль төс ала башлады. Шушы шартларда балалар шагыйре Ш.Галиев иҗатының, гомумән балалар әдәбиятының бәясе күзгә күренеп арта. Балалар шигыренең кадере, аның файдалы эш коэффициенты гадәти әдәби әсәрләргә караганда югарырак икәнен хәзер укытучылар, тәрбиячеләр генә түгел, җәмәгатьчелек тә аңлый башлады булса кирәк. Бу җәһәттән, Ш.Галиевнең күпкырлы иҗаты, бигрәк тә балалар шигърияте әйтеп бетергесез әһәмияткә ия.

*1988*

Балачактан башланырга тиеш!

(*Татарстан язучыларының XI съездында сөйләнгән доклад*)

Илебездә барган революцион үзгәртеп кору балачактан, өлкәннәрнең балаларга булган мөнәсә-бәтеннән башланырга тиеш иде. Балаларга булган мөнәсәбәт үзгәртеп коруның язмышын хәл итәчәк. Чөнки бүгенге балалар инде иртәгә үк, берсекөнгә үк үзгәрешләр дилбегәсен үз кулларына алачаклар. Бүгенге укучы (акыллы һәм отличник малайлар-кызлар гына түгел, ә «2»лече, тәмәке тартучы, хулиган, токсикоман малайлар-кызлар да, пионер оешмаларындагы нәни формалистлар да, Казан урамнарындагы мотальщиклар да) иртәгә заводларга киләчәк, арендаторлар булачак, райком секретаре вазифасын башкарачак. Кыскасы, ил белән җитәкчелек итү алар кулына күчәчәк. Әмма баланың психологиясе, фикерләве, дөньяга карашы инде бүген формалаша. Бала барысын да күреп, аңлап үсә. Уңай күренешләрне дә, кимчелекләребезне дә... Шуңа күрә дә «перестройка балаларын» бүгеннән үк тәрбияли башларга кирәк. Без моны, үзгәртеп коруның бишенче елында булса да, ниһаять, ныклап аңларга тиешбез. Без бит барыбыз да белеп торабыз: балаларыбыздагы бөтен кимчелекләр өчен дә, мәктәпләрдәге, пионер оешмаларындагы җитешсезлекләр өчен дә, үсмерләр арасындагы моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән җинаятьләр өчен дә без үзебез гаепле. Фәкать үзебез! Аларны без үзебез шушы хәлгә җиткердек. Балаларга бүген мәктәптә дә, өйдә дә, урамда да әйбәт түгел. Ни өчен дисәң, балаларның бездә бернинди дә хокуклары юк. Алар әле: «Безгә яңа мәктәп кирәк! Безгә яңа больница кирәк! Безгә матур китаплар кирәк!»—дип таләп итә алмыйлар. Бездә иң яхшысы да—балаларга түгел. Иң яхшысы—безнең үзебезгә. Үзебездән, ягъни өлкәннәрдән калса гына—балаларга. Безнең үзебезгә мәһабәт биналарда эшләргә, шәп курортларда, санаторийларда ял итәргә, дәваланырга кирәк. Ә балаларыбыз ни хәлдә? Ул хакта без уйланмадык, борчылмадык. Борчылырга теләмәдек. Шулай рәхәтрәк, тынычрак иде безгә.

Гомумән, сталинизм елларында, торгынлык чорында иң кимсетелгән, игътибардан иң читтә калган социаль катлам, мөгаен, балалар булгандыр. Без коточкыч заманалар кичердек. Үзегез уйлап карагыз. Сугышта һәлак булганнарның саны миллионнарча. Сугыш ятим иткән балаларның саны ничә миллиондыр—аларны санап караучы кеше булды микән? Сталинизм корбаннары 20 миллионга җитә диләр. Алардан калган ятим балаларның саны ничә миллион булды икән? Ә балалар өчен төзелгән спецлагерьлар, спецтөрмәләр, спецдетдомнар? Гомер буйларына «халык дошманы баласы» дигән кара тамга?

Торгынлык елларының иң популяр лозунгларының берсе «Иң яхшысы—балаларга» иде. Без аны күп тапкырлар кабатладык—хәтта шуңа ышанып яшәдек. Янәсе, нинди бәхетле безнең балаларыбыз! «Бәхетле, кояшлы балачак!» «Балалар—тормыш чәчәкләре!» «Балалар—иң привилегияле класс!» Ә бүген шушы бәхетле балаларыбызның Республика пионерлар сарае юк. Республика балалар китапханәсенең дә үз

бинасы юк. Ул Казан буйлап сибелгән. Китаплары подвалларда су эчендә йөзеп йөри. Ул гына да түгел, без балаларыбыз өчен бер-беребезне уздыра-уздыра төрле подваллар эзлибез, табабыз, шул подваллар белән горурланабыз, рапортлар бирәбез.

Шулай да республикада балаларга мөнәсәбәт акрынлап булса да әйбәт якка үзгәрә бара. Мәсәлән, Республика балалар клиник больницасының 300 урынлык яңа корпусы төзелүнең озак елларга сузылу куркынычы бар иде. Совет балалар фондының Татарстан бүлеге бу хакта партиянең өлкә комитетына мөрәҗәгать итте, хәлнең аяныч булуын аңлатып бирде. Дөресен әйтим, безне аңладылар, әлеге мөһим объектны беренче секретарь үзе контрольгә алды. Яңа клиник больница балаларны вакытында кабул итәр дигән өметебез бар. Казандагы югары кунакларга исәпләнгән ике кунакханә шулай ук балаларга бүләк ителде. Аларның берсендә инвалид балалар өчен санаторий урнашты. Зинин урамындагы икенче кунакханәне безнең съезд кунаклары да яхшы беләдер. Гафу итсеннәр, бу юлы аларны анда урнаштырып булмады. Ул хәзер—балалар поликлиникасы. Бүгенге көндә иске аэропортны балаларга бирү турында кайнар бәхәсләр бара. Анысы да уңай хәл ителер дип уйлыйбыз.

Кайбер саннар китерсәм, урынлы булыр. Республикадагы ятим һәм инвалид балалар тәрбияләнә торган 86 учреждениенең 47 се—зәгыйфь акыллы балалар өчен. Аларда 8790 бала яши. 16 яшькә кадәрге 878 бала церебраль паралич белән авырый. Аларның барысы да — гомерлек гариплеккә дучар балалар. 1568 бала йөрәк авыруы белән, 4282 бала тын юллары авырулары белән, 3633 бала бавыр авырулары белән, 1350 бала бөер авыруы белән, 4528 бала тире авырулары белән авырый, ел саен 100—120 балада рак авыруы табылып тора. Бу саннарны тагы да дәвам итергә булыр иде. Болары әле учетта торганнары гына. Ә авылларда бер тапкыр да больницада булмаган, врачка күренмәгән балалар күпме?

Шушылар өстенә әхлаксызлык, рухи саңгыраулык, рухи сукырлык белән авыручы балаларны да өстәсәк? Әле тагын бер авыру бар. Анысы татар балаларына гына кагыла. Медицина термины беләнрәк әйтсәк, аны тел склерозы дияргә булыр иде. Аның диагнозын сез яхшы беләсез булыр: бала туган телен оныта. Шуның нәтиҗәсе буларак, акрынлап, туган халкының мәдәниятен, тарихын, әдәбиятын хәтереннән җуя башлый. Әти-әнисенә, Туган җиренә, Туган иленә булган мөнәсәбәте үзгәрә. Гуманизм, патриотизм, фидакарьлек һәм әхлак сыйфатлары югала. Бу авыру белән күпме татар баласы авырыйдыр, әйтә алмыйм. Әмма алар күп, бик күп.

Миңа бүген Сибгат Хәким җитми. Аның халкыбыз турында борчылуы, туган телебезне, әдәбиятыбызны, шул исәптән балалар әдәбиятын да кайгыртып яшәве җитми. Гаҗәп киң күңелле, булганны күрә белгән, үзенең җылы сүзен әйтергә тарсынмый торган шагыйребез иде ул. Соңгы елларында аның теленнән «Тукай, туган тел, халык» төшенчәләре төшмәде дә. Балаларыбызның туган телләрен онытуларын, мәктәпләрдәге телгә игътибарсызлыкны авыр кичерде. Татарча аңламаучы, аңларга да теләмәүче укучыларны күреп, Казан мәктәпләреннән рәнҗеп, күңеленнән елап кайта торган иде ул. Менә аның сүзләре: «Бервакыт шулай, Казанның Совет мәйданындагы рус классларында укый торган татар балалары белән очрашу өчен, Әнвәр Давыдовны (исән иде әле, мәктәп—аның күршесендә), М.Садрины, мине бер урта мәктәпкә чакырдылар. 7—8 класс балалары... Башта Әнвәр чыгып укыды. Тыңламыйлар, чөнки телнең эченә керә алмыйлар. Садри, хәйләкәр, Ершовның «Конек-горбунок» тәрҗемәсеннән өзек укыды, тыңлыйлар, русча сюжеты буенча аңлыйлар. Мин, демонстратив рәвештә ташлап чыгып китте дип әйтмәсеннәр өчен, бик кыска бер шигырь укып бактым... Шуннан соң берничә ай яза алмадым. Яңадан андый мәктәпләргә бармаска сүз бирдем. Бу—үз телеңнең ни рәвештә бетүен карарга бару иде. Рәхмәт, яңадан карыйсым килми...» Әмма Сибгат ага шуңа да карамастан мәктәпләрдә еш булды, һәм күп очракта шушы ук хәл кабатланды. Хәтеремдә, Тукай көннәренең берсендә Сибгат аганы, Р.Мөхәммәдиевне һәм мине Ленин районындагы бер мәктәпкә чакырдылар. Хөрмәтле шагыйребез ул мәктәптән дә «башка бармыйм» дип кайткан иде. Ни үкенеч, шушы елларга кадәр яши алмады ул. Илебездәге үзгәрешләргә иң куанган кеше, мөгаен, Сибгат ага Хәким булыр иде. Үзгәртеп коруның иң алгы сафында барыр иде ул.

Әйе, соңгы дүрт елда гына да күп әйберләр үзгәрде, күңелләрдә ышаныч уянды. Ләкин стереотиплардан котылу, ай-һай, авыр. Мәктәпләрдә дә, әйбәт-әйбәт карарлар, күрсәтмәләр булуга карамастан, туган телне укытуга мөнәсәбәт авыр үзгәрә. Мәктәп чиновникларыныкы да, ата-аналарның үзләренеке дә. Менә Мөслимнән килгән бер хаттан гыйбрәтле юллар: «Хәзер татар классларын «дебиллар» дип йөртәләр. Ул класста укучы балаларны укучыга да санамыйлар. Әлеге классның җитәкчесе булырга теләүче укытучы да юк. Шул сәбәпле, үзләренә бик авырга туры килсә дә, барлык ата-ана да баласын рус классына бирергә тырыша. Укытучылар, укытканда, балаларны куркытып кына торалар: «Әгәр тырышып укымасагыз, әнә татар классына күчерәбез»,—диләр». Бу әле—иң татар төбәге дип исәпләнгән төбәктән, чиста татар районыннан килгән хат. Заманалар үзгәрә. Элегрәк башка халыклар балаларын «Отдам татарину!» дип куркыткан булсалар, хәзер татарлар үзләре балаларын «Отдам в татарский класс!» дип куркыталар. Гыйбрәтле хәлләр, валлаһи!

Мин, бу җәһәттән, Финляндиядән килгән татар кызы Айнур Низаметдиннең сүзләрен китерер идем: «Казанга килгән саен мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ничек инде Казанда туып-үсеп, ана телеңне белмәскә мөмкин? Шәһәр яшьләренең күбесе туган телләрен оныткан, татарча китапларны, газета-журналларны укый алмый. Без Татарстаннан еракта, Финляндия илендә яшәсәк тә, телебезне, динебезне, халкыбыз йолаларын онытмыйча, аларны бернигә дә алыштырмыйча яшибез. Мин үзем фин, швед, инглиз, немец телләрендә иркен яза һәм сөйләшә беләм. Тик аңа карап үз телемне—татар телен онытмыйм. Кем булуымны, тамырымны, халкымның тарихын беләм. Киләчәктә үз балаларымны да татар телен белүче һәм хөрмәт итүче кешеләр итеп үстерергә телим».

Ә без гаеплеләрне эзлибез. Без—бөек халык дип лаф ору гына җитми шул. Үз бәясен белгән, үзаңы югары булган, ниһаять, үз-үзен хөрмәт иткән, яраткан халыклар телләрен дә, мәдәниятләрен дә иң авыр чакларда да саклап кала алдылар. Ә без телебез югалганны читтән генә күзәтеп тордык. Бу—барыбызга да, шул исәптән балалар язучыларына да кагыла.

«Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты укучы балаларның үз тормышын чагылдырган бер генә яңа повесть, поэма, пьеса да бастырып чыгармады, бер генә фәнни-художестволы, маҗаралы яки фантастик әсәр дә тумады, нәниләр өчен бер генә яңа әкият тә язылмады, укучыларны туган табигать кочагына да алып кермәдек. Кыскасы, татар совет балалар әдәбиятында торгынлык чоры пәйда булды». Гафу итәсез, бу—минем сүзләр түгел, ә «Социалистик Татарстан» газетасында мәкалә бастырган икенче бер каләмдәшебезнеке. Әгәр дә бу сүзләр хак булса, мин бу трибунага чыгарга оялыр идем. Әгәр дә мин бу сүзләр белән килешсәм, соңгы елларда балаларның үз тормышыннан искиткеч повестьлар, хикәяләр язган Фаил Шәфигуллин белән әдәбиятыбызны яңача балалар шигырьләре белән баетып киткән Афзал Нигъмәтуллинның рухлары рәнҗер иде. Әгәр дә бу сүзләр хак булса, нәкъ менә соңгы елларда актив иҗат иткән бик күп язучыларыбызны әдәбияттан бөтенләй сызып ташларга туры килер иде.

Бәхетебезгә, бүгенге балалар әдәбиятында, җиң сызганып, талантлы язучылар, шагыйрьләр эшли. Өлкән әдипләребез, яшьләребез... Шигъриятебезнең инде аксакалы, соңгы вакытта Казандагы мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан кайтып кермәгән Шәүкәт Галиев, балалар әдәбиятының ветераны, ярдәмчел, гадел Ләбибә Ихсанова, Җан җанлы Шамил Рәкыйпов, сагындырып кына, ялындырып кына язучы, әмма бер язса берәгәйле язучы Г.Сабитов, әкиятче Батулла, балалар поэзиясе солдаты Х.Халиков, «Яшь ленинчы» белән «Ялкын»да берсеннән-берсе матуррак әкиятләр бастырган Фәнис Яруллин, вакыт-вакыт үзенең шигырьләре белән сөендерүче Р.Фәйзуллин, үсмерләр прозасында үзен тапкан К.Кәримов, нәни китаплар да язучы дәү Мәхмүт Хәсәнов, табигать җене кагылган, хыялый Альберт Хәсәнов, балалар матбугаты ветераны, пионерия язучысы Роза Хафизова, шигъри әкиятләр авторы, яшь редактор Җәүдәт Дәрзаман, балалар поэзиясенә уйламаган-нитмәгән җирдән килеп чыккан Н.Измайлова, балалар әдәбиятына лирик проза алып килгән Р.Бәшәр... Алар арасында холыклары белән бер-берсенә бик тә охшаган Адлер Тимергалин белән Гарәфи Хәсәнов та бар. Чиста күңелле «чиста» ике балалар язучысы. Аларның икесе дә—Сталин терроры аша узган, Сталин төрмәләрен, сөргеннәрен татыган каләмдәшләребез. Ниләр кичергәннәрен, ниләр күргәннәрен алар бер үзләре генә беләдер. Язмыш аларны мең кат сынаган. Ләкин алар үзләренең карашларына, иманнарына берчакта да хыянәт итмәгәннәр. Үзләренең намуслары кушканча яшиләр, үзләре теләгәнне язалар. Алар әле дә безнең белән янәшә, алар әле дә сәламәтлекләре мөмкинлек биргәнчә балалар әдәбиятына намус белән хезмәт итәләр. Сталинизм репрессиясе аларны дөньяга, җәмгыятебездәге реаль тормышка ачык күзләр белән карарга өйрәткән. Мөгаен, үзләре булып калу өчендер, Г.Хәсәнов бөтен иҗатын кешеләрдән ераккарак дөньяга—табигать дөньясына багышлады. А. Тимергалин да реаль тормышка караганда фантастик дөньяны якынрак күрде. Ул— бүген безнең төп фантастыбыз. Әйбәт күңелле, ыгы-зыгылардан, тартыш-талашлардан өстен торган шушындый язучыларыбыз булганда, балалар әдәбиятының йөзе һәрчак якты булачак.

Гомумән, иң авыр торгынлык елларында да безнең әдәбият балаларыбызга намус белән хезмәт итте. Г.Мөхәммәтшинның табигатьне саклауга, яклауга багышланган, экология проблемаларын күтәргән «Саумысез, аккошлар!» повесте, Ф.Шәфигуллинның авыл баласының рухи дөньясын яктыртып күрсәткән, гаделлек белән гаделсезлек көрәшен ачып биргән «Ак яллы аргамаклар» повесте, Ш.Галиевнең ул чакта әле бөтенләй сәер тоелган «Әни, дим, эчмә инде!», эт атучылар турындагы «Куркыныч хәбәр», туган телен оныткан малай турындагы «Магнитофон онытмый» кебек шигырьләре, Ә.Гаффарның әхлак проблемаларын күтәргән «Су астындагы чишмә» повесте... Боларны күрмәмешкә салышу гаделлек булмас иде.

Соңгы вакытта гына, нигездә, өлкәннәр өчен язучы Р.Низамиев, Хәйдәр, Н.Әхмәдиев, М.Галиев, Г.Мөхәммәтшин, Н.Гыйматдинова, Р.Харис, К.Тимбикова, Н.Мадьяров, Р.Сәлим, Н.Арсланов, Ә.Баян, М.Шабаев, Р.Хисмәтуллин, Ф.Садриев балаларыбызны яңа китаплар белән сөендерделәр. М.Фәйзуллина,

Н.Гайсин, Р.Вәлиева, Э.Мөэминова, М.Әмирханов, Д.Гарифуллин, Ф.Зыятдинова кебек әдипләребезнең әсәрләрен дә балаларыбыз яратып укый.

Элекке балалар язучысы Җ.Тәрҗемановның әле күптән түгел «Социалистик Татарстан» һәм «Комсомолец Татарии» газеталарына җибәргән бер мәкаләсендә түбәндәге юллар бар. Русчасы тәэсирлерәк яңгырый аның: «Ровно тринадцать лет тому назад «Яшь ленинчы» опубликовала вреднейшую повесть Аяза Гилязова «Күзгә-күз», которая воспитывала в мальчиках жестокость, черствость, бессердечие. Результат не замедлил сказаться: некоторые наши татарские подростки прославились своей жестокостью на всю страну». Миңа калса, бу—сенсацион яңалык. Чыннан да, Казан үзенең группировкалары белән ил күләмендә яңгыраш тапты. Менә ничәнче ел инде республика җәмәгатьчелеге—партия һәм совет органнары да, комсомол белән профсоюз да, тәртип саклау органнары да әлеге күренешнең сәбәпләрен эзлиләр. Баксаң, сәбәпчесе берәү генә—А.Гыйләҗевнең шушы повесте икән. Ләкин бит ул группировкаларда татар малайлары гына түгел. Әллә инде рус малайлары әлеге повестьны татарча укыдылар микән?

Дөресен генә әйткәндә, язучылар өчен бу әллә ни яңалык түгел инде. Әлеге повесть турында Җ.Тәрҗеманов моннан унөч ел элек «рәхимсезлеккә, кансызлыкка өйрәтә торган повесть» дип кара бер реплика язып чыккан иде. Күрәсез, фикере аның тамчы да үзгәрмәгән. Югыйсә үзгәрергә тиеш иде кебек. Чөнки ул чагында Язучылар союзына күпчелек язучылар җыелган иде. Җыелышта язучылар Җ.Тәрҗемановны бертавыштан субъективлыкта гаепләделәр. Сүзем дәлиллерәк булсын өчен, шул җыелышның стенограммасыннан берничә фикер тыңлагыз:

«Ш.Маннур:

— Повесть кирәкле темага язылган. Һәм изге ният белән язылган. Автор тормышны шомартып түгел, ничек бар шулай, җитешсезлекләрне тулысынча әйтеп язган. Шунлыктан мин Җ.Тәрҗемановның репликасына аптырап калдым.

Ф.Хөсни:

— Миндә: «Тәрҗеманов иптәш әдәбиятны шомартырга чакырмыймы? Лакировкага өндәмиме?»— дигән сорау туды. Әсәрдә тревога сугарлык әйбер тапмадым мин.

Х.Сарьян:

— Реплика авторы повестьтагы кара җөмләләрне генә җыеп алган. Димәк, Җәвад гайбәт сөйли.

Ф.Миңнуллин:

— Җ.Тәрҗеманов каршы чыккан, яратмаган күренешләр миндә, укучы буларак, ямьсез тойгы түгел, андагы кире геройларга нәфрәт уятты, аларга каршы көрәшәсе килү хисе уятты. Әсәрнең иң көчле ягы шунда, минемчә».

Әлеге абруйлы язучыларга өстәп, мин шуны гына әйтә алам: моннан унөч ел элек А.Гыйләҗев әлеге повестен язып зур кыюлык эшләгән иде. Мондый катлаулы, четерекле темага язучылар әле ярый сирәк булса да табыла тора. Мин монда иң элек Л.Ихсанованың «Милиционер малае» повестен, К.Кәримовның «Ана нәфрәте», Н.Акмаловның «Үз урамым» повестьларын, Батулла белән Р.Мингалимнең Казан телевидениесеннән күрсәтелгән «Сандугач сары була» телевизион спектаклен күз алдында тотам. Әлбәттә, бу темага язу җиңел түгел. Андый әсәрләрне хәтта укуы да авыр. Шуңа күрә бөтен кешегә дә ошап та бетмәскә мөмкин. Ләкин балалар арасында барган катлаулы процессларны читтән генә күзәтеп тору безнең әдәбиятыбызны бизәмәс иде. Үсмерләр дөньясында җинаятьчелек күренешләре массовый төс алган бер вакытта язучыларыбызның газета-журнал битләрендә публицистик язмалары бөтенләй диярлек басылмавын да берни белән дә аңлатып булмый. Бу, мөгаен, бүгенге балаларны белмәвебез, аларның күңелләрен аңламавыбыз, аларның мәнфәгатьләреннән ерак торуыбыз нәтиҗәседер.

Балалар тормышын белмәү кайчагында әйбәткә дә була икән. Без менә ничә еллар инде мәкалә саен, ел йомгаклары саен, съезд саен, мәктәп тормышыннан, пионер тормышыннан әсәрләр язылмый дип зарланыштык, борчылып сөйләдек. Монда, билгеле, пионер сборлары, тантаналы линейкалар, тимер-томыр җыючы пионерлар, тимурчылар, отличниклар, пионер активистлары белән гөр килеп торган повестьлар, хикәяләр күз алдында тотыла иде. Мин дә бүген шул ук сүзләрне кабатлыйм, ләкин шатланып, хәтта горурланып кабатлыйм. Әйе шул, соңгы елларда, чыннан да, пионер оешмасы турында, сүз тыңлаучан, тырыш, акыллы, итагатьле, әйбәт малайлар-кызлар турында проза әсәрләре бөтенләй диярлек язылмады. Газета-журналларыбыз төрле конкурслар да уздырып карады үз вакытында. Нәтиҗәсе барыбер булмады. Безнең язучылар тыштан ялтырап торган мәктәп, пионер тормышына алданмадылар. Ә бит күпме ясалма сюжетлы, ялган пафослы, көн кадагына суга торган бер көнлек әсәрләр язылган булыр иде. Болай да әллә ни мактанырлык булмаган балалар прозасы тагын да чүпләнер иде. Билгеле инде, әгәр дә бу темаларга да талантлы әсәрләр язылган булса, алар басылып чыккан булса, мин дә мактау сүзләрен кызганып тормас идем. Әмма талантсыз әсәрләрнең язылмавы да кайчагында олы юаныч икән.

Ә безнең мәктәпләрдәге, пионер оешмаларындагы хәлләрне сез үзегез яхшы беләсез. Торгынлык чоры мәктәпне, укучыларны һәм укытучыларны күз буярга өйрәтте, формализмга кертеп батырды. Укытучының авторитеты төште, белем дәрәҗәсе кимеде. Гомуми урта белем фикция булып чыкты. Шуңа күрә дә мәгариф хезмәткәрләренең соңгы съездында, бик озак бәхәсләшкәннән соң, гомуми урта белем мәҗбүри түгел дигән карарга киленде.

Бүгенге бала күңеле кискен борылышлар чорын кичерә. Идеаллар җимерелә. Ничә еллар табынып яшәгән кумирлар, геройлар күз алдында юкка чыга. Әйтик, Павлик Морозов кем ул? Укучылар, пионерлар да, укытучылар үзләре дә аптыраштa хәзер. Матбугат битләрендә кайнар бәхәсләр бара. Менә «Яшь ленинчы»га килгән хатлардан юллар: «П.Морозовка карата булган чиксез нәфрәтем төгәл кырык ел йөрәгемдә йөри. 1949 елда, җиденче класста укыганда таныштым мин аның «батырлыгы» белән. Менә шуннан бирле атасын аттырган кабахәт малай булып йөрде ул минем күңелдә». Моны укытучы кеше яза. «Исән булса, Павлик бүген дә гаделлек өчен көрәшер, дөреслекнең күзенә курыкмыйча туры карар иде. Шуңа күрә мин «Павлик бүген кирәкме?» дигән сорауны урынсыз дип саныйм. Ул әле иртәгә дә кирәк булачак!» Монысы—бүгенге пионер сүзләре. Күрәсез, безнең рухи дөньябызда эчке көрәш бара. Ә бит Павлик Морозов—үз заманының корбаны. Ул—бәхетсез бала. Аның язмышы—фаҗига. Ә без шул фаҗигане ничә еллар буена байрак итеп күтәреп йөрдек. Мин монда шуны әйтмәкче булам: балалар әдәбиятының бурычлары да җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән бергә үзгәрергә тиеш. Укучылар бездән яңа сүз, заман сүзе көтә. Балалар күңелендә хәзер мең төрле сорау. Мең сорауга мең җавап та булырга тиеш. Тик шунысы: өлкәннәрнең үз күңелләрендә дә шул ук мең сорау. Җавапларны бергәләп эзләргә туры килә. Публицистикада да, прозада да, сәхнә әсәрләрендә дә, шигърияттә дә. Әлегә, миңа калса, җавапларны бүгенге балалар поэзиясеннән эзләргә кирәк.

Шигырьне кимсетү соңгы вакытта модага кереп китте. Бу балалар поэзиясендә дә шулай. Әйтик, балалар әдәбияты турында сүз чыкса: «Бездә балалар шигыре бар ла ул, менә әйбәт проза, драматургия, тәнкыйть юк»,— дияргә яратабыз. Ләкин бит акцентны төрлечә куярга мөмкин. Әйтик, менә болай: әйе, бездә балалар прозасы да, балалар тәнкыйте дә, драматургиясе дә бар. Әмма алар арасында балалар поэзиясе үзенең камиллеге, художество югарылыгы белән аерылып тора. Бу—аңлашыла да. Чөнки бүгенге поэзия артында Тукай, Ф.Кәрим, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Б.Рәхмәт кебек зур исемнәр тора. Шигърият балалар әдәбиятының һәрчак мактанычы булды. Шуңа күрә аны бер селтәнүдә генә юкка чыгару кыен булыр. Әмма, дөресен әйтим, кул күтәрергә тырышучылар бар. Мәсәлән, шул ук Тәрҗеманов бүгенге балалар поэзиясен юмор-кинаягә, шаяртуга, сүз уйнатуга корылган «такмазалар» дип кенә атый. Ә инде Г.Моратов, Р.Бәшәр, Ш.Галиев, Хәйдәр, Я.Игәнәй, Р.Корбанов кебек шагыйрьләрнең «Яшь ленинчы»да басылган шигырьләрен «бер үк алым белән, ягъни сабыйлардан ничектер кимсетеп-мыскыллап, аларга өстән карап, зәвыкны камаштыра торган ясалма-уйдырма сюжетка салып, буш сүз уйнатып язылган шигырьләр» дип атый. Мин биредә сатира-юморның балалар әдәбиятында тоткан урыны турында сөйләп торуның кирәге юк дип исәплим. Фәкать Тукайның да, Җәлилнең дә, Ә.Фәйзинең дә, Б.Рәхмәтнең дә шаян шигырьләр язуын гына искә төшереп китәм. Шунысы кызык: югарыда телгә алынган шагыйрьләр, гомумән, бер-берсенә һич кенә дә охшамаган. Әгәр дә аларның шигырьләрен бергә җыеп укысак, без анда балалар поэзиясенең бай палитрасын күрер идек.

Безнең татар балалар поэзиясе — Бөтенсоюз аренасына чыккан, башка халыклар арасында йөз кызартмаган поэзия. Ул гына да түгел, илкүләм балалар поэзиясендә безнең үз йөзебез, үз биеклегебез бар. Тукай, Җәлил, Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, Р.Мингалим кебек шагыйрьләребезнең Мәскәү нәшриятларында чыккан китаплары шул хакта сөйли. Чөнки безнең шигъриятебезнең нигезендә сәламәт материал ята. Авыл материалы. Ә авыл ул—югары әхлак дигән сүз.

Шунысы да куанычлы: соңгы вакытта шагыйрьләребез бүгенге көннең иң катлаулы мәсьәләләрен дә шигырь юлларына күчерергә курыкмыйлар, балалар өчен чын мәгънәсендә перестройка шигырьләре язалар. Ш.Галиевнең, З.Мансуровның, Г.Моратовның, Г.Садәнең соңгы публикацияләрен шундыйлар рәтенә кертер идем.

Балаларга бүген нинди шигырьләр кирәк соң? Бәлки, менә мондыйдыр? Шигырьнең исеме «Күңелле, кызык уйнавы бергә» дип атала. Игътибар итегез, сүз уен турында бара. «Бакча буйлатып, Быргы уйнатып, Бергә җырлашып, Тип-тигез басып, Башны күтәреп, Күкрәк киереп, Кулларны селкеп, Күрсәтик йөреп. Күңелле, кызык Уйнавы бергә. Килегез сез дә Бергә йөрергә». Йә, ничек, күңелле, кызык уен уйныйлармы безнең балалар? Ә бит бу—1988 елда чыккан «Нәниләргә бүләк» исемле китаптан. Авторы—Җ.Тәрҗеманов. Заманында шигырьләре белән шаулаган шагыйрь. Ләкин нинди шигырьләр соң алар? Менә тыңлап карагыз: «Нурлы кояш елмайганда, Мин йокыдан уянам. Сталин бабам рәсемен Күреп шунда куанам». Шагыйрьнең бер китабы шушы шигырь белән ачылып китә. Һәм, нигездә, шушы рухта дәвам итә.

Әле генә илебездә СССР Верховный Советына халык депутатларын сайладык. Шушы нисбәттән ничек инде менә бу шигырьне искә төшермисең: «Сайлау көне—бәйрәм көне, Матур итеп киендек. Безнең кандидат—Сталин, Барыбыз да сөендек». «Татарстан турында балалар җыры» исә менә болай тәмамлана: «Яшәсен, үссен Мул Татарстан! Сталинга дан! Сталинга дан!». Гомумән, «Сталинга сәлам!», «Даһи Сталин бабабыз», «Даһи Сталин—Кояшыбыз!» кебек сүз тезмәләре җитәрлек анда. Сез инде мондый шигырьләр күптән тарих төпкелендә ятадыр дип уйлыйсыздыр. Юк шул, әлеге шигырьләрнең берсе дә әрәм булмаган. Әлеге китапның икенче басмасында да урын алган алар, ләкин «Сталин» дигән сүзләр Ватан, Туган ил, Ленин кебек сүзләр белән алыштырылган. Торгынлык елларында чыккан өченче басмасын да юри караган идем, бәхеткә, андагы теге сүзләр ни өчендер «Брежнев» белән алыштырылмаган иде.

Шагыйрьне аңларга була, билгеле. Үзгәрү җиңел түгел. Ләкин мондый шигырьләр чоры инде узды. Үткәнгә кире кайту булмаячак. Яңа чор килде. Яңа шигърият килде. Без барыбыз да узганнардан сабак алырга, гыйбрәт алырга тиешбез. Мин бу мисалны бигрәк тә яшьләр ишетсен дип китердем.

Ә инде балалар шигыренә килсәк, ул бүген бигрәк тә кирәк. Туган телебезгә йөз белән борылганда. Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр өчен, рус мәктәпләрендә укучылар өчен. Әйбәт шигырьләр кирәк, төрле-төрле шигырьләр кирәк. Татар теленә өйрәнгәндә бүгенге балага фәкать шигырь генә ярдәм итә ала. Бу—минем генә фикер түгел, укытучыларныкы да, тәрбиячеләрнеке дә. Балалар шигыренең файдалы эш коэффициенты соңгы вакытта бермә-бер артты. Шуңа күрә күпсенмик без балалар шигырен. Тәнкыйть мәкаләсе язганда да, газета-журналларда бастырганда да, китап итеп чыгарганда да.

Балалар китабы—кичә-бүген генә килеп туган проблема түгел. Без бу хакта съезд саен, ел йомгаклары саен сөйлибез. Ачынып, борчылып сөйлибез. Ләкин хәл озак еллар үзгәрешсез кала бирде. Балалар язучыларының сүзләрен ишетмәмешкә салыштылар. Китаплар төссез чыга килде. Нәшриятның балалар редакциясе массовый төстә уртакул әсәрләр чыгару белән мавыкты. «Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларына» дигән гриф белән, зурлар өчен язылган сыек әсәрләр дөнья күрә торды.

Без күп чакта югарыдан ниндидер күрсәтмәләр көтәргә күнеккәнбез. Ә менә кайчакта аерым шәхесләр хәл итә ала торган проблемалар да була икән. Р.Мөхәммәдиевнең нәшриятка килүенә әле елдан артык кына. Ул үзенең күп санлы чыгышларында, мәкаләләрендә балалар китабын күпләп, матурлап чыгарачакларын кат-кат әйтә килә. Безнең аңа ышанмаска хакыбыз юк. Хәл, чыннан да, әйбәт якка үзгәрә. Китап кибетләрендә төсле, зәвыклы бизәлгән, зур форматлы татар китаплары күренә башлады. Һәм гомергә күрелмәгән әйбер—китапларның тиражлары 100—150 шәр мең данә. Монда Ринат Мөхәммәдиевнең үзенең дә талантлы балалар язучысы булуы сәбәпчедер, бәлки. Баксаң, балалар китапларын да башкалар төсле чыгарып була икән. Теләк кенә булсын! Әлбәттә, авырдыр! Әлбәттә, кыенлыклар күптер! Р. Мөхәммәдиев үзе дә бу хакта язып чыккан иде: «Ә менә сабыйлар өчен китап дип кайгыртучылар, ни өчендер, алай ук күп түгел. Кече яшьтән үк үз туган телендә, заманча төсле рәсемнәр белән зәвыклы бизәлгән китапларга ихтыяҗ канәгатьләндерелми торып, ата-ана һәм сабыйларны телсезлектә гаепләү коры сафсата булып кала—киң җәмәгатьчелекнең бу мәсьәләгә битарафлыгын мин берничек тә аңлый һәм аңлата алмыйм. Кем-кем, хәтта Язучылар союзыбызның махсус балалар өчен әдәбият секциясе тарафыннан да нәшрият хезмәткәрләре әлегәчә конкрет ярдәм күрә һәм яклау таба алганнары юк». Каты әйтелгән. Дөрес сүзгә җавап юк. Ни өчен дисәң, моңа кадәр балалар китабы бары тик балалар язучыларына гына, балалар әдәбияты секциясенә генә кирәк иде. Ләкин, иптәшләр, ялгыш фикер калмасын. Секция дә, балалар язучылары да нәшриятка ярдәм итәргә әзер. Ләкин ничек итеп? Ул хакта бергәләп уйлашырга кирәк. Киңәшен дә бирербез, язучылар, китаплар исемлеген дә тәкъдим итәрбез. Хәер, без болай да моңа кадәр, Союзга караганда, нәшриятка күбрәк хезмәт күрсәтеп килдек. Секциянең төп эше нәшрият тәкъдим иткән кулъязмаларны тикшерүгә кайтып кала. Шуңа күрә минем бер тәкъдимем бар. Балалар әдәбияты секциясен Язучылар союзы һәм китап нәшрияты каршында төзергә кирәк. Ул чагында без эшебезне тагын да җанлырак, эшлеклерәк итеп оештыра алган булыр идек.

Болары, миңа калса, эшләп була торган, экономикага бәйләнмәгән әйберләр. Ә менә полиграфиянең артталыгын без генә хәл итә алмабыздыр. Биредә нәшрият хезмәткәрләренә партия һәм совет органнарының да җитди ярдәме кирәк булачак. Ә полиграфкомбинатның бүгенге хәле нәшриятның таләпләренә дә, теләкләренә дә туры килми. Шулай булмаганда, М.Җәлилнең балалар өчен китабы 1986 елдан бирле, Б.Рәхмәтнең шундый ук китабы 1987 елдан бирле полиграфкомбинат цехларында адашып йөрмәс иде. Ә инде М.Җәлилнең балалар шигырьләре тупланып, матур итеп бизәлгән бер генә татарча китабы да булмавы—бик гаҗәп хәл. Югыйсә «Малыш» нәшрияты аның шигырьләрен менә дигән басмада ике тапкыр бастырып чыгарды.

Балалар китабы турында безнең художниклар белән бер тапкыр да зурлап сөйләшкәнебез юк шикелле. Татарстан художниклары татар балалары алдында үзләрен бурычлы итеп сизәләр микән, белмим, әмма

балалар китапларының төссезлегендә аларның да гаепләре зур. Шуңа күрә дә безнең ничә еллар инде балалар китапларына уздырылган престижлы конкурсларда җиңеп чыгу түгел, аларда катнашканыбыз да юк. Шулай да күңелдә бер өмет бар: нәшриятка талантлы рәссамыбыз Тавил Хаҗиәхмәтов килде. Җәл, Татарстан художникларына үзләренең съездларына безне—язучыларны чакырып тормадылар. Югыйсә әйтәсе сүзләр, теләкләр, киңәшләр бар иде. Гомумән, безгә—иҗат Союзларына—балаларга багышлап берләштерелгән пленум уздырырга вакыт җитте. Аерым гына без берни дә кыра алмабыз. Әнә шул аеры-чоеры яшәгәнгә-эшләгәнгә күрә дә безнең бүгенге көндә балаларыбыз өчен театрыбыз юк, нәниләр өчен журналыбыз юк, мультфильмнарыбыз юк һәм тагын бик күп әйберләребез юк. Хәер, «Союзмультфильм» күптән түгел «Шүрәле» дигән мультфильм төшерде төшерүен. Аны беренче татар мультфильмы дияргә дә мөмкиндер. Беренчедән, материалы татарныкы. Икенчедән, ул—сүзсез мульфильм, бер генә тапкыр «Шүрәле» дигән сүз яңгырап китә. Әллә русча, әллә татарча әйтелә—аңлашылмый да кала. Нәниләр журналы булачак, диләр... Ә инде татар ТЮЗы турында безгә җитдирәк уйланырга кирәк. Чөнки ул укырга түгел, тыңлауга корылган. Татарча сөйләшә белүче татарларга гына түгел, татарча тыңлый белүче татарларга да кирәк ул. Эзләсәң акчасын да табарга буладыр. КамАЗ әнә балалар фильмы үзәге өчен 10 млн сум акча тапты бит. Чыгарды да салды. Димәк, мөмкин. Сорый белергә генә, «елый» белергә генә кирәк.

Күптән түгел үзебезнең академия театрында Т.Миңнуллинның «Авыл эте» дигән балалар спектаклен карарга туры килде. Дөресен әйтим, балалар өчен андый әйбәт татарча спектакльне минем күптән күргәнем юк иде. Күтәрелгән заманча проблемалар, мәгънәле, үткен диалоглар. Бигрәк тә артистларның уены ошады. Аларның әлегә кадәр ачылмаган яңа мөмкинлекләрен күрдем мин ул спектакльдә. Этләр булып шундый уйныйлар минсиңайтим! Хәтта башка бер фикер дә килде: «Ай-яй тиз керәбез дә инде эт кыяфәтенә. Җае чыкканны гына көтеп торабыз». Татар ТЮЗының артистлары менә ничек уйнарга тиеш, татар ТЮЗында менә нинди спектакльләр уйналырга тиеш! Автор үзе дә нәкъ шул хакта уйлап утыргандыр, мөгаен. Аның да татар ТЮЗын күрәсе киләдер, татар ТЮЗы өчен язасы киләдер. Алай үзенең дә теләге булгач, әйдәгез, без аңа, СССР халык депутаты буларак, наказ бирик. Язучылар исеменнән дә, Кукмара, Балтач, Саба сайлаучылары исеменнән дә. Татар ТЮЗын оештырып бирсен ул безнең балаларыбызга. Эшләсә, ул гына эшли алачак бу зур эшне.

Без бүген яшь алмаш әзерләү турында да җитди сөйләшергә тиешбез. Безнең нинди резервыбыз бар? Тылыбыз ничек? Ныклымы, түгелме? Ә бит, Т.Миңнуллин әйткәнчә, түгәрәк кысыла бара, чикләр тарайганнан-тарая. Башкортстан белән Чувашиядән килгән Ләис Зөлкарнәев белән Ркаил Зәйдуллин соңгы могиканнар булмасмы? Килгәннәрен кул кушырып көтеп кенә утырсак, Татарстанның үзеннән дә килми башлаячаклар. Торгынлыкның иң чәчәк аткан чагында да Язучылар союзы яшьләр белән эшләүне үзенең иң төп эше итеп исәпли иде бит. И.Юзеев белән Ш.Галиев оештырган конференцияләр, семинарлар Союз тарихында матур бер сәхифә булып калачак. Шушы залда утыручы иптәшләрнең күбесе—шул чорда әдәбиятка килгән С.Хәким, А.Гыйләҗев, Ә.Баян, Г.Ахунов, Р.Гатауллин кебек, яшь алмаш тәрбияләү өчен энергияләрен дә, вакытларын да кызганмаган иптәшләрнең шифалы ярдәмнәрен тоеп үскән әдипләр. Тик ни гаҗәп: шушы изге эшне юкка чыгарырга тырышучылар табылды. Шунысы кызык: ул шикләнүчеләрнең күбесе—яшьләр өчен кыл да кыймылдатмаган, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәгән кешеләр. Әллә шуларның сүзенә бирелеп, Язучылар союзы яшьләр белән эшләүне рәсми рәвештә туктатты. Т.Миңнуллин үзе дә бу хакта йомшартып кына, хәтта горурланып диярлек әйтеп китте: «...в современных условиях, быть может, единственно эффективная форма работы оказалась почти заброшенной». Почти түгел, ә полностью «заброшенный» бу эш. Хәтта ул гына да түгел, ВЛКСМ өлкә комитетының «Яшь ленинчы» каршындагы А.Алиш берләшмәсе җитәкчесе штатын да Союз үзенә тартып алды. Эшләүче генә булмады. Үзгәртеп кору чорында, татар халкының язмышы хәл ителгән бер вакытта, әдәбиятыбызның киләчәге турында аеруча борчылыр бер чакта яшь алмаш тәрбияләүгә төкереп карау, «талантларны мәктәпләрдән эзлисе юк, талант үз-үзенә юл яра ул» дигән принцип белән яшәү—бүген кичереп булмаслык хәл. Безнең төп ориентирыбыз—мәктәпләр, дөресрәге, балалар бакчалары һәм мәктәпләр. Мәктәпләрдә булмаган, балалар белән сөйләшеп карамаган, андагы үзгәрешләрне читтән генә күзәтеп, матбугаттан гына укып барган язучыларны мин аңламыйм. Үзенә шәкерт әзерләмәгән язучыны да аңларга теләмим.

Әлбәттә, Союз аппараты эшләмәде дип кенә, яшьләр белән эшләү бөтенләй тукталмады. Мин монда яшь балалар язучыларыньң республика семинарын искә төшерер идем. Балалар әдәбияты секциясе уздырган әлеге семинар балалар әдәбияты тормышында истә калырлык вакыйга булды. Күп кенә яшь язучылар Союз членлыгына тәкъдим ителде, яңа исемнәр ачылды. Ике съезд арасында чын язучылар булып өлгереп җиткән яшьләр шактый бездә.

Р.Корбанов—ике китап авторы. Өченчесе— нәшриятта. Классикларыбызның традицияләрен дәвам итүче талантлы балалар шагыйре. Беренче китабы ук укучыларның игътибарын җәлеп итте. «Иң күп укыла

торган балалар китабы» дип табылды. Яшь балалар язучыларының Бөтенсоюз семинарында аның шигырьләре югары бәя алды.

Ләбиб Лерон балалар әдәбиятында яратып, җиң сызганып эшли. Язганнары—шигырь, юмореска, фельетон, әкият, пародия. Язганнары—заманча, образлы. Күп яза, күп басыла, шуңа күрә күпне дә күтәргә була.

Р.Низамова—нәниләр өчен язучы прозаик. Ике китап авторы. Өченчесе—әзер. Балалар психологиясен яхшы белә. Теле—матур, үзе—РСФСРның атказанган укытучысы. Әдәбият түгәрәге җитәкчесе. Аның соңгы китабы да китапханәләрдә иң укыла торган китапларның берсе икән.

Гайсә Гатауллин, Рәниф Шәрипов, Вакыйф Нуриев, Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснияр, Рафаэль Газизов, Заһид Мәхмүтов һәм әле яңа гына авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган Илгизәр Гыйбадуллин... Балалар әдәбиятының киләчәге— алар кулында. Шушы яшьләр арасында тагын бер талантлы шагыйребез бар иде. Чын балалар шагыйре Афзал Нигъмәтуллин. Ике китабын чыгарып өлгерде. Өченчесен күрә алмады. Аның әле үзеннән соң да искиткеч шигырьләре, хикәяләре, повестьлары калды. Кызганыч, Союзга алып өлгерә алмадык. Игътибар җитмәде. Ә ул бик тә лаек иде.

Балалар әдәбияты бездә бары тик энтузиазмга гына корылган шул. Элек тә шулай булган, хәзер дә. Балалар өчен язу татар әдәбиятында ни өчендер мәртәбәгә исәпләнми. Хәтта Тукайның балалар өчен язуына да сәерсенеп караганнар бит замандашлары. Бу—тәнкыйтьнең мөнәсәбәтендә дә, китаплар чыгарганда да, Язучылар союзы җитәкчелегенең мөнәсәбәтендә дә ачык чагыла. Союзга кабул иткәндә дә шул ук күренеш күзәтелә.

Аңлыйм, һәр язучының үз борчулары, үз мәшәкатьләре. Һәрберебезне иң элек үз жанрыбыз, үз китапларыбыз, үз гонорарыбыз, үз томнарыбыз, әдәбияттагы үз урыныбыз, абруебыз кызыксындыра. Аннары инде, әгәр вакыт калса, энергия, теләк калса, укучы, халык турында да кайгыртуыбыз мөмкин. Тик менә андыйларыбыз күп түгел шул. Шуңа да карамастан съездда да, съездан соң да үз мәнфәгатьләребездән, көндәлек мәшәкатьләрдән өстенрәк булырбыз дип ышанам. Әдәбият, аның киләчәге, аның язмышы мәктәптән, балалардан, яшь буыннан башлана. Әгәр дә балалар язучылары гына түгел, гомумән язучылар коллективы шушыны аңласа, киләчәгебезгә якты өметләр белән карарга мөмкин. Әгәр дә халкыбызның, димәк, әдәбиятыбызның да гомерен озайтыйк дисәк, шушы хакыйкатьне онытмасак иде.

*Май, 1989 ел*

## Балаларыбызның Ак Апасы

Язучы турында яза башласак, без, гадәттә, аның әсәрләренә анализ ясаудан уза алмыйбыз. «Монысы—уңай образ, тегесе—тискәре герой, сюжет-композициясе—уңышлы, теле—үзенчәлекле...» Ә менә язучының шәхесенә ничек тә кагылмаска тырышабыз. Тыйнаграк булырга кирәк, янәсе. Кагылган очракта да, «фәлән елны туган, фәлән җирдә укыган, фәлән булып эшләгән»нән ерак киткәнебез юк. Әйтерсең лә әлеге әсәрләрне ниндидер бер робот-компьютер иҗат иткән. Шуңа күрә дә укучы язучының үзе турында бөтенләй диярлек белми. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары теге яки бу язучы-шагыйрьнең биографиясенә кагылышлы материаллар таба алмыйча зар елыйлар.

Күренекле татар балалар язучысы Ләбибә апа Ихсанованың да иҗатына, аның әсәрләренә яңадан бер кат күз салырга, аларның балалар әдәбиятында тоткан олы урыны турында сөйләргә, укучыларга ул әсәрләрнең яшь буынны эстетик яктан тәрбияләүдәге әһәмиятен янәдән аңлатып бирергә мөмкин булыр иде, билгеле. Әмма Ләбибә Ихсанованың татар әдәбиятында балалар прозасын әйдәп баручы икәнен, аның кырыклап китап авторы, татар балаларының иң яратып укый торган язучысы, мәктәп дәреслекләренә кергән тере классик булуын укучылар болай да яхшы беләдер дип ышанам.

Әгәр дә миннән: «Балалар язучысы нинди булырга тиеш?»—дип сорасалар, ике дә уйлап тормыйча: «Ләбибә Ихсанова шикелле!»—дип җавап бирер идем. Миңа калса, балалар язучысы булыр өчен Ләбибә апаның бөтен ягы да килгән: кыяфәте дә, холык-фигыле дә, белеме дә, таланты да, яшәү рәвеше дә. Балалар язучысының статусы (башка язучылар үпкәләмәс дип уйлыйм) гадәти язучыларныкыннан шактый югарырак. Аның әдәбияттагы миссиясе башкаларныкыннан бик күпкә җаваплырак. Ул җаваплылык—балалар алдындагы, ягъни киләчәк алдындагы җаваплылык. Республикабызның, халкыбызның киләчәге турында сүз бара. Балалар язучысы— әдип кенә түгел, ә филолог та, биолог та, психолог та, иң мөһиме, тәрбияче дә. Ул әсәрләре белән генә түгел, үзенең тормышы, шәхесе белән дә тәрбияли. Ләбибә апа исә—нәкъ әнә шундый кеше.

Каян килә соң кешегә шундый талант? Әле күптән түгел генә Әгерҗе районы хакимият башлыгы Нурулла Баһрам улы Баһрамов белән сөйләшеп киттек тә, сүз үзеннән-үзе Ләбибә апага килеп тоташты.

Әңгәмәдәшемнең дә танышы булып чыкты ул. Беләм дигәч, аның әйбәт язучы икәнен әйттем. «Якташым ул минем»,—ди Нурулла әфәнде. Шулай дигәч, мин тагын да мактарга керештем Ләбибә апаны. Әңгәмәдәшем дә дәвам итте: «Беләм, беләм, бер авылныкы без». Шуннан мин язучының әти-әнисен дә мактый башладым. Чөнки аларның затлы кешеләр булуын, авылда, тирә-якта хөрмәтле нәсел икәнлекләрен белә идем. Хәтта Гыйлембану апаны күргәнем дә бар иде. Ләкин әңгәмәдәшемнең минем сүзләргә әллә ни исе китмәде: «Беләм, беләм, мин—Ләбибә апаның әнисендә укыган кеше»,—дип, әлеге мөхтәрәм гаилә турында зур ихтирам белән искә алды. Миңа исә, «әйе, әйе» дип җөпләп, баш кагып кына утырырга туры килде.

Язмыш миңа мәрхәмәтле булды: өлкән буын балалар язучылары белән якыннан аралашып яшәргә мөмкинлек бирде. И.Туктар, З.Туфайлова, Г.Хәсәнов, Ә.Бикчәнтәева, Н.Исәнбәт... Ш.Галиев белән Ш.Рәкыйповны әйтеп тә тормыйм. Ә Ләбибә апа Ихсанова—минем өчен гади бер язучы гына түгел. Менә ничә еллар инде без үзара аралашып, фикерләшеп, «тел вә лөгать алмашып» яшибез. Без аның белән озак еллар бер йортта күршеләр булып та гомер иттек, «Казан утлары» журналында бергә дә эшләдек. Һәм, ниһаять, Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе безне ныклап дуслаштырды, фикердәшләр итте. Аның кебек сабыр холыклы, итагатьле һәм тыныч кешене язучылар арасында гына түгел, гомумән дә сирәк очратасың. Ярдәмчеллеге, күндәмлеге турында әйтеп тә тормаган булыр идем, әмма дә ләкин Ләбибә апаның үзеннән яшьрәк язучыларга күрсәткән игелекләре, ярдәмнәре аерым бер хуплауга һәм мактауга лаек. Соңгы унбиш елда без секция утырышларында әллә никадәр яшь язучының әсәрләрен укып тикшердек, гадел бәя бирергә тырыштык. Һәркайсына киңәшләребезне бирдек, кайсыларының кулъязмаларын нәшриятка китап итеп әзерләштек, үзебезнең Язучылар союзына тәкъдим иттек. Яшь прозаикларның остазы, әлбәттә инде, иң элек Ләбибә апа булды. Кулъязмаларны ул бернинди кыенсынусыз укып чыга, җентекле анализ ясый, бәясен бирә, файдалы киңәшләрен юллый. Һәр талантлы әсәрне шатланып каршы ала, һәр яңа прозаикка үзенең хәер-фатихасын бирергә ашыга. Шул ук вакытта ул— үз сүзен һәрчак туп-туры әйтеп бирә торган бик принципиаль кеше дә. Халтураны — халтура, әйбәт-не — әйбәт дияр. Фәкать күңелендәгесен, инанганын гына әйтер. Балалар әдәбиятын чын мәгънәсендә кайгыртып яшәүче, аның киләчәген олы итеп күрергә омтылучы язучы башкача булдыра да алмас иде.

Ләбибә апаның киң күңеллелеге, шәфкатьлелеге ерактан, күптәннән—татарның Нократ дигән матур бер төбәгеннән үк, ире Шәрәф Мөдәррис белән бергә гомер иткән бәхетле елларыннан ук киләдер, мөгаен. Зур шагыйрь белән гомер итү, балалар үстерү, өстәвенә, үзең дә зур язучы булу җиңел булмагандыр аңа. Ул чаклар хәзер инде легендага әйләнгән. Ләбибә апа истәлекләр китабы яза икән. Ул чорлар чагылмый калмас әле анда. Шулай да бер генә фактны искә алмый китә алмыйм.
50—60 нчы елларда Ш.Мөдәррисләрнең фатиры—чын мәгънәсендә кунак өе булган, диләр. Анда көн саен диярлек Чабаксардан килгән чуваш шагыйрьләре, Уфа каласыннан килеп төшкән башкорт әдипләре җылы почмак тапкан. Гаилә дуслыгы язучылар-әдәбиятлар дуслыгына, халыклар дуслыгына әверелгән...

Ләбибә апа гомер буе кеше арасында, тормыш эчендә кайнады, үз заманының тынгысыз бер баласы булды. Беренче карашка җитезлеге күзгә ташланып тормаса да, ул һәрвакыт актив иҗат белән шөгыльләнде (унбишләп повесть, күп санлы хикәяләр, мәкаләләр, очерклар, истәлекләр), армый-талмый казна эшендә эшләде (радиокомитет, китап нәшрияты, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналлары), җиң сызганып җәмәгать эшләрен башкарды (депутат, идарә әгъзасы, партоешма секретаре...). Һәрвакыт балалар арасында булды, мәктәпләрдән кайтып кермәде. Ул әле дә кирәк чакта радио-телевидение аша да чыгышлар ясый, газета-журналлар өчен публицистик әсәрләр дә, мәкаләләр дә яза. Каләмдәшләренең иҗатларына сөенеп язган әдәби тәнкыйть мәкаләләре дә язучының киң күңелле, игътибарлы олы әдип булуы турында сөйли.

Ихлас күңелле, олы җанлы, кешелекле, һәрвакыт елмаеп яшәүче Ләбибә апабызга 70 яшь тулды. Татар балаларының Ак Апасы үзенең иҗат бәйрәмен, гадәттәгечә, елмаеп каршылый. Ул елмаюдан безнең күңелләргә дә аклык, пакьлек иңә. Бәхетле язмышлы кеше ул Ләбибә апа, чөнки ул—Балалар Язучысы.

*1993*

Балалар дөньясын яңгыратып...

Хәкимҗан абый Халиков—чиста балалар шагыйре. Башка жанрлар белән берчакта да вакланмады шикелле. Дөрес, яшь чагында, юләр чагында, өлкәннәр өчен дә язгалаган диләр. Композитор Хөснул ага Вәлиуллин белән бергә язган туган як турындагы бер җырын мин дә беләм. Әйбәт җыр. Калган бөтен иҗаты—балаларыбызга. Шагыйрь үзенең 60 яшьлек юбилеена шактый бай иҗат белән килде. Татар һәм рус телләрендә чыккан уннан артык китап. Шигырьләр, җырлар, шигъри уеннар, табышмаклар, әкиятләр...

Шагыйрьнең гомер юлын һәм иҗат эшчәнлеген күз алдыннан кичергәндә, кызык бер әйбер күзгә ташлана: Хәкимҗан Халиков—бөтен барлыгы белән шагыйрь-мәгърифәтче. Бу бәяне ишетүгә—кайберәүләрнең сискәнеп китүе яисә авыз кыйшайтып елмаюы да мөмкин. Әмма дә ләкин шактый искергән, шул ук вакытта телебезгә дә, тормышыбызга да яңадан әйләнеп кайтучы киң һәм тирән мәгънәгә ия әлеге сүз шагыйрьгә бик тә килешеп, туры килеп тора.

Бөтен асылы белән мөгаллим кеше ул Хәкимҗан абый. Алган белеме-һөнәре дә, яшәү рәвеше һәм иҗат принциплары да шул хакта сөйли. Арчадагы педагогия училищесы, Казан университеты, авыл мәктәбе. Шул авыл мәктәбендә укыткан чорда— яшьлек елларында ук ул педагог булып формалашкан. Мәктәп аның аңына, канына сеңгән. Әнә шул мөгаллимлекне ул кайда гына эшләмәсен—«Ялкын» журналындамы, «Яшь ленинчы» газетасындамы— барыбер саклап калды. Аннары ул Абдулла Әхмәт, Гариф Галиев, Идрис Туктар кебек өлкән буын балалар язучылары белән якыннан аралашып яшәде, алардан күпне өйрәнеп калды. Андагы сабырлык, тыйнаклык шул өлкәннәрдән киләдер, күрәсең.

Без Хәкимҗан абый белән шактый еллар бер бүлмәдә кара-каршы утырып эшләдек. Ул—«Яшь ленинчы»ның әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. Мин—корреспондент. Язучылар дөньясына килеп керүемдә, олы язучылар белән танышып, алар белән аралашып китүемдә Хәкимҗан абыйның да тәэсире булмый калмагандыр. Хәтеремдә, икәүләшеп Аккош күленә, Хәсән ага Туфан янына барган идек. Яңа шигырьләрен сорарга. Интервью алырга. Юл уңаенда Абдулла Әхмәтләргә дә кердек. Авырый иде инде. Хәлен белештек. Күренекле балалар язучысын беренче һәм соңгы күрүем шунда булды...

Безнең бүлмәдән язучылар берчакта да өзелмәде. Белмим, үзе шундый булгангамы, әдәбият бүлегенә һәрвакыт талантлы һәм әйбәт кешеләр күбрәк килә иде. Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Ләбибә Ихсанова, Шәүкәт Галиев, Нәби Дәүли, Нури Арсланов, Риза Ишморат, Идрис Туктар, Зәкия Туфайлова, Гариф Галиев. Яшьрәк буын язучыларны әйткән дә юк. Хәсән Сарьян газета битләрендә «Әдәби осталык мәктәбе» алып бара, Фаил Шәфигуллин ике-өч санның берсендә өр-яңа хикәя, йә иҗат кешеләре турында очерк-зарисовка бастыра. Гомәр ага Бәширов— «Туган ягым—яшел бишек» рубрикасы җитәкчесе. Хәкимҗан абый шалтырата, хатлар яза, үгетли, ялвара, исләренә төшерә... Ничек итсә итә, әмма барыбер үзе теләгәнен яздырта. Ул, әйткәнемчә,— бик тыйнак, итагатьле, төгәл, тәртипле, шул ук вакытта принципиаль дә. Болай карап торуга йомшак кына кебек булса да, кирәк вакытында үз сүзен кистереп әйтә торган, начар әсәрләрне ике дә уйлап тормыйча кире бора торган кеше. Ул «Яшь ленинчы»да эшләгәндә, хәтта танылган язучы, шагыйрьләрнең дә йомшак әсәрләре газета битләренә үтеп керә алмады.

Шагыйрьнең тагын бер игелекле сыйфатын әйтми китә алмыйм. Ул да булса,—аның иҗат яшьләренә булган ихлас һәм ярдәмчел мөнәсәбәте. «Ялкын» белән «Яшь ленинчы»да озак еллар эшләү дәверендә ул йөзләгән башлап язучыларның әсәрләрен дөньяга чыгарды. Алар белән хат алышты, киңәшләре белән ярдәм итте. «Идел» альманахы редакторы булганда да, «Совет мәктәбе» журналында эшли башлагач та яшь әдипләр белән эшләвен дәвам итте. Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясенең бюро секретаре булган чагында да, матур әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе вазифасын башкарганда да балалар белән элемтәсен өзмәде. Яшь язучыларның беренче кульязмалары да аның аша узды. Мәктәп укучылары белән даими очрашулар оештырды.

Хәкимҗан Халиковның шигърияте әлеге дә баягы шул мәгърифәтчелек белән сугарылган. Шигъриятә кайчандыр хупланмаган бу алым шагыйрь иҗатында үзен тулысынча аклады дияр идем. Шигырьгә төреп бирелгән үгет-нәсыйхәт, әйбәтлеккә өндәү, дөньяны танып белүгә ярдәм итү—шагыйрьнең төп кредосы. Мәктәп тормышын, пионерлар һәм октябрятлар дөньясын иң яхшы белүче, аларны иң нык аңлаучы шагыйрьләребезнең берсе дә ул. Шигырьләренең нигезендә мәктәп тормышы ятканга гына түгел, ә балаларга булган мөнәсәбәтеннән дә шуны чамаларга мөмкин. Балаларны матурлыкка, пакьлеккә, яхшы булырга өйрәтү—балалар шигъриятенең асыл сыйфатлары бит. Әгәр дә шулар булмаса, балалар шигыре коры шалтыравык кына булып калыр иде. Бәхеткә, безнең Хәкимҗан абыйның шигырьләре балаларның үз дөньясыннан алып язылган. Шуңа күрә дә алар балалар бакчаларында, мәктәпләрдә яратып укыла, төрле бәйрәмнәрдә, кичәләрдә, концертларда еш файдаланыла.

Шагыйрьнең балалар җыры өлкәсендә ирешкән уңышлары турында да әйтәсем килә. Моннан күп еллар элек аның Илдус Якубов белән иҗат иткән «Бытбылдык» исемле җырын «Ләйсән» ансамбле башкара иде. Аннан соң композитор Әхмәт Хәйретдинов белән махсус җыр китабы да яздылар. Ул җырлар балалар дөньясында үзе бер вакыйга булды, балалар ансамбльләренең иң яратып җырланган җырларына әверелде. Алар радио-телевидение тапшыруларында әле дә еш яңгырап тора.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, танылган балалар шагыйре Хәкимҗан Халиковның җырлары, шигырьләре, әкиятләре балалар дөньясын моннан соң да яңгыратып торыр дип ышанам.

*1993*

Урыны — түрдә

(*Бари Рәхмәтнең тууына 100 ел*)

Үзең күреп белмәгән әдип турында язу авыр икән. Хәтта ул бик танылган булса да, аның иҗатын яратсаң, яхшы белсәң дә. Күренекле балалар шагыйре Бари Рәхмәт турында моннан ун ел элек «Татарстан яшьләре» газетасына бер тапкыр язып та чыккан идем инде. Ләкин ул минем шагыйрь турындагы гомуми уйлануларым гына булган икән. Дөресрәге, соклану хисләре генә булып чыккан. Әле менә яңадан укып карадым да, күңелдә ниндидер канәгатьсезлек калды. Бари Рәхмәтнең иҗаты элек мин уйлаганча гына булмаган. Безнең әдәбиятта аның урыны, әлбәттә, түрдәрәк. Чөнки аның шигырьләре—балаларыбызның күңел түрендә. Ә инде балалар күңеленә юл табу, аңа үтеп керә алу бәхете бик сирәкләргә генә тия торгандыр.

Каләмгә тотыныр алдыннан, аның китапларын яңадан бер тапкыр карап чыктым. Күбесен болай да беләм икән. Аның турында язылган мәкаләләрне эзләп карадым. Бик аз икән. Р.Кукушкин, Ш.Галиев мәкаләләре, юбилейлар уңаеннан чыккан кечкенә-кечкенә истәлекләр... Бармак белән генә санарлык. Шагыйрьнең замандашлары белән очраштым, каләмдәшләре белән сөйләштем... Хатыны Гайшә апа янына да барып килгән идем заманында. Кайбер истәлекләрне ул сөйләде... Сибгат ага Хәким белән сөйләшеп утырган чакларны искә төшердем. Балалар әдәбияты турында сүз чыкканда, Бари Рәхмәтне телгә алмый калмый иде... Акрын-акрын гына шагыйрьнең образы күз алдына килә башлады.

Тыйнак, йомшак табигатьле иде диләр. Шаян сүзле, уен-көлкене бик ярата иде диләр. Ничек алай булгандыр ул? Югыйсә шаян табигатьле кешеләр күп сүзле була торган иде. Б.Рәхмәтнең сәхнәдән шигырь укуы бик күпләрнең исендә калган. Үз шигырьләрен укырга бик яраткан икән. Тукай клубында уздырылган шигырь кичләрендә еш чыгыш ясаган. Радио аша да еш сөйли торган булган. Берәр язмасы сакланмаган микән дип белешеп караган идем дә, юк шул, сакланмаган.

Шагыйрьләрне язмыш үзе сайлый. Күп бездә олы язмышлы, кызыклы язмышлы шагыйрьләр. Һәрбер-се—үзе бер тарих, үзе бер дөнья. Бер-берсенә һич тә охшамаган язмышлы шагыйрьләр. Япь-яшь килеш әдәбиятка килеп, дан-шөһрәт казанган талантлы шагыйрьләрне уйлый башласам, күз алдына Бари Рәхмәт килеп баса, аның иҗат биографиясе күңелгә килә. Бөтенләй башка төрле язмышлы, әдәбият кануннарына бик үк сыеп бетми торган биографияле шагыйрь. Татар балалар поэзиясенең соңлап килгән бәхете.

Аның иҗат юлына караганда тормыш юлы баерак та, гыйбрәтлерәк тә. Иҗат язмышы башкаларныкы кебек булмаса да, биографиясендә башка әдипләребез белән охшаш яклары бик күп. 1897 елның 29 маенда хәзерге Казакъстанның Гурьев өлкәсендәге Жилая Коса поселогында туган малай шундагы мәдрәсәдә укып йөри. Татар дөньясының шаулаган чагы, мәдрәсә шәкертләренең дә яңалыкка, яктылыкка омтылган бер вакыты. Мәгърифәткә тартылган яшьләрнең Тукайны укып шашкан, канатланган чорлары. Бари да Тукай шигырьләрен укып белә, үзенең беренче өйрәнчек шигырьләрен дә язып карый. Өстәвенә, шушы якларга сөргенгә җибәрелгән, соңыннан балалар шагыйре һәм педагог булып танылган Фәрит Ибраһимов белән якыннан танышып ала. Танышып кына да калмый, аңардан русчага өйрәнә, татар әдәбияты белән ныграк таныша. Тукай белән ныклап кызыксынуы да шунда башлана. Бөек шагыйрьне яраткан, иҗатына табынган Ф.Ибраһимов ул вакытта ук инде Тукайга ияреп шигырьләр яза, ул шигырьләрен «Ак юл» журналында бастырып та чыгара. Аның Тукай һәм шигърият белән мавыгуы Барига да күчә.

Гомумән, Б.Рәхмәтнең балалар поэзиясенә килүенә Тукай, Фәрит Ибраһимов һәм «Ак юл» журналы сәбәпче булгандыр. Минем мөхтәрәм язучыбыз Нәкый ага Исәнбәтнең татар балалары өчен чыккан ул беренче журнал турында бик яратып, аны күкләргә күтәреп сөйләгәнен, журналның редакторы Фәхрелислам Агеевны олы хөрмәт белән искә алганын тыңлаганым бар. Бу—аңлашыла да. Нәкый ага—шул журналны укып үскән, иң беренче шигырьләрен шунда бастырган язучы. «Ак юл»дан башланган беренче тәҗрибәләре, татар балаларына булган олы мәхәббәте Н.Исәнбәтне олы балалар әдибе итте. «Ак юл»—Бари Рәхмәтне дә әдәбиятка алып килгән игелекле журнал. Үзенең иҗатын ул 1914 елда басылган «Бәйрәм котлы булсын» дигән шигыре белән башлап җибәрә. Беренче шигырьләрен шушы журналда бастыра башлый, аның актив авторына әйләнә. Шуңа күрә дә үзен канаты астына алган әлеге журналга шагыйрь гомере буена рәхмәтле булып кала.

Шагыйрь язмышы! Илебездәге кискен борылышлар, үзгәрешләр, авырлыклар, көрәш юллары Бари Рәхмәтнең дә тормыш юлына әверелә. Кызылармеец, хәрби газета хезмәткәре, эшче, бухгалтер; Бөек Ватан сугышы юллары—солдат, хәрби корреспондент, госпиталь... Шагыйрьнең иҗат юлы гаять тә бормалы,

сикәлтәле. Аның матбугатта шактый басылганнан соң да югалып торган чаклары күп була, бөтенләй онытылып та тора. Әмма шагыйрь күңелендә яткан хәзинә соң булса да тышка ташып чыга, шигырь китаплары булып укучылар күңеленә барып ирешә. Башлангыч чор иҗатында ул революцион күтәренкелек белән сугарылган шигырьләр иҗат итә. Соңрак лирик, сатирик һәм юмористик шигырьләр яза... Әмма сатира-юмор турында сүз чыкканда, без хәзер Бари Рәхмәт исемен телгә алмыйбыз диярлек. Ә бит аның сугыш елларында, шулай ук илленче-алтмышынчы елларда күп кенә шигырьләре халык арасында шактый популяр иде. Бигрәк тә үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концертларында еш яңгырыйлар иде алар. 1957 елда чыккан «Шигырьләр» дип аталган җыентыгы укучыларның яраткан китабына әйләнде. 1916—1956 елларда язылган шигырьләре тупланган йөз битле әлеге җыентык чын мәгънәсендә талантлы шагыйрь кулы белән язылган. Лирик шаянлык, тапкырлык, киная хәтта Бөек Ватан сугышы елларында язылган шигырьләренә дә килеп керә. Темасы, вакыйгасы белән лирик, моңсу, сентименталь булырга тиешле әсәрләрен дә оста гына итеп «елмайта» белә ул. Ирексездән М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Фәйзи кебек шагыйрьләрнең шул елларда язылган шигырьләре искә төшә. Нишлисең, татар шагыйрьләре үлем белән күзгә-күз очрашкан вакытта да елмая белгәннәр. Андый шагыйрьләр арасында Бари Рәхмәт тә бар! Дошманнан ачы көлү, җиңүгә тирән ышаныч, оптимистик рух, халыкчан шаянлык аның сагыну-сагышларына да, сугыш кырларында күргән газапларына да «елмаю» өсти. Бик күп фронтовикларны бәхетле иткәндер ул шигырьләр. Сугыш авырлыкларын, югалту газапларын вакытлыча гына оныттырып торганнардыр. Сугыштан соң да яратып укыдылар ул шигырьләрне. Б.Рәхмәтнең шулай ук сугыштан соң язган сатирик-юмористик шигырьләре дә Ш.Галиев, Г.Афзал кебек юмор осталары иҗаты белән аваздаш булды. Алар бүген дә актуальлекләрен  югалтмаганнар.

Сатира-юмор белән балалар поэзиясе арасында ниндидер бер серле уртаклык бар. Үзендә балалык сыйфатларын саклап кала алган, балаларга хас шаянлыкны, тапкырлыкны, беркатлылыкны югалтмаган шагыйрь генә сатира-юмор әсәрләре яза аладыр, мөгаен. Кайсы гына күренекле балалар шагыйрен алып карасаң да, үзләренең әдәби эшчәнлекләрен сатира-юмордан башлаганнар. Тукай, Маршак, Михалков, Ш.Галиев. Аларның һәркайсы, үзләре дә сизмәстән, танылган балалар шагыйрьләре булып киткәннәр. Шундыйлар арасында, әлбәттә, Б.Рәхмәт тә бар.

Ул балалар әдәбиятына чын мәгънәсендә җитди хезмәт итеп караган, зур әзерлек белән килгән иң беренче шагыйрь булгандыр. Тукай иҗаты белән фольклорга гына йөз тотмыйча, ул рус поэзиясенә дә игътибар итә. Үзе белән бер чорда иҗат иткән К.Чуковский, С.Маршак, С.Михалков, А.Барто кебек шагыйрьләрдән дә балалар шигыренең серләренә өйрәнә, аларның кайбер шигырьләрен татарчага тәрҗемә иткәли. Нәтиҗәдә Б.Рәхмәт татар балаларына—яңа шигъри дөнья, ә балалар поэзиясенә яңа шигъри сүз алып килде. Яңа шигырьләр, заманча шигырьләр иде алар. Тематик яктан да, образлар системасы ягыннан да, балалар психологиясен шигъри юлларга күчерү нисбәтеннән дә ул новаторлык үрнәкләре күрсәтте. Шигырьләрдә баланың үзе күренә башлады. Бала сүзләре белән олыларча кыланучы яисә бала булырга тырышучы лирик герой түгел, ә чын-чынлап бала психологиясен ачып биргән Бала образы иде ул.

Балалар шигырендә риторика, гомуми газета лозунглары өстенлек иткән, балалар китаплары марш атлап йөрүче балалар, ура-шигырьләр белән чуарланган бер чорда аның шигырьләре кайберәүләр өчен, бәлки, сәеррәк тә булып тоелгандыр. Чөнки алар гадәти шигырьләр түгел иде. Ул чакта бит күп шагыйрьләр үзләре уйлап чыгарган балалар дөньясы белән балаларга якын килергә тырышып карадылар. Ләкин ул дөньяның ясалма булуы, чынбарлык белән туры килмәве тиз ачыкланды. Ә Бари Рәхмәт, киресенчә, әдәбиятка балаларның үзләреннән килде. Шуңа күрә дә аның шигырьләрен балалар да, олылар да бердәй җылы кабул иттеләр. Ләкин, һәрбер яңалык шикелле үк, Б.Рәхмәт шигырьләре дә соклану хисләре белән бергә аптырау да тудырды. Ышанмыйчарак караучылар да, җитешсезлек эзләүчеләр дә булмады түгел. Гомере буена аз-маз гына язышып килгән, берчакта да актив шагыйрьләр рәтендә йөрмәгән килеш ничек инде ул кинәт кенә талантлы шагыйрьгә әйләнсен? Картайгач каләмгә тотынган кешеләрнең кем икәннәрен беләбез, янәсе. Хәтта балалар матбугатында да аның шигырьләрен аңламаган очраклар була. Шигырьләре башкаларныкына охшамаган, балалар кабул итәр микән, дип шикләнәләр. Шигырьләрен кире алып кайтып киткән чаклары да була шагыйрьнең. Алып кайтып китә дә шуларны ук балаларга укып карый. Яраталар! Ни өчен дисәң, шагыйрьнең шигырьләре кебек үк, балалар үзләре дә—заман балалары бит.

Г.Ахунов илленче елларда язган бер мәкаләсендә менә мондый бер факт китерә: «Яшермичә әйтәм, балалар язучыларының әсәрләрен күп укыйлар, китапханәләрдән алып та, кибетләрдән сатып алып та укыйлар. Баулы китап кибетендә китаплар сатучы Мәрфуга Әминова иптәш балалар китапларына таләпнең зур булуын әйтте. Ә.Бикчәнтәеваның «Дачада», Бари Рәхмәтнең «Бакчада күңелле» исемле китапларын чират торып алып бетергәннәр. Ә алар Баулы кибетенә 10—15 данә генә түгел, икешәр йөз кайткан...» Китабыңны чират торып алсалар, олы бәхет инде ул! Минем дә шул еллар исемә төште. «Якуп белән

вакыт» исемле шигырьне ятлап, укучыларның район смотрында җиңеп чыккан идем. Ул вакытта шигырьнең авторын да искәрмәгән булганмын. Бари Рәхмәтнеке булган икән бит, рәхмәт яугыры! Әле үзе исән чакта ук аның иҗаты белән таныш булганмын икән. «Бакчада күңелле» исемле җыентыгын да яратып укыганмын. Әле шул елларда чыккан китапларын күргәч, яңадан искә төште. Һәрбер татар баласы кебек, мин дә Бари Рәхмәт шигырьләрен укып үскәнмен.

Әйткәнемчә, безнең балалар поэзиясен Б.Рәхмәт яңа алымнар, яңа чаралар белән баетты. Мәсәлән, балалар шигъриятенә беренче булып цикллар алып килде. Балалар әдәбияты белгече Равил Кукушкин үзенең «Канатлы дөнья» китабында шагыйрьнең бик күп үзенчәлекләрен ачып бирә. Менә шуларның берсе: «Шунысы әһәмиятле — Б.Рәхмәт әсәрләре балалар өчен дә, олылар өчен дә бердәй кызык. Зурлар өчен балачакны искә төшерә торган җылы, мөлаем рухлы, елмаюлы шигырьләр... Ә балаларга алар дөньясын чагылдыруы, конкрет детальләргә корылуы, аларча фикер йөртүе белән кадерле». Бүгенге шагыйрьләрнең шигырьләрен укып карыйм да, таныш рифмалар, таныш темалар, образлар, шигъри детальләр, таныш алымнар күзгә чалынып китә, бигрәк тә, яшьләрдә. Шул исәптән үземнекеләрдә дә...

Бер сөйләшү истә калган. Ничектер минем шигырьләр турында сүз чыкты. Шагыйрь дусларның берсе, шактый гына мактау сүзләре әйткәннән соң, тәнкыйть тә әйтергә кирәк тапты. «Йолдызлар саныйбыз» исемле шигырьдән:

Ә йолдызлар нигәдер
Биешә башладылар,
Селкенә башладылар,
Сикерә башладылар,
Җемелди башладылар,
Дерелди башладылар,
Чуалышып беттеләр,
Буталышып беттеләр...—

дигән өзекне алды да, мондый санап китүләр шигырьнең бәясен төшерә, дигәнрәк фикер әйтте. Киләчәктә санаулардан сакланырга киңәш итте. Шулчакны янәшәдә утырган Ш.Галиев, сүзсез утыруымнан файдаланып: «Ярар, ярар, искә алырмын!»— дип әйтеп ташлады. Бүлмәдә утыручылар әлеге сүзләрдән дәррәү көлешеп алдылар. Бу вакыйганы, Ш.Галиевнең әлеге кечкенә шаянлыгын искә төшерүем юкка гына түгел. Чөнки шагыйрь дустыбыз әлеге «кимчелек»нең балалар поэзиясендәге махсус бер алым булуын, бу шигъри алымның беренче үрнәкләре Б.Рәхмәт поэзиясендә үк кулланылганын белсә, уңайсыз хәлдә дә калмас иде. Дәлил өчен бер генә мисал китерәм. Алар шагыйрьдә шактый күп. «Уенчыклар» шигырендә, мәсәлән, мондый юллар бар:

Ни генә юк анда:
Тун кигән аюлар,
Кыланчык маймыллар,
Тиеннәр, керпеләр,
Куяннар, төлкеләр,
Мөгезле пошилар,
Мыеклы песиләр...

Бу алым балалар шигырендә иң элек картина тудыру, шигырьдә сөйләнгән вакыйганы ныграк күз алдына китерү өчен кулланыла. Аннары ул шигырьнең хәрәкәтчәнлеген, динамикасын арттыру өчен дә кирәк. Ш.Галиевнең үзенең дә шактый шигырьләре, чыннан да, шул алым белән язылган. Яшь шагыйрь Афзал Нигъмәтуллинда да бар иде андый шигырьләр. Аннан соң киләчәк шагыйрьләрдә дә булыр дип уйлыйм.

Бари Рәхмәт, миңа калса,—Тукай шәкерте. Әгәр дә игътибар беләнрәк карасаң, аның шигырьләре Тукайның балалар өчен язылган әсәрләре белән шактый аваздаш икәнен күрербез. Балалар шигърияте өчен кирәк сыйфатларның күбесен ул Тукайдан алган... Һәм Шәүкәт Галиевкә тапшырган. Б.Рәхмәт — балалар әдәбиятында Тукай белән Ш.Галиев арасында торучы, аларның иҗатын бергә тоташтыручы шагыйрь. Ул үзенең шигырьләрен балалар поэзиясенә Шәүкәт Галиев килсен өчен яза башлагандыр кебек. Аны кызыктырыр өчен, балалар шигыренең мөмкинлекләрен, аның серләрен сөйләр өчен, балалар поэзиясе пәрдәсенең бер читен ачып күрсәтер өчен язгандыр кебек. Чыннан да, әгәр дә поэзиядә Бари Рәхмәт булмаса, Ш.Галиев балалар өчен яза башлар иде микән? Ә бит Б.Рәхмәт шигъри эстафетаны, чыннан да, Ш.Галиевкә тапшырып китә.

Бари Рәхмәт 1957 елның 26 маенда, 60 яше туларга өч көн калганда вафат булды. Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә. Зур залның сәхнәсендә, кайнарланып шигырь укыганда. Шигърияте чәчәк аткан бер вакытта. Олы иҗат дәрте белән янып йөргәндә. Әмма аның үлеме дә шигъри үлем булды. Кайнап торган бер халәттә, тантаналы шигъри мохиттә йөрәге тибүдән туктады. Шигъриятен турыдан-туры шигырь сөючеләргә калдырып китте ул. Көчле кул чабулар, алкышлар астында. Ул алкышлар шагыйрьнең үлеменә түгел, аның татар балаларына калдырган үлемсез иҗатына иде.

*1987—1997*

Эчтәлек


Без теләгән шагыйрь (*кереш*) ..............................

Балалар өчен шигырьләр

Җиде абый тай җигә ................................................
Өлкәннәр ..............................................................................
Бүтәннәр күрмәсә дә... ................................................
Торам менә елмаеп ....................................................
Айны ничек менгезим? ..............................................
Олы булсам... ......................................................................
Карбабайның борыны турында ике шигырь
Пират .............................................................................
Сүз тыңлый торган малай .....................................
Әни эштән кайтканчы ..........................................
Бутаган ...............................................................................
Югалган көн ....................................................................
Әтием палас кага .......................................................
Мактанырга яратмый... ............................................
Әйтмим ..........................................................................
Булатларга кунакка! ..................................................
Йолдызлар .........................................................................
Сабантуйда .....................................................................
Кем нәрсә тарта... .........................................................
Кызыл тавык ...................................................................
Кыр кәҗәсе .....................................................................
Мөгезсез бозау .............................................................
Саттар дәү үскән! ........................................................
Минем таныш автобусым ...................................
Энемне тирбәткәндә ..............................................
Әкәмәт җанварлар .....................................................
Качышлы уйнаганда ...................................................
Яздык ....................................................................................
Яңа ел ...................................................................................
Тылсымлы таяк ...........................................................
Кәнфиткә алыштырган ..........................................
Бакча белән хушлашу ...............................................
Авырткан кебек кенә ................................................
Уйламый ярамый! .........................................................
Тәгәрмәчле яңгыр .......................................................
Бабай кебек .....................................................................
Мин кояшны яратам! ...............................................
Күчтәнәч ...........................................................................
Йолдыз буласым килә ..............................................
Песнәк белән сөйләшү .............................................
Елмаючы...…бүреләр .......................................................
Хәйләкәр малай .............................................................
Акбай шулай ди... ...........................................................

Урман аша узганда .....................................................
Акбайга ..................................................................................
Кояш белән узышу ......................................................
Без абыйны озаттык .............................................
Кураем ....................................................................................
Урамнан фил китеп бара .......................................
Мине дә күрәләрдер ..................................................
Елның дүрт төсе ........................................................
Курыкмыйбыз! ................................................................
Туган илнең улы мин! ................................................
Акбай цирк карый .......................................................
Яз булмас микәнни? ...................................................
Җиңел җилләр, җитез җилләр... ............................
Кеше карап тормагач ...............................................
Яңгыр шундый буламы? ...........................................
Агыйнеш ..........................................................................
Балачак бәйрәмнәре ...................................................
Яңгыр җыры ....................................................................
Иписез табын... ..............................................................
Игенчеләр гаиләсе ......................................................
Сабантуй бүген бездә! ...............................................
Тәкә ......................................................................................
Кульъяулык ..........................................................................
Энем арттан иярә! .....................................................
Чүлмәк вату ....................................................................
Әтәчле сәгать .............................................................
Малайлар сөйләшә ........................................................
Хәрефләр буталганда ...............................................
Бик әйбәт минем эшләр! .......................................
Чыршы әйләнәсендә ..................................................
Әти төсле! ........................................................................
Мин — укучы әтисе! ...................................................
Аяк тая тайгакта .....................................................
Икесе дә мин үзем! .....................................................
Арыган... ..............................................................................
Кыш бабайны көткәндә ..........................................
Беркем узып китәлми! ..............................................
Үзебез генә калгач ......................................................
Телевизор...…тыңлыйбыз ...........................................
Рәсем ....................................................................................
Яз килгән бит! ................................................................
Яз керде өебезгә! ..........................................................
Өйрәнә ..................................................................................
Бабай белән абый .........................................................
Көтәм мин корабымны .............................................
Капитан булачакмын! ................................................
Күршеләрнең бакчасы ................................................
Кем дә елар иде! ...........................................................
Әниемә булышам! .......................................................
Кызыл төс ........................................................................
Көтү әйбәт көтелгән ..............................................
Беренчегә! ..........................................................................
Үзем ясаган кораб .........................................................
Светофор ..........................................................................
Тырыш малай ................................................................
Яңа бүрек .........................................................................
Чәкчәк ..................................................................................
Ничекнигәниөчен ...........................................................
Мин әгәр икәү булсам... .............................................
Кысла .......................................................................................
Кызганыгыз бүрене! ....................................................
Черкиләр җыры .............................................................

Портта булган хәл ....................................................
Балыкчы ...............................................................................
Җил авырган бит әле! ..............................................
Җил .......................................................................................
Чишмә җыры ....................................................................
Безнең як крокодиллары ...........................................
Мичкә ягылган мичкә ...................................................
Урманда .................................................................................
Менә сиңа мә! ..................................................................
Армас-талмас Барлас ................................................
Кем соң минем Әби? ..................................................
Мөгезборын белән озынборын ................................
Кайтабыз ла җиләктән ............................................
Айга очтык! .......................................................................
Батырлык эшләр идем... ..........................................
Тырышам .............................................................................
Әни кирәк ...........................................................................
Онытканнардыр... ......................................................
Барыбер ...............................................................................
Әйбәт булган! ..................................................................
Белә икән ............................................................................
Үч итеп! ...............................................................................
Әллә мин Гаяз микән? ..................................................
Күзләреннән аңлыйбыз ..............................................
Бәрәңге алышабыз .........................................................
Юкка малай булганмын! ............................................
Дельфин да күрмәгән! ................................................
Уйлап табучы ....................................................................
Пианино ...............................................................................
Нәкъ Чапай кебек чабам! ........................................
Саныйлар .............................................................................
Булышчы ............................................................................
Мин әнигә ышанам .......................................................
Алмаш-тилмәш ..............................................................
Тәмле кычыткан ..........................................................
Рррр белән Мррр .............................................................
Беркемгә дә охшамаган ...............................................
Крокодил йомыркасы ..................................................
Кайтмый калдык чак кына! .....................................
Кайтыйк ла үзебезгә! ..................................................
Сөн буенда .........................................................................
Яңгырдан соң .....................................................................
Колын ......................................................................................
Нәни поши ............................................................................
Атказанган сандугач ...................................................
Өзмәдем ...............................................................................
Акбай, Актүш, Актырнак ........................................
Жираф .....................................................................................
Туган тел ............................................................................
«Шираматан» ....................................................................
Карачкы-батыр ...............................................................
Акрын тәмамланучы тиз шигырь .....................
Җәяүле буран ..................................................................
Мөгезле болыт ................................................................
Ай нәрсәгә охшаган? ....................................................
«ДТ-75» тракторының улына җырлаган бишек җыры ......................................................................
Ак ат .....................................................................................
Буранлы көн .....................................................................
«Ми-8А» ...................................................................................
Мияулый торган ишек ...............................................
Санарга өйрәнәбез .......................................................
Дәрестә .............................................................................

Үсик әле ..................................................................................
Югалган хәрефләр ........................................................
Абый итеге ......................................................................
Әби белән Нәби ................................................................
Алмазның гаражы ...........................................................
Кызык! ......................................................................................
Күңелле тәнәфес ............................................................
Алмаз, үгез һәм мөгез ................................................
Дөнья балаларының кешелеккә әйтер сүзе ...
Минем сеңелкәшем! .......................................................
Бабайлар нинди була? ................................................
Без таган атынабыз! ................................................
Йөрибез! ................................................................................
Без йолдызлар саныйбыз .........................................
Әни, мин көчек күрдем! ...........................................
Әниемә ял кирәк! .........................................................
Печән өсте .......................................................................
Табышмак-шигырь .......................................................
Оча торган чаңгылар ................................................
Кем ничек өлгерә? .......................................................
Сайрый торган агач ...................................................
Мин дә катнаштым! ...................................................
Җәйнең яшел аты .......................................................
Болытлар ...........................................................................
Сабантуй кызык булды ............................................
Кара инде бу гөлне! ......................................................
Зоопаркта ниләр бар? ..............................................
Диңгезләр нинди төстә? ........................................
Серле кара маҗаралары ...........................................
Таш, чыпчык һәм алма ............................................
Боек үгез ..............................................................................
Йөгәнсез чаптар ..........................................................
Канатлы ут ......................................................................
Яңгыр .....................................................................................
Үзебез ясаган машина ................................................
Шүрәле ..................................................................................
Җилләр исте куяннан! ...............................................
Энекәш кирәк миңа! ...................................................
Җайдаклар ........................................................................
Кызык кеше .....................................................................
Качып калган яңгыр ....................................................
Сандугач белән малай ................................................
Мияу! .......................................................................................
Тирәкләргә җил кирәк! ..............................................
Куркак туп .......................................................................
Очасым килә ....................................................................
Дер-дер куян ....................................................................
Өрә белүче шкаф ..........................................................
Койрык .................................................................................
Пешмәгән ............................................................................
Туган тел ............................................................................
Шигъри әлифба
Ай ...............................................................................................
Әтәч ......................................................................................
Болыт ......................................................................................
Велосипед ............................................................................
Гөмбә .......................................................................................
Дага белән дуга ...............................................................
Елга ...........................................................................................
Жираф ....................................................................................
Җиләк ......................................................................................
З ...................................................................................................

Иләк ..........................................................................................
Йолдызлар ...........................................................................
Капка .....................................................................................
Лимон ...................................................................................
Машина ...............................................................................
Нота .....................................................................................
Үсми калган хәреф ....................................................
О ...............................................................................................
Өстәл ....................................................................................
Песи .......................................................................................
Рәшәткә ..............................................................................
Сөлге ......................................................................................
Тук тукран ........................................................................
Урындык ..............................................................................
Үгез ........................................................................................
Фонарь .................................................................................
Хат ...........................................................................................
Һәйкәл ...................................................................................
Циркуль ...............................................................................
Чаңгы белән чалгы ....................................................
Шырпы ..................................................................................
Щетка ....................................................................................
ъ билгесе ............................................................................
Ыргак ....................................................................................
ь билгесе ............................................................................
Эт .............................................................................................
Юлбасар юлбарыс ........................................................
Ябалак ...................................................................................
Журнал укучы жираф ...............................................
Сөзәргә өйрәнә .............................................................
Сакчылар ............................................................................
Белдерү ................................................................................
Черки, чабак, чуртан һәм чиләк .........................
Кро! ко!! дил!!! ...................................................................
Ачык авыз .........................................................................
Көнгерә ................................................................................
Төклетура ..........................................................................
Бытбылдык ........................................................................
Елан белән камчы .......................................................
Аю ...............................................................................................
Дөя ...........................................................................................
Нарат ....................................................................................
Чыршы .................................................................................
Имән .......................................................................................
Алма .......................................................................................
Тирәк .....................................................................................
Эт ...........................................................................................
Үрдәк ...................................................................................
Төнбоек ..............................................................................
Ташбака ..............................................................................
Йомран ................................................................................
Карлыгач ............................................................................
Тилгән ..................................................................................
Антилопа .............................................................................
Шүрәлеләр турында, Тылсынчы бабай турында һәм малайлар турында, тагын шүрәлеләр турында кечкенәкият ................................
Җәяү йөрүче машина турында кечкенәкият
Батыр куянның ничек итеп куркак куянга әйләнүе турында кечкенәкият ..............................
Куян йөрәкле бүре турында кечкенәкият ....
Бозау белән көчекнең дуслашуы турында кечкенәкият .....................................................................
Кечкенә көчек турында кечкенәкият .............
Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенәкият ............................................................................

Койрыксыз куян турында кечкенәкият .........
Кояш буласы килгән кызыл шар турында кечкенәкият .......................................................................
Хәтерсез балыклар турында кечкенәкият ..
Бүренең кешеләр белән дуслашуы турында кечкенәкият ...................................................................
Зур кабак турында кечкенәкият .......................
Балыкчы булырга хыялланучы суалчан турында кечкенәкият ..................................................
Кояш, жираф һәм төлке турында кечкенәкият ..................................................................................

Әдәби тәнкыйть, иҗат портретлары, рецензияләр

Киләчәк буын хакына .................................................
Үз җырларын җырлатыйк! .......................................
Ана сөте белән! ............................................................
Күңелгә якын шигырьләр .........................................
Сөендерде дә, көендерде дә ..................................
Уртак уйга чакыру .......................................................
Балачактан башланырга тиеш! ...........................
Балаларыбызның Ак Апасы ......................................
Балалар дөньясын яңгыратып... ..............................
Урыны—түрдә ................................................................

Литературно-художественное издание

Миннуллин
Роберт Мугаллимович

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

I книга

(*на татарском языке*)

Редакторы *Н. К. Нотфуллина*
Тышлык рәссамы
һәм бизәлеш редакторы *Л.С.Золондинова*
Техник редакторы
һәм компьютерда биткә салучысы *Л.М.Тилк*
Корректорлары *Г.Г.Мөхәммәтҗанова,*
*Ф.Х.Макарова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.03.2004.
Форматы 75ә90 1/32. Офсет кәгазе.
«Korinna» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 17,5+форз. 0,16.
Нәшер-хисап табагы 14,01+форз. 0,28.
Тиражы 5000 д. Заказ Э-20.

«Мәгариф» нәшрияты.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф».
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http: // magarif. kazan. ru
E-mail: magarif @ mail. ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.